www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 31 (1447) 11 август 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



7

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Миңнуллинның без быел 75 яшьлеген билгеләп үткән булыр идек.



16-17

Бәгъзе драмаларда кулын сузып, хәер эстәп йөргән качак рәвешендә сурәтләнгән Гаяз Исхакыйның көндәлекләре аның бөеклеген исбат итә.

24

Казан кирмәнендә узучы «Мирас һәм традицияләр» күргәзмәсендә төрле халык образлары булып гәүдәләндерелгән курчаклар барча тамашачыларны гашыйк итте.

Идел-йортта кызу урак өсте, Имин көннәр бирсен Ходаем...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Быелгы урак барышында Татарстанның иген кырларыннан беренче миллион тонна икмәк уңышлы җыеп алынган.

● Ил башлыгы В.Путин Россиянең барлык чиновникларын үзебезнең ил заводларында эшләп чыгарылган автомашиналарга күчереп утыртырга ниятли.

● Татарстанда айлык уртача хезмәт хакы 57 мең 490 тәңкәгә менеп җиткән һәм без Идел буе федераль округында иң югары күрсәткечкә ирешкәнбез икән.

● Норвегия апрель аенда Россия илчелегеннән 15 хезмәткәрне чыгарып җибәрү турында карар кабул иткәч, Россия моңа җавап итеп Норвегия илчелегенең 10 кешесен илдән чыгарды һәм моңа кадәр «безнең белән дус түгел илләр» исемлегендә 47 илгә (шуларның 27 се – Европа Берлеге илләре) Норвегия дәүләтен дә өстәп куйды.

● Карелия республикасының Деревянное авылында ике сәрхуш ир берьюлы ике йортка ут төртеп, 6 кешене (шуларның дүртесе балалар) яндырып үтергәннәр.

● Мәскәү биржасының «Арикапитал» компаниясе генераль директоры Алексей Третьяков, нефть һәм газ сатудан валюта керемнәре кимү сәбәпле, август аенда доллар курсының 100 сумнан артып китәчәген белдерде.

● Сок елгасында су коенучы 12 яшьлек кыз баланың аякларын яннан узучы моторлы көймә винтлары кисеп үтә, табибләр аның аякларын көч-хәл белән генә саклап кала.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

14 август – композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Луиза Миңнегали кызы Батыр-Болгари (Батыркаева)га 70 яшь (1953).

15 август – җырчы, педагог, ТАССРның халык артисты Асия Сафиулла кызы Измайлованың тууына 120 ел (1903–1993).

17 август – хәрби һәм сәяси эшлекле, дипломат Хөсәен Баһаветдин улы Мәүлетовның тууына 130 ел (1893–1937).

СЫНАМЫШЛАР

- 11 августта иртән кырау төшмәсә, 5 сентябрьдә дә төшмәячәк әле.
- 14 августтан (Бал Спасы) салкын чык төшә башлый; мәк уңышын җыялар.
- 15 августта көн нинди булса, сентябрь буе шундый була.
- 16 августның һава торышы октябрьнең нинди булачагын күрсәтә; көчле җил иссә, карлы кыш көтелә.
- 17 августта нинди көн булса, ноябрьдә һава торышы шундый була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 07 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 32 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 25 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **30 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **18 августта 14 сәгать 55 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(8-16 август)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның 24 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Иршад ГАФАРОВ

АЮ ТИРЕСЕН БҮЛЕШҮ...

Инде ничә еллар телевидениедә «үлмәгән аюның тиресен бүлешү» бара. Бәхәснең нигезендә: «Кырым кемнеке, руслар һәм украинлылар туганнармы, Киев – славяннарның башлангычымы» һ.б. сораулар ята. Шул уңайдан Козьма Прутковның: «Зрите в корень!» – дигән афоризмын искә аласы килә. Безнең очракта «тамыр» ул тарихи мәгълүматлар, табылдыклар...

Заманында мәшһүр рус тарихчысы В.О. Ключевский (1841-1911), шул чорда табылган кульъязмалар нигезендә, 28 томлык Россия империясенең тарихын язган. Анда түбәндәгеләрне укыйбыз: «VII гасырга кадәр Киев тирәсендә славяннар юк иде, ә аларның зур хәрби берлеген VI гасырда Карпат тирәсендә очратабыз. Бу хәрби берлекне без тарихыбызның башлангыч чорына куя алабыз: ул VI гасырда иң читтә, безнең тигезлекнең көньяк-көнбатыш почмагында, Карпат тауларының төньяк-көнчыгыш итәкләрендә һәм битендә башлана. Көнчыгыш славяннар VII гасырда әлеге итәкләрдән Рус тигезлегенә күченеп утыра башлый. Әлеге күченешне безнең тарихның икенче башлангычы турындагы факт дип танырга мөмкин».

Аның сүзләренә расламаны без «Россия: Полный энциклопедический иллюстрированный справочник» та (2002) да табабыз, Анда: «Славяннар хәзерге Россиядә 700 нче еллар тирәсендә күренә», – дип язылган.

Әлеге хәбәрләр русларның башлангыч ватаннары Алтай, Ерак Көнчыгыш һәм гомумән барысы да руслардан башланган, дип тарихны яңадан язарга тырышучыларга да җавап булып тора.

Биредә урынлы сорау туа: «Ул чакта Днепр елгасы бассейнына урнашкан Киев, Полтава тирәсендәге җирләрдә кемнәр яшәгән соң?» Ниһаять, бу турыда дөреслек ишетелде кебек. Безнең карашка, бу сорауга политолог, тарих фәннәре докторы Александр Сытин җавабы туры килә. Быелның 5 апрелендә «Место встречи» тапшыруында ул: «Элек «Кыргый дала»да бернинди дә украиналы булмаган (димәк руслар да), ә анда ат өстендә татарлар йөргән», – дип ныклап әйтте. Димәк, татарларның борынгы бабалары болгарлар яшәгән. Әлеге фаразның шулай икәне күптән тарихта билгеле булса да, моны бер як та танырга теләмәде. Һаман да «үтерелмәгән аюның тиресен бүлешү» барды.

632 елда Кубрат хан җитәкчелегендә Бөек Болгарстан исемендәге дәүләт төзелә. Икенче төрле ул «Болгар кабиләләренең берлеге» исемендә дә билгеле. Бу дәүләт Түбән Кубань һәм Көнчыгыш Азов буйларын, ә кайбер чыганакларга караганда, көнчыгышта, Каспий диңгезеннән алып, көнбатышта, Көньяк Бугка кадәр, ягъни Украинаның Киевтән көнчыгышка таба булган барлык җирләрне үз эченә ала. Заманында Бөек Болгар дәүләте шактый көчле була. 640 елларда болгарлар Византия белән берләшмә дә төзи.

Якынча 642 елда хан Кубрат вафат була. Тарихи мәгълүматларга караганда, ул агулы уктан яралана. Шундый риваять сакланган. Кубратның биш улы була. Үләр алдыннан ул аларны үз янына чакыра һәм аларга себерке биреп, шуны сындырырга боера. Тик күпме генә тырышсалар да, булдыра алмыйлар. Шуннан себеркене туздырып, һәр чыбыкны аерым-аерым сындыралар. Кубрат: «Әгәр бергә булсагыз, сезне беркем дә җиңә алмас, аерылсагыз, җиңелерсез!» – ди.

1912 елда Полтава өлкәсенең Яңа Санжар районы Кече Перещепина авылы янында күп алтын һәм көмеш әйберләре булган кабер табыла. Алар арасында ат дирбиясе, сугышчы кораллары һ.б. кирәк-яраклар, савыт-саба бар. 800 дән артык (урлаганнан соң калган) җиһаз 25 кг алтын, 50 кг көмештән ясалган була. Хәзерге заманда ул Санкт-Петербург Эрмитажында «Кубрат хан хәзинәсе» исемендә саклана. Табылдыклар арасында «Кубрат патрикий» дигән монограммалы балдак та бар. 1994 елда алар Татарстанның милли музеенда да куелган иде.

Бер чыганактан күренгәнчә, хәзинә озак еллар буе өйрәнелми. Сәбәп, безнең карашка, бик гади: Пушкин сүзләренә мөрәҗәгать итсәк: «Здесь Русью не пахло!». Заманында шундый ук хәл орхон-енисей язмалары (руннары) белән дә булган иде. Шифрлар ачыкланып, аларның төрки телдә язылган булуы беленгәч, совет галимнәре алар белән кызыксынуны туктата.

1980 елларда гына хәзинә белән немец тарихчысы, профессор Иоахим Вернер кызыксына башлый. Аңа Германия һәм Болгария тарихчылары һәм археологлары да кушыла. Тикшерүләр нигезендә Вернер монография бастырып чыгара. Аңарда ул, «Перещепина хәзинәсе Кубрат ханны күмү белән бәйле, җирләү өчен кирәк булган әйберләр җыелмасы» дигән, фәнни нигезләнгән нәтиҗә ясый. 2001 елда Украинаның Болгар ассоциясе тарафыннан әлеге урында истәлек билгесе дә куела.

Тик балалар әтиләренең сүзен тыңламый һәм алар Бөек Болгарны бишкә бүлә. Аларның һәркайсы үз отрядларын җитәкли, ә ялгыз килеш хазарларга каршы торырга көчләре җитми. Хазарларның кысрыклавы нәтиҗәсендә, Котрак җитәкчелегендәге төркем төньякка юнәлә һәм VII-VIII гасырларда урта Идел һәм Камада төпләнеп кала. Биредә соңрак Идел Болгарстаны барлыкка килә. Әлеге болгарлар хәзерге казан татарларының һәм чуашларның бабалары була.

Кубратның өченче улы Аспарух хан җитәкчелегендәге икенче төркем көнбатышка таба юнәлә һәм Дунай елгасының түбән агымында туктала. Ул җиде славян кабиләсен буйсындыра. Әмма тарихта бу очракта көчләү булмаган, дип раслана.

679 елда болгарлар Византия армиясен тар-мар итә. Вакыт узу белән болгарлар славяннар белән кушыла. Аспарух болгарлары белән төрле славян һәм фракия кабиләләре калдыклары кушылуыннан, беренче славян дәүләтләреннән булган, Болгар патшалыгын төзегән болгар милләте барлыкка килә. Бер нәрсәне искәртәсе килә, төркиләр телләрен, гореф-гадәтләрен югалтса да, милләт исемен саклап кала алган.

Мин София шәһәрендәге картиналар галереясында «Хан Аспарух славян кабиләләрен буйсындыра» исемле күләмле хезмәт каршында озак басып тордым. Картинада мех киемнәрдән, бүрекләрдән һәм төркиләрчә коралланган җайдаклар сурәтләнгән.

Патшалык төзелүнең вакыты 681 ел дип билгеләнә. Болгар киночылары әлеге вакыйганың 1300 еллыгына багышланган «Хан Аспарух» исемле ике сериядән торган фильм да төшерә. Фильмда дунай болгарларының Идел ярларыннан килгән кардәшләре белән очрашу мизгеле турында күренеш бар. Кунаклар үзләренең тормыш итү өчен бик җайлы урын табулары турында сөйли. Ау, балыкчылык белән шөгыльләнергә, терлек асрау өчен зур мөмкинлекләр булуын искәртәләр. Моңа җавап итеп хуҗалар: «Без инде гаиләләр төзедек, уртак балаларыбыз үсә, без монда калабыз!» – дип җавaплый. Аспарухны Болгариядә хөрмәт белән искә алалар, аның исемендә шәһәр, урамнар бар. 100 атаклы болгар исемлегендә Аспарух өченче урынга куелган.

Болгарларның шактый өлеше, Кубратның бүтән улы Батбай белән үзләренең төп туган җирләрендә калган. Тиздән алар Кырым ярымутравын, Днепр буендагы далаларны һәм урман-далаларны яулап ала.

Славяннар милләт буларак нәкъ шушы төбәктә оеша. Алар сарматлардан һуннарга, алардан соң аварларга һәм болгарларга ясак түләүче халык булып тарихка керә. Болгарлар күченеп киткәндә аларны үзләре белән алмаган, һәм алар шул җирләрендә калып, беркүпме вакыттан соң Киев Русена берләшә. Шулай булгач, без ышанычлы итеп, борынгы болгарлар күп милләтләрнең, шул исәптән, украин, рус, Кавказ төрки халыкларының, чуашларның барлыкка килүендә мөһим роль уйнаган, дип әйтә алабыз.

Болар барысы да V гасырда Киев шәһәренә нигез салучылар Щек һәм Хорив, сеңеле Лебед белән кенәз Кий нигез салган дигән билгеләмәнең дөреслеген шик астына куя. Ягъни Рус оешуга 200 ел алдан, монда киләчәк варисларыбыз яшәячәк дип, Днепр ярларына славяннарның төзүчеләр җибәрүенә ышанычбелдерә алмыйбыз.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән: вакыйгалар, хәбәрләр, яңалыклар

Тынычлыкка сикәлтәле юл

Теләсә нинди сугыш та тыныч сөйләшүләр белән тәмамлана, дигән гыйбарәне еш ишетергә туры килә. Вәләкин тарих дөньядагы иң дәһшәтле сугышның да аны башлаган якның берсүзсез капитуляциясе белән тәгәлләнүенә шаһит. Бу җәһәттән, Украинада инде бер ел ярым бара торган махсус хәрби операция белән бәйле хәлләр дә күп кенә сораулар тудыра. Алга куйган рәсми максатлары тискәре нәтиҗәләргә китерүе сәбәпле, бүген инде ул Россиягә каршы Көнбатыш алып бара торган гибридлы сугыш буларак та игълан ителде. Шул ук вакытта, сәяси яктан Мәскәү Украинада үз контролен урнаштырган территорияләрне ничек булса да үзендә калдырырга омтыла. Ә Киев инде үзенең халыкара дәрәҗәдә танылган территорияләрен хәрби юл белән тулысынча азат итүне һәм, илгә салынган матди зыянны да каплау ниятендә, Россиядән репарация түләтүне максат итә. Ләкин хәрби яктан ул тулысы белән Көнбатыш һәм халыкара коалиция ярдәменә бәйле. Хәлбуки, АКШ Россиянең җиңелүен дә теләми. Чөнки зур сәясәттә Көнбатыш белән Россия әлеге сугыш аша, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда (халыкара мөнәсәбәтләрдә яңа дөньяви тәртип урнаштыру) эш итә. Шуңа күрә Украинага хәрби ярдәмне дә ул сугышны дәвам итәрлек дәрәҗәдә генә күрсәтә. Максаты – халыкара аренада бүген чик-чаманы тәмам югалткан һәм үзенең бөекдержавачыл амбицияләренә янә ирек биргән Россияне хәрби, икътисади вә сәяси яктан үз урынына кую.

Фронтлардагы хәлнең хәрби ягына килгәндә, шахмат телендә аны хәзер, мөгаен, пат халәте дип бәяләргә буладыр. Дөнья тотучылар моны махсус эшләде кебек, чөнки, бер яктан, Россиягә үз контролендәге территорияләрдә оборонаны тоташ мина кыры һәм тимер-бетон белән ныгытылган кат-кат линияләр итеп кору мөмкинлеге бирелсә, икенче яктан, Украинага контрһөҗүмгә күчү өчен кирәкле сугыш коралларын (F-16 очкычлары, ур-тача ераклыкка оча торган ракеталар һ.б.) кую соңарды. Шуңа күрә фронт сызыгы да үзгәрешсез кала диярлек. Шул ук вакытта Киев һаман тактик яктан мөһим биеклекләрне кулга төшерү җаен карый һәм, Россия оборонасын өзеп, диңгезгә чыгуны (Кырымны коры җир аша логистикадан аеруны) максат итә. Аның стратегик резервлары да җитәрлек. Ә мөмкинлекләр тупланышы алга таба яңа мөмкинлекләргә дә юл ача һәм моны мәскәүлеләр дә аңлый. Икенчедән, Киев белән тыныч сөйләшүләрне башлау Мәскәүгә үз йөзен саклап калу мөмкинлеге дә бирә. Киев исә мөнәсәбәтләрне әлегә фәкать сугыш кырында җиңеп кенә ачыклауга йөз тота кебек.

Мәгълүм булганча, тыныч сөйләшүләргә әзерләнүнең хәрби, сәяси, дипломатик һ.б. юллары бар. Беренчесе сугыш кырында каршы якка мөмкин кадәр зуррак зыян салуны, шул рәвешле, сөйләшүләрдә аны күндәмлеккә этәрүне максат итә. Әлегә һәр ике як өчен дә ул төп юнәлеш булып кала. Сәяси юл исә дошманга төрле коалицияләр аша басым ясау мөмкинлеге бирә. Ә дипломатик чаралар исә күбрәк хокук һәм дипломатия аша эш итүне күздә тота. Нәтиҗәләр, әлбәттә, дөреслекнең кем ягында булуына да бәйле. Шуңа күрә Мәскәүгә бүген, дөнья тотучыларның «сәясәт коралы» буларак, алар яклавына исәп тотып та эш итәргә туры килә (җөмләдән, алар узган гасыр ахырында да Россияне таркалудан саклап калды: Кремльгә бирелгән карт-бланш Чечня фонында илдә «хакимият вертикале»н торгызуга юл ачты). Бу җәһәттән игътибарны узган айда дөнья матбугатында шау-шу тудырган бер хәбәр җәлеп итә. Анда сүз АКШ ның геосәясәткә бәйле кайбер элеккеге түрәләре, Украинада низагны туктату буенча сөйләшүләргә нигез салу максатында, быел апрельдә Нью-Йоркта РФ тышкы эшләр министры С.Лавров белән берничә сәгатькә сузылган яшерен сөйләшүләр үткәрүе турында бара. Дөрес, министрлыкның рәсми вәкиле М.Захарова моны соңрак «фейк» дип атады. Ә бу инде үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Чөнки мондый эшләрдә төтен утсыз гына булмый.

Күптән түгел В.Зеленскийның тынычлык формуласын гамәлгә кую буенча өч фазалы дипломатик һөҗүмгә күчүе турында Киев тә белдерде. Аның кысаларында бу планны алга этәрү ниятендә, июньдә Копенгагенда 15ләп ил катнашында бер очрашу инде үткәрелгән дә. Ә узган ял көннәрендә Җиддә каласында, Согуд Гарәбстаны белән берлектә, икенче очрашу да үткәрелде. Анда 40лап илдән (АКШ, Бөекбритания, ЕС илләре, Иран, Кытай, Һиндстан һ.б., БРИКС илләре дә килгән, Россия генә чакырылмаган) вәкилләр катнашкан. Максаты – әлеге тынычлык планын «Глобаль Көньяк» илләренә дә тәкъдим итү һәм уртак фикергә килү. Анда, Украина суверенитетын һәм территориаль бөтенлеген хөрмәт итү, БМО уставының өстенлеге кебек үк, тынычлык буенча теләсә кайсы килешүнең дә үзәгендә булырга тиеш, дигән уртак фикергә килгәннәр. Очрашуда шулай ук, В.Зеленский тәкъдим иткән тынычлык формуласының төп пунктлары буенча эшче төркемнәр булдыру һәм консультацияләрне алга таба да дәвам итү турында карар кабул ителгән. Мәскәүдә сөйләшү нәтиҗәләре тискәре бәяләнгән, мәсьәләне БРИКС очрашуында ачыкларга җыенуларын әйткәннәр. Киевтә исә ул «тынычлык формуласы»ның эшли башлавы буларак бәяләнгән. Анда ел ахырына кадәр дәүләт җитәкчеләренең тынычлык буенча глобаль саммиты үткәрелүенә дә исәп тоталар.

Фоат УРАЗАЙ.

Роберт Миңнуллин исемендәге бәйге

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге Роберт Миңнуллин исемендәге II балалар әсәрләре бәйгесен игълан итә. Бәйгегә әсәрләр 2023 елның 1 октябренә кадәр дүрт номинациядә кабул ителә:

«Балалар һәм үсмерләр өчен иң яхшы проза әсәре» (повесть яки хикәя)

I урын – 100 мең сум;
II урын – 80 мең сум;
III урын – 60 мең сум;

«Иң яхшы комикс» (иллюстрацияләр аша тасвирланган хикәя):

I урын – 120 мең сум;
II урын – 90 мең сум;
III урын – 70 мең сум;

«Балалар һәм үсмерләр өчен иң яхшы драма әсәре»:

I урын – 90 мең сум;
II урын – 70 мең сум;
III урын – 50 мең сум;

«Иң яхшы балалар шигыре (шигырьләр циклы яки поэма)»:

I урын – 80 мең сум;
II урын – 50 мең сум;
III урын – 40 мең сум.

Әсәрләр электрон формада (DOC, DOCX яки PDF форматларында) sprt@tatar.ru һәм Aydar.Gilyazov@tatar.ru электрон адресларына «Роберт Миннуллин исемендәге конкурска» дип җибәрелә һәм ике данәдә кәгазь формада Татарстан Язучылар берлегенә тапшырыла. Аерым конвертта автор (исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туган елы, адресы, телефон номеры, персональ мәгълүматны эшкәртүгә ризалыгы) турында мәгълүмат тапшырыла.

1 нче биттә – «Игенченең уңганлыгы кырларыннан күренә». Фото «Татмедиа» фотоархивыннан алынды.

Тугыз фильм төшерү өчен җиде миллион сум

Агымдагы елда Татарстан Мәдәният министрлыгы 9 фильм төшерүгә җәмгысы 7 миллион сум күләмендә акча бүлеп бирергә ниятли. Шул максатта фильмнарга бәйге игълан ителә. Анда республикабызның коммерцияле булмаган оешмалар катнаша ала.

Исемлектә түбәндәге тема һәм жанрлар тәкъдим ителгән:

– «Дәвер шәхесе» яки «Гасыр вакыйгасы»;

– «Кыйссаи-Йосыф» – дөнья мәдәнияте шедевры;

– «Геройлардан Ватанны сакларга өйрән»;

– «Татарстанның яшь композиторлары»;

– «Татарстан республикасының матди булмаган мирасын күрсәтү фильмы;

– Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында фильм;

– Милли мәдәниятләр елы уңаенан Татарстанның 5 районының үзенчәлеген тасвирлый торган фильм;

– Республикабыз халыклары мәдәнияте турында мультфильм;

– Гомумкешелек кыйммәтләрен пропагандалауга багышланган фильм.

Заявкалар 1-5 сентябрьдә кабул ителә. Заявка белән бергә синопсис, сценарий, кинопроектның сметасын, презентациясен һәм видеоролигын (булса) тапшыру сорала.

7 сентябрьдә XIX Казан мөселман киносы фестивале кысаларында узачак пичтингта бәйгедә катнашучылар үзләренең проектларын тәкъдим итә алыр.

Буа театры яңа биналы була

Буа дәүләт драма театрының яңа бинасын 30 августка тәмамлау бурычы куелган.

Коллективның директоры һәм сәнгать җитәкчесе Раил Садриевнең әйтүенә караганда, заман таләпләренә җавап бирерлек итеп җиһазландырылган яңа бинада кунакка килгән күп театр коллективларын кабул итеп булачак. Аерым алганда Иран, Сербия, Россиядән Якутия, Калининград, Новороссийск, Грозный, Дагыстан, Калмыкия, Красноярск театрларын кунакка чакыру күздә тотыла. Яңа бина әзер булгач та, эшне озакка сузмыйча, өй туе кебек театр фестивале үткәрү ниятләнелә.

Иске бинада исә курчак театрының эшләп китүе көтелә. Ул Мәскәүдәге Образцов исемендәге дәүләт академия курчак театры белән берлектә, аның иҗат канаты астында эшләргә тиеш. Образцов театры үткәргән лабораториядә Буа артистлары инде укып, өйрәнеп тә кайткан. Хәзер ике театр уртак лаборатория үткәрергә план кора.

«Татарстан» радиосы җиңүче

Татарстан радиосы журналисты Нәсим Акмал Дагстанда үткән «Голос Евразии» фестивалендә Рәсүл Гамзатов истәлегенә багышлап әзерләнгән тапшырулар циклы өчен гран-при алды.

Быел Дагстанның халык шагыйре Рәсүл Гамзатовның тууына 100 ел тулуга багышланган бу чара 2-5 августта Махачкала шәһәрендә үтте.

Фестиваль кысаларында журналистлар өчен осталык дәресләре үтте. Моннан тыш фестиваль кунаклары мәшһүр шагыйрьнең туган авылына барды.

Нәсим Акмал Рәсүл Гамзатовның «Минем Дагстаным» китабының беренче өлешен татарчага тәрҗемә итүче дә. Китап тиздән Татарстан Язучылар берлегенең «Язучы» нәшриятендә дөнья күрәчәк.

ВУЗда уку бәяләре

Республикада югары уку йортларында укырга кабул итү кампаниясе ахырына якынлашты. Исегезгә төшерик, быел документларны бишәр юнәлеш буенча барлыгы 5 югары уку йортына тапшырып була иде. Уку йортына укырга кергәннәр исемлеге август башында билгеле булды. Бюджет урыннарына укырга керә алмаучылар түләүле бүлектә белем ала алачак. «Республика Татарстан» газетасы белешкәнчә, быел түләүле бүлекләрдә укучылар өчен бәяләр арткан.

Шул ук вакытта Казан милли тикшеренү технология университетында (элеккеге КХТИ) «декоратив-кулланма сәнгать» бүлеге кыйммәтлеләр арасында лидерлыкка чыккан. Анда уку елына 288 600 сум тора. Хәтта медицина өлкәсендә теш табибына уку да арзанрак.

IT белгечлекләр иң алда

Быел Татарстандагы югары уку йортларында барлыгы 21102 бюджет урыны каралган, шул исәптән магистратура һәм аспирантурада да. Боларның төп өлеше Казан университетына туры килә. Әгәр дә сүз бакалавриат һәм белгечлек программалары турында бара икән, монда да 4000нән артык урын булган КФУ лидер булып тора. Аның артыннан 2543 урынлы Казан милли тикшеренү технология университеты килә. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты (КАИ) – 1641 урын, энергетика университетында – 1300. Калган югары уку йортларында бюджет урыннары күпкә кимрәк.

Быел абитуриентлар арасындагы иң популяр белгечлекләрне атау әле иртәрәк. Биредә һәр абитуриентның 25 урынга гариза бирү мөмкинлеген онытырга ярамый. Шулай да тенденцияләрне күзәтергә була. Мәгълүмати технологияләр бүлеге популяр. Безгә моның белән бәйле юнәлешләрнең популярлыгы турында әлеге белгечлекләр булган барлык югары уку йортларында да сөйләделәр.

Абитуриентлар өчен IT белгечлекләр белән беррәттән КФУдагы Халыкара мөнәсәбәтләр, шулай ук Икътисад, Идарә һәм финанс институтлары да популяр.

Казан милли тикшеренү техник университетында (КАИ) IT һәм икътисад белгечлекләреннән кала авиатөзелеш юнәлеше, ә Казан милли тикшеренү технология университетында (КХТИ) мәгълүмати технологияләр белән бергә нефтехимия өлкәсендә уку да зур кызыксыну уята.

Традицион рәвештә абитуриентлар арасында Казан медицина университеты да популяр булып кала бирә. Тик әлеге уку йортының түләүсез уку бүлегенә керү бик кыен: андагы 70% урыннар максатчан юллама һәм ташлама белән укырга керүчеләр өчен каралган.

Теш табибы булыр өчен КФУда белем алу отышлырак

Казан медицина университетындагы иң кыйммәтле юнәлешләр булып «стоматология» (248 мең сум) һәм «дәвалау эше» (245 мең сум) бүлекләре кала. «Педиатрия» бүлегендә уку елына 213 мең сумга төшәчәк. «Фармация», «медицина-профилактика эше» юнәлешләре 163 мең сум тора. Медицина университетына караганда, КФУда теш табибы белгечлегенә уку күпкә отышлырак. Анда «стоматология» һәм «дәвалау эше» бүлекләрендә уку 221,5 мең сум. КФУда иң кыйммәтлесе булып «дизайн» бүлеге кала. Бер елга уку бәясе – 265,5 мең сум.

«Менеджмент» һәм «идарә итү» – елына 174 мең сум, ә «икътисад», «юриспруденция» һәм «халыкара мөнәсәбәтләр» юнәлешләре – 190,4 мең сум, «нефть һәм газ эше» бүлегендә уку елына 194,6 мең сумга төшә.

«Фундаменталь информатика һәм мәгълүмати технологияләр», «мәгълүмати системалар һәм технологияләр», «мәгълүмати куркынычсызлык» кебек кирәкле IT-белгечлекләр быел КФУда 200 мең сумнан артып китте.

Федераль университетта иң арзан белгечлек – «яшьләр белән эшне оештыру» (126 мең сум). Республиканың төп югары уку йортында түләүле уку студентларга елына уртача 170 мең сумга төшә.

Төрле югары уку йортларында бер үк төрле юнәлешләрдә белем алу бәясе төрлечә. Мәсәлән, КФУда эколог белгечлегенә уку елына 159,1 мең сумны тәшкил итә, ә Казан аграр университетында – 100,5 мең сум. Биредә бик популяр булган «биотехнология» юнәлешендә уку 115,1 мең сум тора, ә КФУда – 171,4 мең сум. Казан аграр университетында икътисадчы булырга уку елына 106,5 мең сум.

Сәнгать акча таләп итә

Казан милли тикшеренү технология университетында (КХТИ) иң кыйммәтле булып катлаулы техник һәм иҗади юнәлешләр санала. Техник бүлекләрдән алдынгы урында «наноинженерия», «атом энергетикасы һәм җылылык физикасы» тора. Уку елына 207,6 мең сум тора. «Нефть һәм газ эше» бүлегендә уку 201,6 мең сум, ә «химик технология», «информатика» бүлекләре 165,6 мең сум тора.

Әмма аларны «декоратив-кулланма сәнгать һәм халык иҗаты» белгечлеге күпкә артта калдырган. Биредә уку елына 288,6 мең сум тора. КХТИда «дизайн», «костюм сәнгате һәм текстиль» юнәлешендә уку да шул ук дәрәҗәдә. Күрәсең, уку бәясенә модельерларны укыту өчен чыгым материаллары да керә.

Казан консерваториясендә белем алу да арзан түгел. Көндезге бүлектә барлык юнәлешләрдә дә бакалавриат һәм белгечлек алып чыгу 275,5 мең сум тора.

КАИда «транспорт радио җиһазларын техник эксплуатацияләү» белгечлеге елына 311 мең сумнан бәяләнә. Казан югары уку йортларында нәкъ менә шушы белгечлеккә уку соңгы берничә ел эчендә иң кыйммәтлеләреннән санала. «Авиатөзелеш», «очу аппаратларының двигателе», «көймә төзелеше» юнәлешләре берaз арзанрак – елына 185 мең сум, ә «математика» – 150 мең сум. Югары уку йортының матбугат хезмәтендә хәбәр итүләренчә, күпчелек техник юнәлешләрдә көндезге бүлектә уку елына уртача 148 мең сум тора, ә IT-юнәлешләрдә – 165 мең сум.

Республикада иң кыйммәтле уку – Иннополис Университетында. Биредә информатика һәм исәпләү техникасы буенча белгечләрне елына 800 мең сумга әзерлиләр. Иң яхшы абитуриентлар биредә уку өчен грант ота ала. Читтән торып та укырга мөмкин икәнлеген онытмагыз. Гадәттә, бу – 2-3 тапкырга арзанрак. Белем бирү дәрәҗәсе аңа карап кына үзгәрми. Укуда иң мөһиме: белем алу өчен теләк.

«Фән һәм мәктәп» журналыннан.
Фото «Татар-информ» архивыннан.

АЮ ТИРЕСЕН БҮЛЕШҮ...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Бер уңайдан, Киев археологы Юрий Олейникның Киев шәһәрен Кубрат хан энесе Шамбат хан нигезләгән дигән расламасын да искәртәсебез килә. Моны ул Киевнең элек Самбатос (ягъни Шамбат) дигән атамасыннан чыгып искәртә (төрки sam – югары һәм bat – көчле). Киев атамасы борынгы төрки сүзе «Кыел» – аерыл дигәннән һәм шулай ук татарча «кияү» сүзләреннән алынган дигән фаразлар да яши. Шулай ук украина-америка тарихчысы Омель ян– Прицак та топонимны төркинеке дип саный.

Хәзерге археологлар шәһәргә IX-X гасырларда гына нигез салынгандыр дисә дә, 1982 елда Политбюро махсус ЮНЕСКО өчен 482 елны ала һәм Киевнең 1500 еллык юбилеен үткәрү турында карар кабул ителә.

Безнең фикерләрне Украинада саклана гaн күп төрки топономикалар – географик атамалар да раслый. Украинаның көньяк өлешендәге төрки топономикасы буенча зур белгеч Валерий Бушаков украин телендә «Лексический состав исторической топонимии Крыма» дигән монографиясендә 1700 төрки, 200 чамасы грек, шулай ук 11 иран, 3 әрмән, 5 итальян һәм 7 кавказ лексемалары турында яза. Ул заманында озак вакытлар Аскания-Нова тыюлыгында эшләгән һәм Мариупольдә укыткан. Шулай ук В.Луценконың «Тюркский фактор в истории и этногенезе украинцев и их предков» исемле хезмәтенә дә мөрәҗәгать итәсебез килә. Анда алфавит тәртибендә төрки топонимика бирелә. Мәсәлән, «б» хәрефенә генә башланган 100 дән артык торак урынның атамасын табабыз.

Шуны да искәртик, 1944-1945 елларда, билгеле сәбәпләр аркасында Кырымда 26район үзәгенең 11 е, 327 авылның исеме үзгәртелә. 89 географик атамага да шул ук хәл яный. Тик адмирал Сергей Горшков, алар лоцияләргә (йөзү өчен кирәк булган диңгез һәм яр буйлары сурәте) кертелгән карталарда, шул исәптән чит илнекеләрдә дә, беркетелгән дип, түрәләрнең нәфесләрен чикли. Кайбер төрки-татар атамаларын язып үтик: Бакчасарай, Джанкой, Судак, Аю-даг, Сапун-гора, Балаклава, Перекоп h.б.

Укучылар игътибарына, безнең өчен кызыксыну тудырган, украиналы журналист-тарихчы Анатолий Железныйның «Мәйдан» исемле гаммәви-мәдәни газетасында басылган (Киев, №1-3, 1898) мәкаләсен тәкъдим итәсебез килә. Аны Мәскәү шәһәренең «Туган тел» исемле татар мәдәни оешмасы 2000 елда «Инсан» нәшриятында «Киев Русенең борынгы тарихы буенча очерклар» исемендә нәшер иткән. Анда, Киевнең борынгы тарихына кагылышлы күп чын мәгълүматлар, лингвистик материаллар нигезендә, Михаил Башту ибн Шамс Тебирның «Шан кызы дастаны» поэмасын файдаланып, Анатолий Железный: «... славян дәүләте Киев Русе ярымкыргый полян, древлян, северян h.б. кабиләләрдән түгел, ә биредә яшәгән, башкаласы Башту-Киоба булган Бөек Болгар (Кара Булгар), төрки телле дәүләтнең славянлашуы.... борынгы рус халкының барлыкка килүендә алар да (славяннар) һәм бүтәннәр дә (төркиләр) тигез зур роль уйнаган. Шуны ук, грамматик яктан славянча, ә сүз төзелешендә яртыча төрки булган, борынгы рус теле турында әйтеп була (Железный А., 2000, 5).

Димәк, Россиянең тулы хокуклы гражданнары булган татар, чуаш, балкар һәм бүтән кайбер төркиләрнең: «Бәхәсләшмәгез, шапырынмагыз, Кырым, Днепр тирәсендәге урман-далалар безнең ерак бабаларыбызның ватаны булган!» – дип, аяк терәп әйтергә хаклары бар.

● Изге Коръәндә барлыгы 114 сүрә һәм 6236 аять, 1 015 030 нокта, 323 670 хәреф, 77 934 сүз бар.

● Коръәндә “Аллаһ” сүзе 2707 тапкыр телгә алына: баш килештә – 980 тапкыр, иялек килешендә – 1135 тапкыр, төшем килешендә – 592 тапкыр.

● 2007 елдан 2012 елга кадәр 5 ел дәвамында Әфганстан башкаласы Кабулда хаттат Мөхәммәд Сабир Хидри һәм аның 9 шәкерте дөньяда иң зур Коръән китабын күчереп язган: аның бит үлчәме 2,3 метрга 1,5 метр, авырлыгы 500 килограмм тәшкил итә. Алтын шрифт белән язылган һәм бик матур символик бизәкләр хасил иткән миллионнарча төсле нокта белән бизәлгән китапны әзерләү ярты миллион долларга төшкән, тышлыгы 21 кәҗә тиресеннән иләнеп ясалган.

Апанай мәчетендә сөйләшү

Апанай мәдрәсәсендә «Татар телен саклап калуда һәм аның үсешендә «Иман» нәшриятының кертқән өлеше: тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән конференция узды. Ул Казанда танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, Апанай мәчетенең имам-хатыйбы Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алу чаралары кысасында үткәрелде. Диния нәзарәтенең белем бирү бүлеге җитәкчесе Вәлиулла Якупов 2012 елның 19 июлендә атып үтерелгән иде.



Энгель Таһиров.

Җәлил хәзрәт Фазлыев.

Фәнни җыенда дин әһелләре һәм татар җәмәгатьчелеге: Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, Татарстан Республикасының баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин, ТР Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды директоры Нурия Һашимова, Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров, танылган тарихчы Энгель Таһиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, күренекле шагыйрьләр Ләбиб Лерон һәм Рифат Сәлах катнашты.

Фәнни җыен барышында Вәлиулла хәзрәт Якуповның катлаулы тормыш юлы һәм ислам мәгарифе өлкәсендәге казанышлары, Апанай мәчетенең эшчәнлеге, татар телен саклау, милләтнең үткәне һәм киләчәге турында чыгышлар ясалды. Татарстан Республикасының баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевнын чыгышы бик гыйбрәтле булды:

– Милләтебезнең кимүенә 3 зур сәбәп бар: динсезлек, телне югалту, катнаш никах. Алдагы сан алуда 600 мең югалткан булсак, киләсе сан алганда 1 млн га кимибез әле. Монда башкорт та, беркем дә гаепле түгел. Әнгам Атнабаевның язган шундый сүзләре дә бар:

Син башкортмы, син татармы –
Анда түгел мәсьәлә.
Башкорттан да, татардан да
Урыс туа – вәт бәла! –
Менә кайда мәсьәлә!

Балаларыбыз телен, динен, милләтен белеп, горурланып үсәргә тиеш. Дәүләтчелекне сакларга, дибез, ләкин ул кулга корал тотып яклау гына түгел. Байлыкның да «дәүләт» дигән мәгънәсе бар. Шуңа күрә кызлар да, тел дә, галимнәребез дә, китапларыбыз да – безнең дәүләтебез, уңга-сулга, бүтән милләтләргә без ул дәүләтне таратырга тиеш түгел.

Тарих фәннәре докторы Энгель Таһиров та дистә еллар буена милләт өчен җан атучы буларак мәгълүм.

– Кем ул татар? Кайда аның тамыры? Алтын Урдасы бар икәнлеген, Болгар заманын беләбез. Безнең тарихи тумыш Кытай тирәсендә, ул вакытта Кытайның атамасы дә булмый, төрле халыкларга бүленеп яшиләр алар. Алар утрак тормыш алып баручы халык булса, без – күчмә, сугышчан халык булабыз. Безнең каныбызда империя каны бар, без шундый канлы булмасак, безне күптән таптап киткән булырлар иде.

Татар халкының тарихы бик бай, без аны белеп кенә бетермибез. 3 мең ел дибез дә, шуның белән канәгатьләнәбез. Дөресен генә әйткәндә, безнең тарих 5 мең елга тарта. 3 меңме, 5 меңме... Анысы кемне ничек кузгата инде, алай ук мөһим түгел. Ләкин аның эчтәлеге, нинди юл салуы мөһим. Татар – Тын океаннан алып Атлантик океанга кадәр юл үткән, бүтән халыкларны да үстергән халык ул.

Хәзер татарның саны кими, дибез. Монысы да мөһим, киметмәскә тырышырга кирәк, ләкин мөһимрәк мәсьәлә – ул татарның сыйфаты. 1 миллионга кимегән икән, ә калганы нинди? Үрнәкме соң? Татар халкының сакланып калуында кешеләр, дәүләтләр арасында күпер сала белү, уртак тел таба алуы мөһим.

Татар телен сакларга кирәк, дигән мәсьәләне хәзер бик каты күтәрәбез. Мәктәпләрдә, университетларда, урамда русча сөйләшкән заманда телне саклый торган фактор нәрсәдә? Дөнья күләмендә таралган иң беренче тел – латин теле, аны инглиз теле җиңә, ә хәзер инглиз телен кытай теле басып килә. Кытай халкының безнең белән чагыштырганда күп әйберләре азрак яки бөтенләй юк, ләкин ул үсә һәм беренче дәүләт булып килә. Ә дәүләт артыннан тел бара. Телне үзеннән-үзе саклап калып булмый, аңарга энергия, көч бирү өчен, аның үрнәк булуын күрсәтү мөһим. Кытай менә шундый үрнәк күрсәтә һәм шуңа күрә алга бара.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла сүзләре дә бәгырьгә үтәрлек:

– Безнең халык үз тарихыннан бик җаһил, без үз тарихыбызны белмибез һәм кызыксынмыйбыз. Белмәү – ул гаеп түгел, ә кызыксынмау – гаеп. Белмәү, наданлык аркасында төрле фантазияләр үсеп чыга. Тарих белән әз генә кызыксына башлаган кешеләр «Безнең халкыбыз, тарихыбыз бөек булган, фәлән дә төгән» дип кычкырырга ярата, ләкин бу, минемчә, халыкның уяулыгын югалтуга китерә. Әлбәттә, безнең тарих бөек. Әгәр дә шәҗәрәне Таҗетдин Ялчыгол, Нух пәйгамбәрләргә китереп тоташтырсак, анда бөек шәхесләр бик күп. Әфләтүн (Платон) дә шәҗәрәгә кереп утыра. Ул чакларда, әлбәттә, горурланырга мөмкинлекләр күп. Ләкин бөек халыкның үз дәүләтчелеге була. Дәүләтчелек безнең бар, ләкин, дөресен әйтергә кирәк, горурланып йөри торган дәүләт түгел бу. Ниндидер зур дәүләт булган кебек кыяфәт чыгарып йөрү – үз-үзебезне алдау гына. Безнең дәүләт югалган.

Безнең бабаларыбызның ялгышы безне һаман чабудан тотып тора. Без кайда ялгышканбыз? Ул ялгышның нинди сәбәпләре булган? Шуны аңларга кирәк. Безнең шундый хәлгә калуның сәбәпле бик ерак 500-400 елларга ук килеп тоташа, Казан ханлыгы таркалган чорга. Бездә бердәмлек булмаган, һәм ул әле дә юк. Без бер-беребезгә адым ясарга кыенсынабыз, тәкәбберлек көчле.

Мәсәлән, тарихка кереп китәбез икән, рус халык авыз иҗатында, әкиятләрендә патша эзләп йөриләр, иң соңгы чиктә «Иван-дурачокны» мич башыннан алып, тәхеткә утырталар. Татар әкиятләрендә ничек? Патшаны үтерәләр дә, дәгъвачылар килеп чыга, аның кызын алалар һәм тәхет өчен көрәш башлана. Әкиятләр халык тормышның хакыйкатен чагылдырган. Димәк, бездә бер лидерга буйсыну урынына, һәркем үзе юлбашчы булырга тырыша. Ләкин, тарих күрсәткәнчә, юлбашчылар күп була алмый.

Татар теле мәсьәләсенә килгәндә, хәзер мәчетләрдә вәгазьләрне татар телендә укырга тырышалар, әммә шулай да татар телен белмәүчеләргә: үзбәкләр, таҗиклар, кыргызлар һәм башкаларга вәгазьне рус телендә сөйлиләр. Үзбәкләр, кыргызлар татарча аңлый бит. Ә таҗиклар – юк... Әгәр дә без Таҗикстанда мәчеткә керсәк, безгә татарча сөйли башлаячакларммы? Беркайчан да сөйләмәячәкләр. Вәгазь сөйләгәндә Коръәннән дә әзекләр китерелә бит, шуңа йә аңлаганы белән канәгатьләнсен, йә татар телен өйрәнсен. Без үз телебезне үзебез хөрмәт итәргә, мөккибән булырга тиешбез, без хөрмәт итмәсәк, телебезне кем хөрмәт итсен?! Тел – ул халык дигән сүз. Теле барның иле бар. Телең юк икән, син башка халыклар арасында эреп югаласың, һәм ул халыклар өчен «тиреска» әйләнәсең…

Конференция барышында ул көнне дин әһелләре дә, шагыйрьләр дә байтак чыгыш ясады.

Камилә БИЛАЛОВА.
Абдул Фархан фотолары.
intertat.tatar.

Атнаның сәяси мизгелләре

Мәнфәгатьләр кисешкән җирдә

Глобаль каршылыклар кискенләшкән чорда мәнфәгатьләр хәтта Нигерда да кисешә. Көнбатыш Африкада урнашкан бу илдә вәзгыять 26-27 июльдә, нәкъ Санкт-Петербургта икенче Россия-Африка саммиты барган көннәрдә кискенләшкән иде. Ул көнне анда хәрби түнтәрелеш нәтиҗәсендә, президент Мөхәммәт Базум хакимияттән читләштерелеп, кулга алынуы һәм аның урынына илнең яңа лидеры итеп генерал Габдерахман Тчиани билгеләнүе турында игълан ителде. Урамнарда фетнәчеләрнең Россия флагларын күтәрүләре дә әйтелде. Башта Мәскәү дә, Вашингтон да бу илдә кылынган түнтәрелешне гаепләп чыкты. Соңгысы хәтта Нигерга күрсәтелә торган финанс ярдәменең киләчәге президентның ирекккә чыгарылуына һәм демократик идарәнең торгызылуына бәйле булачагы турында да кисәтте. Конституцион тәртип торгызылуын фетнәчеләрдән БМО КШ да таләп итте. Бу илгә бюджет ярдәмен туктатуы һәм аннан үз граждannарын чыгаруы турында шулай ук ЕС игълан итте. Мәскәү исә Нигерга карата көч куллану андагы вәзгыятьне җайга салуга хезмәт итмәячәге турында белдерде һәм каршы торучы якларны милли диалогка чакырды.

Ә хакимияттән читләштерелгән һәм кулга алынган Нигер президенты М.Базум үзенең 3 августта The Washington Post газетасында чыккан мәкаләсендә Кушма Штатларга һәм дөнья җәмәгатьчелегенә илдә конституцион тәртипне, закон өстенлеген һәм демократияне торгызуда ярдәм күрсәтү үтенече белән мөрәҗәгать иткән. Ул анда, дәүләт түнтәрелеше оештыручыларның ачыктан-ачык чакыруы буенча, Нигер гына түгел, ә Сахеля төбәге үзе дә, «Вагнер» төркеме ярдәме белән, Россия йогынтысына күчәргә мөмкин, дип яза. Ә фетнәчеләр ул арада элеккеге финанс министрын Нигерның яңа премьер-министры итеп билгеләгән. Бу атнада инде фетнә лидерлары белән АКШ дәүләт секретаренең сәяси мәсьәләләр буенча урынбасары Виктория Нуланд та очрашып сөйләшкән. Ике сәгать дәвамында алар илдәге кризисның дипломатик чишелешен эзләгән. Әммә аңа кулга алынган президент белән очрашу мөмкинлеге бирелмәгән. Мәскәүдә исә моны, Нуланд Нигерны, Украина кебек, төп башына утыртa алмады, дип бәяләгәннәр. Ә бу анда Франция йогынтысы да кимүен аңлата.

Сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. В.Путин призыв яшен күтәрү турындагы законны имзалаган. АКШ белән Украина арасында соңгысының иминлек гарантиясен булдыру турында сөйләшүләр башланган. Мәскәү шәһәр суды, А.Навальныйны экстремистик эшчәнлектә гаепләп, махсус режимлы колониядә тоту шарты белән, 19 елга иреgennән мәхрүм иткән. РФ саклану министры С.Шойгу МХО зонасында алдагы идарә пунктын тикшергән. РФ Иминлек шурасы рәисе урынбасары Д.Медведев, Россиягә каршы бөтен НАТО системасы ачыктан-ачык сугыша, дип белдергән. В.Путин «Ростех»ка «Ланцет» дроннарын җитештерүне арттыру бурычын йөкләгән.

Фоат УРАЗАЙ.

Солдат шинелен - журналист каләменә

Кешене гомер еллары түгел, хезмәт нәтиҗәләре бизи, диләр. Бу сүзләр Түбән Камада яшәүче Виктор Шадринга карата әйтелгән кебек. Питрау җитәргә бер көн кала туган Виктор Борисовичка 70 яшь тулды. Түбән Кама районы Сабантуйларында һәм Питрау җыеннарында спорт комментаторы эшчәнлегенә – 40 ел. Журналистлык хезмәтенә дә декабрьдә 50 ел тула икән.

Балтач район мәктәбенең рус классын тәмамлаган Викторга Казан университетының тарих факультетына керү өчен немец телен житәрлек дәрәҗәдә белмәве комачаулый. Кәефен төшерми ул, авылга кайтып, колхозда эшли башлый. Урып-җыю чорында комбайнчы булган Виктор үзе армиягә киткәч тә, өйләрәнә колхоздан икмәк китереп бушаталар. Укытучы булып эшләгән Наталия Васильевна белән почта башлыгы Борис Владимирович моны күргәч, хәтта уңайсызланып та кала.

Виктор стратегик максаттагы ракета гаскәрләрендә радиотелеграфист булып ике ел хезмәт итә. Берчак аңа, грипп белән ауган хезмәттәше урынына, ике атна буе морзе телендәге радиограммаларны тотучы «колакчын»нарны салмыйча, дивизиянең команда пунктында дежур торырга да туры килә.

Сроклы хәрби хезмәттән декабрь башында кайткач, университетка керү имтиханнары җиткәнче дип, район газетасына фотограф булып урнашырга тели. Газета редакторы, өстеннән хәрби киемен салырга да өлгермәгән егет белән сөйләшкәч, аңа корреспондент эше тәкъдим итә. Виктор ризалаша. Көннәр буе район авылларында йөреп кайткан егет, төннәр буе сүзлекләр актара-актара, татарча мәкаләләр яза башлый, хәтта чираттагы ялга киткән җаваплы сәркатипне дә алмаштыра. Типографиядәге тәҗрибәле верстальщикның катгый таләбе – Виктордан кала бер җаваплы секретарь белән дә эшләмәячәген белдерүе аркасында, аңа бу вазифаны да йөклиләр...

Вакытлыча гына фотограф эше эзләп килгән егет, шулай итеп, хезмәт юлының редакция белән бәйләнгәнен сизми дә кала. Университетның рус журналистикасы бүлеген читтән торып тәмамлаган Виктор Шадрин гомер буе татар газетасында эшли. Үзе армиядә хезмәт итеп кайткан булгач, хәрби частьлардан килгән хатларга бик тә игътибарлы була. Шундый бер хатта Балтач районыннан килгән бер егетнең хәрби частьта бик яхшы хезмәт итүе турында язылган була. Профессионалларча оста язылган хатны Виктор Шадрин Балтач районы газетасының «Патриот» сәхифәсенә урнаштыра. Ә ул хатны физик яктан иң хәзерлекле егетләрне генә җыя торган элита гаскәрендә хезмәт итүче Вахит Имамов (хәзерге вакытта «Мәдәни җомга»ның баш редакторы) язган була...

Халкының күпчелеге татарлар һәм удмуртлар булган Балтач районыннан Түбән Камага күчеп килгәч, Виктор Шадринга үз карендәшләре белән ныклап аралашу мөмкинлеге туа. Дөрес, ул дубляж газетасы «Ленин нурлары»на редактор булып килгән 1983 елда (аннан соң да) Түбән Кама рус теле өстенлек иткән шәһәр иде. Бу яшь каланы төзүчеләрнең бөтен союздан җыелуы да, шин заводы, нефтехимия берләшмәләренең шунда урнашуына да бәйле булгандыр. Шул ук вакытта, яңа шәһәргә үз нигезләрен бирергә мәҗбүр булган Чәбия, Актүбә авыллары керәшеннәре дә әллә кая китми, күпчелеге туган җирендә кала.

Дубляж газетасының беренче редакторы, керәшен Николай Кузнецов янына килеп йөргән каләм тибрәтүчеләр, мәдәният һәм мәгариф хезмәткәрләре, төзелештә эшләүчеләр өчен дә яңа редактор Шадринның керәшен егете булуы үз ролен үти. Теләсә кем белән уртак тел табучы, кешене сәгатьләр буе бүлдермичә тыңлый белүче яшь редактор үз керәшеннәренә аеруча игътибарлы мөнәсәбәттә була. Шуңа да, уйсу җиргә су җыелгандай, керәшеннәр аның тирәсенә елыша. Туксанына якынлашкан Тимофей дәдәй Французовка кадәр, юк йомышын бар итеп, көн дә диярлек редакциягә сугылып китә.

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсенә йөрүчеләр, шул исәптән Никифор Тукмачев; техникум директоры Василий Игнатьев, укытучылар Петр Ибаев, Климентий Кузьмин, Ефимья Хәбирова, Анна Бутяева аның янына еш килә. Олы Атыдан чиркәү яңартучы Павел дәдәй Умнов, Чәбиядән ташчы Вера Боярова, Актүбә почтальоны Ольга Шадрина шикелле, керәшеннәрне борчыган проблемаларны хәл итүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр дә аз булмый. Нәтиҗәдә, җирле татар газетасы район керәшеннәренең рухи бер үзәгенә әверелә. Виктор Борисович үзе 26 ел дәвамында редакторы булган «Туган як» газетасы, гомумән, рус шәһәре Түбән Камадагы татар халкының гаделлек трибунасына әйләнде. Беркемнән дә курыкмаучы Шадрин газетасында гади эш кешесе мәнфәгатен яклаган, чынбарлыкны дөрес яктырткан һәм химия сөремле шәһәр проблемаларын күтәргән мәкаләләрне үз эченә алган рус кушымтасы да бирүне сорап, руслар да аз килмәде. Бу хәл Шадрин редакторлык эшен «Шинник» спорт комплексында матбугат хезмәте җитәкчесе вазифасына алмаштырганчы дәвам итте...

Болар барысы да редакторның, балачагы татарлар арасында үтсә дә, гаиләдәге тәрбиясеннән килә. Үзе әйтмешли, папасы белән әнисенең җәйге ялларында үз туган авыллары Колышчы Сабантуйларына кайтулары эзсез узмый. Колышчы керәшеннәренең көйләбрәк сөйләшүләре, төп йортта табындагыларның кара-каршы җырлашулары, өйләрдәге бистәрләр, киндер өстәл япмалары, үзе туган Әтнәдәге һәм малай чагыннан бирле яшәгән Балтачтагы кешеләр киеменнән аерылып торган өс-башлары, пешерелә торган ризык – берсе дә Викторның игътибарыннан читтә калмый. Әнисе шикелле үк көйгә оста малай, үзе ишеткән җыруларны үзалдына гына кабатларга да ярата.

Үзлегеннән фотога төшерергә өйрәнгән улларына өйдәгеләре «Смена-4» фотоаппараты сатып ала. 1968 елда, беренче мәртәбә, Колышчы Сабантуенда үзенә ошаган ярышларны фотога төшерә. Вакыт үз төсен салган фотоларны әле дә саклый ул.

Редакциядә эшләгән елларыннан башлап, үз керәшеннәре турында республика газеталарында чыккан язмаларны җыеп бара. Түбән Камада үзе редакторы булган җирле газетада Чәбия, Актүбә кебек керәшен авыллары кешеләренә, аларның тарихи фотоларына һәрчак урын таба. Республикада беренчеләрдән булып, татар газетасында ай саен махсус «Карендәш» бите биреп бару идеясе дә аның үзенеке. Редакциядән Шадрин киткәнче, «Карендәш»тә район керәшен авыллары тарихына багышланган язмалар еш чыкты. Чиркәү-керәшен телендә үгетләр дә урнаштырылды.

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, керәшеннәргә, аларның культурасына олы хөрмәт белән караган Рахмай Хисмәтуллин белән бергәләп, әле 1986 елда ук керәшен халык иҗатына багышланган кичә, аннан соң «Җидегән чишмә» кичәсендә Галина Сабирова, Терентий Трофимов кебек җирле керәшен җырчыларының концертларын оештырганын, шулай итеп, сәхнәгә керәшен җырулары чыга башлаганын да әйтергә кирәктер. Чөнки ул кичәләр, тамашачы соравы буенча, берничә көн рәттән кабатлап күрсәтелде. Әлбәттә, керәшен җырулы «Җидегән чишмә» кичәләрен алып баручыларның берсе Шадрин үзе иде...

Дикторларга хас тавышлы, ике телдә дә бердәй оста сөйләүче Виктор Шадрин – Түбән Камадагы беренче елларыннан ук, район Сабантуйларының алыштыргысыз спорт комментаторы. Керәшен егете Викторның Сабантуй мәйданын яңгыраткан көчле тавышын ишеткәч, Татарстан Президенты М.Шәймиевнең «бу егетне югалтмагыз», дигән сүзләрен күпләр хәтерлидер. Ә Виктор Борисовичның Түбән Кама районы Сабантуенда спорт комментаторы булуына быел 40 ел тулды. Бу милли бәйрәмдә акчага җырлап йөрүче сәхнә йолдызларыннан аермалы буларак, үзенең керәшен тыйнаклыгы белән, хезмәте өчен бернинди түләү дә сорамыйча 4 дистә ел дәвамында халыкка бушлай хезмәт итә ул.

Россия күләмендә оештырыла торган Федераль Сабантуйларда (Петербургтан башлап Владивостокка кадәр) дистә елдан артык көрәшне татарча һәм русча алып баручы да Шадрин булды. Шулай ук, Түбән Каманың атаклы баһадиры Данил Галиев истәлегенә республикада оештырыла торган көрәш турнирлары да Виктор Борисовичтан башка узмый. Болардан тыш, спортның билбаулы көрәш төре комментаторы, 2 нче категорияле судья В.Шадрин барлык төр ярышларның гадел хөкем ителүенә бар көчен куя...

Түбән Камада яши башлаганнан бирле ул әле районның керәшен авылларындагы Питрау җыеннарында, башка бәйрәмнәрдә дә спорт комментаторы вазифасын үти, моны ул күңеле кушкан эшкә саный. Җәмгыять җитәкчесе Тамара Алексеевнага һәрьяклы ярдәм күрсәтүе, аңа терәк булуны да үз намус эшенә исәпли. Чөнки ул – Түбән Камада керәшен җәмгыяте оештыруның башында торган кешеләрнең берсе. Ул керәшенләренә кулыннан килгәнчә файда китерергә омтыла. Түбән Кама ягының танылган керәшеннәрен барлап, алар турында язмалар әзерләп вакытлы матбугат битләренә чыгара. Киләчәктә район керәшен авыллары турында китап чыгару максатыннан, аларның тарихларын барлау буенча материаллар туплауны дәвам итә.

Китап язуда аның шактый саллы тәҗрибәсе дә бар. Татар һәм рус телендә Виктор Шадринның «Түбән Кама көрәшчеләре» (2003 ел), «На службе спорту» (2017), «Данил батыр» (2018), «Посвящается «шинному генералу» (2019), «Гасырлар кичкән Колышчы» (2020), «Мягкое золото» Мамадышской земли» (2022) китаплары дөнья күрде.

Вакытлы матбугатны үстерүдәге хезмәте өчен, 1995 елда В.Шадрин «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек булды. Ул – «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале (2005), «Фидакарь хезмәт өчен» медале (2013) иясе. 2010 елда «Бәллүр каләм» конкурсының «Имя в журналистике» номинациясендә җиңүче буларак та танылды.

Фирая МОРАТОВА.

Казан капкалары ачык – Ачып куйдык үзебез!..

(Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинның туууына 75 ел)

Роберт МИҢНУЛЛИН

УТЫЗ ИМӘНИНЕ УКЫГАНДА ТУГАН УЙЛАР

Укыйм Утыз Имәнине –
Аңлый алмыйм сүзлексез.
Аңлашылырга тиеш бит –
Була алмый сүз үксез.

Ник болай булган соң әле –
Безме, сүзме үзгәргән?
Тарихларга китеп барам
Сүзләрдәге эзләрдән.

Тарихыбыз – чытырманлык,
Нинди киртә арада?
Аңлашылмаучылыклардан,
Тарих, зинһар, арала!

Күпме сүз ят безгә хәзер.
Китәм кайчак имәнеп –
Тарихның төпкелләрендә
Калган сүзләр имгәнеп.

Яңгырый сүз, булса гына
Халыкның ул телендә.
Ятка әйләнә сүзләр дә,
Ятса тарих төбендә.

Үзебезнең бабайларның
Аңлама инде телен –
Шушы да булдымы безнең
Югары дигән белем?

Утыз Имәни дә әгәр
Укыса үзе безне,
Аңламас иде, мөгаен,
Безнең бер сүзебезне...

Нәрсәләр булды соң сиңа,
И телем, и тел генәм?!
Утыз Имәни бездән соң
Аңлашыр соң кем белән?

ТАТАР

Татар белән изгән Рәсәй,
Татар белән баскан.
Татардан башка булалмый, –
Татар баштан ашкан!

Татар күчмә кошлар кебек –
Ул туктаусыз күчә.
Утлар-сулар кичә татар,
Шахталарга төшә.

Тату булып яши белә
Татар барсы белән:
Үрчетә чит милләтләрне
Татар башы белән!

Күпме милләт карап тора
Татар күзе белән,
Күпме милләт балкып тора
Татар йөзе белән!

Күпме милләт яшәп ята
Татар каны белән,
Үзе – үзбәк, урыс, башкорт...
Татар – җаны белән.

Татарларны үлчи алмый
Бернинди дә бизмән...
Татар белән баскан Рәсәй,
Татар белән изгән!

БЕЗНЕҢ ЖАКНЫҢ ТЕЛЕ

Безнең жакта жомшак сүләшәләр,
Көлеп тора безнең жак теле –
Безнең жакның жанлы, тере теле,
Башка жаклар өчен жат теле.

Безнең жакның теле матур ул әй,
Үзе житди, үзе жор кебек.
Сүләшепләр генә туеп булмай,
Безнең жакның теле жыр кебек.

Жырларыбызны да шушы телдә
Сиптерәсе безгә, сибәсе.
Башкорт аны, башкорт шивәсе, ди,
Татар өчен – татар шивәсе.

Моның бер дә аптырарлыгы юк,
Матур телгә хужа табыла.
Чөнки ул бит чишмә булып жырлай,
Сөнкәебез булып агыла.

Безнең телдән кемдер көлә икән,
Колагыма да мин элмәем.
Аның кебек татлы, якты телне,
Якын телне башка белмәем.

Гомер буе шулай сүләштем мин,
Рәхәтләнеп шулай сүләем.
Шушы телем белән туганмын мин,
Шушы телем белән үләем!

КАЯ ЮГАЛДЫГЫЗ, ТАТАРЛАРЫМ?!

2002 елгы җанисәптән соң юкка чыккан 200 меңнән артык Башкортстан татарына мәрсия

Кая булдыгыз сез, татарларым?
Әллә сезне утка тыктыларны?
Әллә инде суга салдыларны,
Йә булмаса, тупка тоттыларны?

Кая югалдыгыз, татарларым? –
Кичә генә әле бар идегез,
Бар идегез, татар идегез бит,
Татарларыбызга пар идегез!

Кая булдыгыз сез, татарларым? –
Хөкемнәргә сезне тарттылармы?
Астылармы сезне, аттылармы?
Төрмәләргә әллә яптылармы?

Килмешәкләр диеп сөрделәрме,
Башка юлын әллә таптыламы?
Әллә инде башка бер халыкка
Коллар итеп сезне саттылармы?

Әллә инде үз-үзегезне сез
Жиңел генә шулай саттыгызмы?
Әби-бабайларның әманәтен
Чүплекләргә тотып аттыгызмы?

Әллә инде милләтегезне сез
Бер яртыга сатып эчтегезме?
Нәрсә булды сезгә, милләттәшләр? –
Шушы көнгә килеп төштегезме?

Ә башкалар әнә үрчи тора, –
Татарларны әллә печтеләрме?
Ник дәшмисез, нигә эндәшмисез –
Телегезне әллә кистеләрме?..

Мин беркемне гаепләмим монда,
Мин бит бары авыр сулыйм гына.
«Кая югалдыгыз, татарлар?» – дип
Мин бит сездән бары сорыйм гына...

Кая булдыгыз сез, татарларым?
Сез кайларга китеп югалдыгыз?
Канлы гасырлардан исән чыгып,
Ничек кенә болай булалдыгыз?

Ишетелә кебек еракллардан
Зарларыгыз сезнең, аһларыгыз...
Яу кырында ничек сирәгәйсә,
Сирәгәя шулай сафларыгыз.

«Каравыл!» дип, бөтен дөньясына
Нигә әле оран салмадыгыз?
Ниләр эшләр менә киләчәктә
Бу афәттән исән калганыгыз?..

Ниләр булды сезгә, татарларым? –
Ни дисәң дә, сезгә сүз юк инде.
Жиңел булсын авыр туфрагыгыз! –
Татар өчен хәзер сез юк инде...

Яңа гасырлардан эзләр әле
Улларыгыз сезне, оныгыгыз!..
Йә, хушыгыз! Йә, бер дога кылыйк!
Жәннәтләрдә булсын урыныгыз!

КАЗАН КАПКАЛАРЫ АЧЫК

Казанымның капкалары
Ачып-ачып куелган.
Ул капкалар алтыннан да,
Көмештән дә коелган...

Казанымны заманында
Бер кат алдылар инде.
Бер кат утта яндырдылар,
Суга салдылар инде.

Бәреп керделәр илемә
Казан капкаларыннан...
Күп гасырларны кичеп без
Чыктык кап-караңгыдан.

Дөнья безне суккалады,
Сукты да каккалады.
Ә хәзер киереп ачылган
Казанның капкалары.

Казан капкалары ачык
Күңеле ачыкларга,
Ачык кунакларыбызга,
Дусларга, гашыйкларга.

Ачык безнең күңелебез,
Якты безнең йөзебез.
Казан капкалары ачык –
Ачып куйдык үзебез!

КЕБЕК...

Мин барсын да аңлыйм кебек.
Аңламыймын да кебек.
Мин сезне бер дә алдамыйм...
Алдалыймын да кебек.

Сугыш яралары үткән...
Үзе үтмәгән кебек.
Илдә сугыш беткән кебек...
Үзе бетмәгән кебек.

Солдат улларыбыз үлә...
Үлмәгәннәр дә кебек.
Шуны бар да белеп тора...
Белмәгәннәр дә кебек.

Болар бар да дәрес безгә...
Дәрес тә түгел кебек.
Мин дөресен язам кебек...
Дөрес тә түгел кебек.

Дәүләтебез бар да кебек...
Нигәдер юк та кебек.
Эшләребез хутта кебек...
Без ач та, тук та кебек.

Телебезнең хәле яман...
Яман да түгел кебек.

Гәзит, экран тулы ялган...
Ялган да түгел кебек.

Бу илдә бер тәртип тә юк...
Чүт-чүт тәртип тә кебек.
Бу шигырем тәнкыйть түгел...
Чүт-чүт тәнкыйть тә кебек.

КҮҢЕЛЛӘРДӘ...

Бу татарда акыл төштән соң шул,
Килә безгә акыл соң гына:
Азатлыкны шаулап, яулап алдык,
Кайтарабыз кире шым гына.

Тын гына да, шым гына да түгел,
Кайтарабыз астыртын гына.
Күңелләрдә хәзер берни дә юк,
Күңелләрдә хәзер шом гына.

Элеккегә кайтып барышыбыз
Сиздермичә генә, тын гына.
Күңелләрдә ачы моң гына шул...
Күңел сыкрый акыртын гына.

ҮЗГӘРҮЕН ҮЗГӘРДЕК

Безне хәзер тыеп булмый
Авызлык белән генә.
Буйсындырып булмый безне
Явызлык белән генә.

Жиңеп булмый безне терсәк
Йә беләк белән генә.
Жиңеп була безне хәзер
Ак теләк белән генә.

Безне яулап алып була
Мәхәббәт белән генә.
Теләктәшлек, дуслык белән,
Мәрхәмәт белән генә!

Заман үзгә, Казан үзгә,
Үзебез дә үзгәрдек...
Тезләндек без, ләкин торып
Басар өчен тезләндек!

Ә моннан соң, белмим әле,
Түзәрбезме төзләнми?!
Без күптән үзгәрдек инде...
Мәскәү генә үзгәрми.

Мәдәни җомга
11 август
№31, 2023

Дәрдемәнд даирәсендәге

(Дәвамы. Башы 30 нчы санда).

Фатих Кәрими белән бер үк елларда Чистайдагы Закир ишан хәзрәтләре мәдрәсәсендә белем алган Галиәсгар Гафуров-Чыгатай да шәриктәшеннән калышмаска тырышкандыр. Ике гасыр аралыгында матбугатта аның исеме дә еш телгә алыначак. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң берникадәр вакыт Бозаулык шәһәре мулласы булып торган елларында ул «Тәрҗеман» газетасында хатын-кызлар хокукына кагылышлы мәкаләләр дә бастыра. Шуннан соң аның ике өлештән торган «Тутам, яхуд Яшь гомерем» повестенең 1нче өлеше 1902 елда Оренбургта Кәримов ахун басмаханәсендә дөнья күрәчәк. Бу авторның Бозаулык шәһәрендә мәчет имамы булып торган дәвердә – 1898 елда җәдиди ысулда укытуга керешкән укытучылар өчен махсус курслар оештыруын да искә алырга кирәк. Дөрес, ул курсларны оештыру яңа төр мәктәпләр ачуга күп көч түккән һәм күп акча тоткан Гани бай Хөсәенов белән берлектә башкарыла. Галиәсгарның шәриктәше Фатих Кәриминең шул ук елларда Татар Каргалысы бистәсендә шул ук Хөсәенов Гани бай ярдәме белән уздырылган андый курсларны галимнәребез еш телгә ала. Ә Галиәсгар Гафуровның шундый ук эшчәнлеге исәпкә алынмый. Моның төп сәбәбе, мөгаен, Чыгатайның ул дәвердә мулла булуына бәйледер. Совет хакимияте елларында муллаларның андый эшчәнлеге дә бик сирәк искә алынды ич... Бозаулык каласының Оренбургтан ерак булмавын, Галиәсгар Гафуровның шәриктәше Фатих Кәрими, шәһәрдәше Ярулла Вәли һәм бертуган Хөсәеновлар белән даими рәвештә аралашып торганлыгын искә алсак, аны да Оренбург төбәге зыялылары төркеменә кертергә хаклыбыз. Фатих Кәрими шул гасыр башында нәшер ителгән бер хезмәтендә шәриктәшенең эшчәнлеген югары бәяли. «Мулла буларак ул җәмиг мәчет карамагындагы мәктәптә яшьләрне заманча тәрбияләүгә зур әһәмият бирә. Әдәбият җәһәтеннән дә Галиәсгар әфәнденең тәкъдир итәрлек... бер кач әсәрләре бардыр. (Аларның) басылып таралулары бик матлубтыр (сораладыр)», дип яза ул.

Г.Гафуровның икенче дус каләмдәше Ярулла Вәлиевнең дә башлангыч иҗат чоры шушы Бозаулык шәһәренә бәйле. «Ярулла әфәнденең «Мәңгелек мәсҗед», «Күз яше» исемләрендә язылып таралмыш булган ике рисаләсе (әсәре)... бик ачык вә хуш лисан (тел) белән язылмыштыр», дип бәяли каләмдәшенең тәүге чор әсәрләрен Ф.Кәрими 1903 елда язылган бер хезмәтендә.

Әдәбият галимнәре язучы Ярулла Вәлине 1990 нчы елларгача шушы Бозаулык шәһәре сәүдәгәре буларак кына белдерде. Чынлап та ул шушы төбәкнең уртакул сәүдәгәрләре чутында йөргән. Әмма «Дәрдемәнд» альбомын әзерләү дәверендә табылган документларда аның Буа шәһәре янәшәсендәге Рангун авылыннан булганлыгы ачыкланды. Чыгтай тәхәллүсе белән әсәрләрен бастырган Галиәскәр мулла белән Ярулла 1906 елгача якыннан аралашып бер шәһәрдә яшәгән. Икесенең дә беренче иҗат үрнәкләре Фатих Кәрими атасы ачкан басмаханәдә, чордашлары каләме аша үтеп нәшер ителгән. Ә Рәмиевләр нәшер итәргә ниятләгән «Вакыт» газетасы мөхәррире итеп билгеләнгәч, Фатих Кәрими тиз арада өметле әдип буларак кабул иткән чордашы Ярулланы да Оренбургка чакырып китерә. Һәм бертуган Рәмиевләр белән килешеп, Ярулланы «Вакыт» газетасына хуҗалык һәм финанс эшләре өчен җаваплы кеше итеп билгелиләр. Ярулла үзенә йөкләнгән бурычны бик уңышлы дәвам итеп, киләчәктә тагын да дәрәҗәлерәк үрләрне яулаячак. Бераздан соң ул Рәмиевләрнең чит ил җиһазлары белән тәэмин ителгән »Вакыт» басмаханәсен оештыруда актив катнашып, аның мөдире итеп билгеләнәчәк. Бу шәхеснең иҗаты турында сүз алдарак булыр.

● Галиәскәр Гафуров – Чыгтай.

● Шәриф Камал.

Бертуган Рәмиевләр «Вакыт» газетасын чыгару хәстәренә 1905 елның көзендә, приискалардагы сезонлы эшләрне тәмамлап кайткач керешәләр. Әмма газетаны сыйфатлы итеп чыгарырдай кешеләрне сайлау һәм оештыру эшләре ике-өч айга сузыла. Өч-дүрт ел элек кенә Шакир Рәмиевнең тәрҗемәчесе рәвешендә Европа илләре буйлап бергә сәяхәттә йөреп кайткан Фатих Кәрими дә бу эшкә тиз генә керешә алмый. Башка хезмәткәрләрне, шул исәптән аның урынбасарын сайлау да аңа йөкләнгән була. Ул чорда әле Оренбургта андый эшне башкарырдай кешеләр булмый. Ул төбәктәге шул чор тарихын ярыйсы ук өйрәнгән Мәдинә Рәхимкулова: «Фатих Кәрими Галиәсгар Гафуровка да тәкъдим ясаган булган. Ләкин ул башлаган эшемне ташлап китә алмыйм, дип җавап биргән», дигән иде. Шуннан соң бу вазифаны башкарырдай белемле, тәҗрибәле кеше буларак Ризаэддин Фәхретдиновны чакыру фикеренә киләләр. Ә көндәлек эшне – гадәти редактор (ул заманда әйтелгәнчә – корректор) вазифасын башкарырга Габдулла Тукай да чакырылган була, дигән хәбәрләр дә бар. Әмма аның яңарак килеп урнашкан Казаныннан китәсе килмәгән. Озакламыйча Оренбургка корректор эшен башкарырга дип Шәриф Камал чакырып китерелә. Башкаладагы «Нур» газетасында эшләп берникадәр тәҗрибә туплаган һәм шунда ук тәүге әсәрләре күренә башлаган Ш.Камалның Оренбургка кайчан килеп төпләнүе әлегә архив документлары белән расланмаган. Кайберәүләр аны »Шура» журналына «Уяну» хикәясен җибәргәч, ул хикәя Рәмиевләргә бик ошагач чакырылган, дип яза. Хикәя 1909 елда басылып чыга. 1964 елда Оренбургта бер очрашу вакытында язучы Шакир Мөхәммәдовның кияве Тәүфыйкъ ага Сабитов: «Ул хикәя монда килгәч язылмадымы икән?» – дип тә әйткән иде. Ш.Камалга чаклы «Вакыт» газетасында корректор эшен кемнең башкарганлыгы ачыкланмаган.

Ш.Камалның Оренбургта яшәгәндә иҗат ителгән күпчелек әсәрләре әүвәл «Шура»да басылып чыккан, аннары Рәмиевләр хисабына «Вакыт» нәшриятында китап рәвешендә нәшер ителгән, дип әйткән иде Тәүфыйкъ ага. Аның исә Рәмиевләр ачкан «Вакыт» типографиясе белән бәйләнеше барлыгын миңа Оренбург кешеләре сөйләгән иде инде. Әмма бу язучы киявенең анда нинди вазифа үтәгәнлекне сорашмаганмын.

Шул ук елларда «Шура», «Чүкеч» журналларында да эшләп-күренгәләп киткән Зариф Бәшири «Замандашларым белән очрашулар» китабында (1968) Рәмиевләрнең матбага хезмәткәрләренә яхшы эш хаклары түләвен искә ала. «Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, матбагачыларга зур жалованье бирә иде. «Вакыт» редакторы Ф.Кәрими белән «Шура» редакторы Риза казый аена йөз утыз сум алдылар. Моны күпләр «министрлар жалованиясе» дип әйтер иде», дип яза. Шул ук елларда Рәмиевләр Оренбургның бер үзәк урамында, Шакир Рәмиев йорты белән янәшәдә матбугат хезмәткәрләре өчен дип аерым йорт та төзи. Бер катлы, өч секцияле ул йортның ике секциясендә Ризаэддин хәзрәтнең ишле гаиләсе урнашачак. Соңгы секциядә исә шулай ук башка шәһәрдән чакырып китерелгән Борһан Шәрәф, Кәбир Бәкер кебек журналистлар яшәячәк. (Эшкә кабул ителү документларында аларны «Рәмиевләр йортында яши» дип теркәгәннәр.)

● Фатих Кәрими хатыны Зөһрә белән. Оренбург, 1903 ел. З.Бәширов фотосы.

ОРЕНБУРГ ТӨБӘГЕНДӘГЕ РЕДАКТОРЛАР

1906 елның язында Рәмиевләр баш мөхәррирнең урынбасары вазифасын (рәсми документларда «икенче редактор» диелгән) башкару эшен Риза Фәхретдиновка тәкъдим итү фикере белән килешә. Риза хәзрәт яңарак кына өченче мәртәбә мөфтиятнең казые – мөфтинең төп ярдәмчеләреннән берсе вазифасын үтәргә сайланган була. Аның язучылык эшен бик тә үз иткәнлеген, елына бер-ике китап чыгармыйча калмаганлыгын истә тотып, Риза казыйны Оренбургка китерү мәсьәләсендә Рәмиевләр дә бик тырыша. Шул рәвешле 1906 елның май аенда Риза казый гаиләсе Оренбургка килеп төпләнә. Үзе «Вакыт» редакциясендә баш мөхәррир урынбасары буларак эшкә керешә. Озакламыйча аның өлкән улы Габдерахманны да шушында эшкә алалар.

Фатих Кәрими әнисенең энесен Уфадагы мөфтияттән үгетләп Оренбургка кайтару бурычын, әлбәттә инде, бертуган Рәмиевләр башкарган. Ике елдан

● Галиәскәр Камал.

● Шакир Мөхәммәдев. Ул 15 яшеннән башлап Оренбургта яшәгән, Хөсәенов байларның исәп-хисап эшләрен алып барган, язучылар белән дә бик күп аралашкан.

● Оренбургта Закир Рәмиев-Дәрдемәнд яшәгән йорт. З.Бәширов фотосы. Хәзер бу йортта сәүдә бәяләрен контрольдә тотарга тиешле департамент урнашкан.

шәхесләр

● Риза Фәхретдин гаиләсе белән. 1905 ел.

соң, Ризаэддин хәзрәт «Шура» журналы мөхәррире итеп күчерелгәч, «Вакыт» газетасында аның урынына улы Габдерахман калдырыла. Риза хәзрәт бертуган Рәмиевләр белән килешеп, кулга-кул тотынып дигәндәй, үзенә тәкъдим ителгән һәм үз хыялында йөргән эшне бик теләп башкара. «Шура» журналы большевиклар карары белән ябылганчы шунда эшли. 1918 елның февралендә аларның Дәрдемәнд белән соңгы күрешү вакыйгасы хәзрәтнең кызы Әсма Шәрәф истәлекләрендә китерелә. Югыйсә безнең матбугатта аларның соңгы мәртәбә очрашуы Дәрдемәнд бик каты авырып ятканда, 1921 елның көзендә булган, дигән уйдырма язмалар да булгалады. Имеш, Риза хәзрәт, Уфадан Орск шәһәренә килеп, яшьтәшен һәм фикердәшен бик авыр хәлдә күргән. Ул заманда түгел, әле бүген дә Уфадан Орск шәһәренә бару өчен берничә төрле транспорттан файдаланырга, кимендә ике көнне сарыф итәргә кирәк. Ә 1921 елда әле Оренбург белән Орск арасындагы өч йөз илле чакрымлы тимер юлы да төзелә генә башлаган була .

Дәрдемәнд белән Риза Фәхретдиновның аерылышу вакыйгаларын хәзрәт кызы Әсма Шәрәф истәлекләреннән укып китик. «Оренбургта торганда әткәйнең ике арада самими дуслык, ихтирам саклаган кеше Закир әфәнде Рәмиев (Дәрдемәнд) иде. Закир әфәнде үзе дә безгә еш кына әткәй янына килеп, озаклап утырырга ярата иде. Оренбургтан китәргә әзерләнгән вакытта (1918 ел, февраль урталары), Закир әфәнденең өйләренә әткәй саубуллашырга барып кайта. Күп сүзләр арасында Закир әфәнде әткәйдән сораган: «Хәзрәт, әгәр дә дөньялар тынычланып, заманчарак итеп «Шура» журналы чыгу ихтималы булса, кире кайтыр идегезме?» дип. Әткәй, озак уйлап тормастан: «Һичшиксез, кире кайтыр идем», дигән.

Бу аларның актык күрешүләре булган. Юлга чыгып китәр һәм өйдә калдырыр өчен дә акча кирәк булгач, әткәй кайбер китапларын «Өлфәт» китап кибетенә сата. Аннары ат-чана яллап Иманкол, Мәләвез, Җиргән, Эстәрлеләр аша башта үзе генә китәргә була. Шул рәвешле юл барганнан соң, 1918 елның 1 мартында әткәй исән-сау Уфага барып җиткән... Әткәйгә генә түгел, безнең бөтенебез өчен дә унике ел торган Оренбургтан аерылып китү авыр булды. Чөнки безнең анда яшәгән еллар иң бәхетле, иң күңелле еллар иде. Әткәй «Шура»да, Габдерахман абый «Вакыт» газетасында эшләде, калганнар укуда булды,» дип яза Әсма апа атасына багышлап чыгарылган китапта («Ризаэтдин Фәхретдин», Казан, 1999 ел). Бервакыт миңа да күрше йортта яшәгән Әсма апа белән очрашырга насыйп булган иде. Кайберәүләрнең Дәрдемәнд белән Риза хәзрәтнең 1918 елның февраленнан соң да очрашулары турындагы хәбәрен искә алдым. «Юк, ул буталчык елларда әткәй Уфадан беркая да чыкмады. Андый очрашулар булса, без белмичә калмас идек», – диде Әсма апа.

Шул ук истәлек язмаларында Әсма апа Шакир Рәмиев өе янәшәсендәге йортта яшәү көннәрен дә бераз тасвирлаган. Шакир йорты артындагы зур бакча җәй дәвамында алар карамагында булган. Рәмиевләр җәй айларын шәһәрдән бик еракта урнашкан приискаларында уздырганнар.

Әлбәттә, бу елларда Дәрдемәнд, Ризаэддин хәзрәт, Г.Исхаки, Ф.Кәримиләрдән аерымрак төбәктән – Буа шәһәреннән булган Шакир Мөхәммәдевны һәм аның хезмәтләрен да атамый үтү килешмәс. Шакир Мөхәммәтшә улы унбиш яшеннән Оренбург шәһәренә килеп урнаша. 1884 елдан шәһәрнең иң бай сәүдәгәрләре Хөсәеновлар конторасында төрле эшләр башкара. Ике гасыр аралыгында гына, бер Мәскәү сәүдәгәренә ялланып, ике-өч ел Харбин каласында булып кайта. Шакир Мөхәммәдевнең Харбинда булганда иҗат ителгән «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» әсәре генә 1901 елда Казанда нәшер ителгән. Киләсе елда ул кабат Оренбургка кайтып, Хөсәенов байлар конторасында исәп-хисап эшләрен башкаруын дәвам иттерәчәк. Калган барлык хикәя һәм повестьлары бер-бер артлы Оренбургта Кәримовлар басмаханәсендә дөнья күрәчәк. Һәм берара ул шунда «Карчыга» исемле көлке-сатира журналын да нәшер итәчәк әле. Ул 1923 елда шул калада гүр иясе дә була. Аның эш өстәлендә иганәче Хөсәенов бертуганнарның берсенә багышланган, әмма тәмамланмаган әсәре кала, диелә бер белешмәдә. Бу чорда Ш.Мөхәммәдовның Рәмиевләр белән бәйләнеше матбугат битләрендә бик теркәлмәгән булса да, 1960 елларда Оренбург зыялылары аның төрле җыелыш-утырышларга даими йөргәнлеген, зыялы катлам белән актив аралашканлыгын искә ала иде. «Вакыт» газетасында да аның мәкалә-язмалары чыккалап торган.

ТЕАТР ӘҺЕЛЛӘРЕ

Безнең әдәбият гыйлемендә элек Оренбург төбәгендә яшәп иҗат иткән шәхесләрнең эшчәнлеген барлау өлкәсендә беркадәр сүлпәнлек тә сизелә кебек. Ә кайбер фактлар турында язганда төгәлсезлекләр дә очрый. Узган ике гасыр аралыгында шул төбәктә яшәп иҗат иткән кайберәүләрнең әдәби эшчәнлеге, әдәби талпынышлары исә күп очракта телгә дә алынмый. Мәсәлән, Г.Исхакый, С.Максуди, Х.Ямашевлар белән бер чорда Казан укытучылар мәктәбендә укыган, узган гасыр башларында иҗат «җимешләре» әдәбият сөючеләргә мәгълүм булган шәхесләрдән Габдерахман Дәүләтшин-Хөсәенов (Әхмәт бай Хөсәенов өендә тәрбияләнгән), Шакир Мөхәммәдьяров (Орск шәһәрендә туган, Дәрдемәнд кебек үк, шундагы Борнаев сәүдәгәрләр кызына өйләнгән), Ярулла Вәлиев (Сембер губернасында туган), Габдерәүф Ниязбаев (Оренбург янәшәсендәге Каргалы «каласы»нда туган) исемнәрен алыйк. Ул чорда бит аларның үз драма әсәрләре дә, А.Пушкин, Н.Гоголь, А.Островскийларның әсәрләреннән тәрҗемәләре дә яңа туып килүче театр сәхнәләреннән төшмичә уйналган. Газеталарда әдәбият, мәдәният темасына язган хезмәтләре даими рәвештә басылып килгән. Мәсәлән, Габдерахман Дәүләтшинның «Яшь хатын» драмасы Совет хакимияте урнашканчы күп кенә театр коллективлары тарафыннан сәхнәләштерелә. Яңа хакимият чорында гына «бу буржуйның» үз әсәре дә, тәрҗемә пьесалары да уйналмаган. Аның әдәби хезмәтләренең кайчандыр үзешчән сәхнәдә уйнаганда кабул иткән «Д.Таждаров» тәхәллүсе белән дөньяга чыгуын да әйтеп үтү кирәктер.

(Дәвамы киләсе санда).

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.



Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ

Күл буенда очрашу

Бик тә эссе – чамасыз дәрәҗәдә коры килгән җәй иде ул... Бигрәк тә шәһәр халкы бу хәтле кызудан ничек качарга, кая кереп котылырга белми! Бөтен җир, дөньяның бар почмагы, һәр нәрсә ут кебек кызган. Һәммә җирдән бары тик ут кына, ялкын яки кайнар һава гына бөркелә сыман!

Ә минем хәлләр аларныкы белән чагыштырганда яхшырак. Минем бакчам, дача бар! Әле җитмәсә, ул башкаларныкы сыман ачык җирдә, ялан кыр уртасында түгел – ә зур бер урман эчендә. Монда быелгы эсседән дача өенең түбәсе генә түгел, ә усаклы-каенлы, имәнле-чыршылы һәм ямьле урманның дымлы һавасы, рәхәт күләгәсе дә саклый.

Әле ул гына да түгел. Безнең бүтәннәрдә булмаган тагын бер олы бәхетебез бар. Янәбызда гына зур, матур һәм шактый тирән күл дә җәйрәп ята! Андый эссе җәй көнендә адәм баласы кичергән мондый зур бәхетнең бөтен рәхәтен, барлык ләззәтен болай гына, кыскача гына аңлатып бетерү мөмкин түгел! Моның тулы мәгънәсен, бу ләззәтнең бөтен тирәнлеген бары тик авыл җирендә туып үскән кеше генә аңлый аладыр...

Андый эсседә эшкә дә йөрисе килми: тукталышларда автобус, троллейбус көтеп тилмерүләрне үзегез дә беләсез бит. Шуңа күрә чираттагы ялны ничек җиткерергә белмичә, көннәрне генә түгел, сәгатьләрне дә санардай буласың.

Июнь аеның ахырына хәтле түздем бит мин, шуңа кадәр эшкә йөрдем. Ә инде июль ае кергәч, ял алдым – иреккә чыктым! Үземә иң шәп ял дип бакчада яшәүне сайладым. Гел шунда торырмын дип, шәһәрдәге бөтен вак-төякне дә төяп килдем. Радиоалгыч, китап кебек нәрсәләрне һәм азык-төлекне әйтәм инде. Андый эссе дә вак-төяк өчен дә гел шәһәргә чабасы килми ич.

Шулай итеп, бер өйдә ялгызым рәхәтләнеп яши башладым. Беркем комачауламый, беркем тегене-моны эшләргә кушмый. Син – ялгыз, син – тулысынча үз хозурыңда! Моннан да зуррак бәхет бармы икән бу дөньяда, дип, ятасың рәхәтләнеп җәйге урман эчендә, өеңнең салкынча күләгәсендә.

Ялга чыкканыма өч-дүрт көн узган иде бугай инде... Шулай бер көнне иртә уянып киттем. Уяндым да, кемдер каядыр ашыктырып торгандай – сикереп аякка да бастым. Тәрәзәдән тышка багам: көн кичәге кебек үк аяз, матур, кояшлы. Тәрәзә янындагы урман аша әле кояш күренми, ләкин аның бөтен җан ияләрен уятучы нурлары инде бу дөньяга гаять мул булып сибелгән. Сәгатемә күз салам – әле иртәнге алты гына тулып килә. Шулай булса да, урман һавасы керсен дип, тәрәзәмне ачып куям, киерелеп хуш исле һава сулыйм!

Әйе, ул көнне бик иртә торылган иде шул. Ләкин нишлисең – хәзер йокы тәмам качкан, кирегә юл юк! Бакчага чыгып, алмагач төбенә үзем көйләгән юынгычта битне чылатып алдым. Кәеф тагын да күтәрелебрәк китте. Тирә-юньдә ду килеп кошлар сайрый! Бермәл аларның ярсый-ярсый сайрауларына һушым китеп тордым. Бераздан «Инде нишләргә?» – дим үз-үземә. Һәм шундук күңел: «Күл буена!» – дип җавабын да бирде. Тиз генә өйгә кереп үземнең киң кырлы салам эшләпә сомбрероны алып чыктым да күл буена таба кузгалдым.

Күлгә илтүче бу сукмак инде ничәмә-ничә еллар буе йөреп тәмам күнегелгән, андагы һәммә борылышны, кырыйда кала торган һәр агач төбен һәм уйсулыкларны беләм. Ләкин бүген аннан ни өчендер беренче мәртәбә үткән шикелле – рухланып, канатланып уздым. Олы капканы узгач, туктап та алдым әле. Алдымда яшь-яшь юкәләр, төз матур каеннар тора. Алардан күзне алып булмый! Аларга караган саен күңел тагын да очынарак төшә, ныграк канатлана, көчлерәк талпына. Әйтерсең лә, көчле бер тылсымчы кулына килеп эләккәнмен!

Әйе, дөнья гүзәл, бик тә гүзәл иде ул көнне!.. Ашыкмыйча гына атлыйм. Күңелдәге, җандагы чиксез бәхетне һич кенә дә чайпалдырасы, түгәсе килми. Дөньяны шундый да матур, рәхәт, ләззәтле итеп яратканы өчен Ходайга эчтән генә бетмәс-төкәнмәс рәхмәтләр укыйм.

Шулай бөтен җаным-рухым белән оча-очына күл буена төшеп җиткәнемне сизми дә калганмын! Ә анда минем инде күптән ияләнгән, күнеккән уңайлы урыным бар. Ямь-яшел чирәмле матур гына бер култык ул. Кеше бик килми торган аулаграк урын.

Әнә шул, көн дә су керә торган җиремә дип барсам – ни күрәм: анда бер кыз басып тора! Баштарак күзләремә ышанмыйчарак тордым – төш кенә күрмимме икән, дип уйлыйм. Чөнки йокыдан да әле яңа гына уяндым бит. Аннан соң, бу вакытта, шушылай таң атар-атмас чакта, ничек инде күл буенда кыз бала ялгыз гына басып торырга мөмкин?!

Әмма чыны шул – минем көн саен су коена торган урынымда гүзәл бер кыз тора! Ул инде өске киемнәрен салып куйган, суга керергә тәмам әзерләнеп беткән, ләкин әллә суның салкынлыгыннан куркып, әллә берьялгызы гына керергә базмыйча, җир белән су арасында дигәндәй басып тора. Кайчак матур гына иттереп аяк бармагын суга тигезеп ала, әмма эчкә кереп китәргә һаман кыймый.

Мин исә әле читтәрәк. Ул да әле минем якка карамый. Ләкин мин аның бераз гына тулырак гүзәл буй-сынын, шул буй-сынга бик тә килешеп торган тулы матур аякларын, ачык яшел төстәге йөзү костюмы каплый төшкән тулы нәфис күкрәкләрен шактый әйбәт күрәм. Әлбәттә инде, акрын гына атлый-атлый, үземне төш белән өн арасында сизеп, аңа якынаям... Бераздан ул да минем якка күтәрелеп бакты бит! Бу вакытта мин аңа шактый якын килгән идем инде, шуңа күрә бер-бер сүз катмыйча мөмкин түгел иде.

кызның күңелендә миңа карата ниндидер бер ышану тойгысы тудырды булса кирәк – бер мәлдән ул да йомшак кына елмаеп:

– Әйе шул, хәерле иртә булсын! – диде. Ә үзе һаман миңа баккан. Аның хатын-кыз табигате сүзсез генә әле мине өйрәнә, мине тикшерә иде шикелле. Минем нинди зат, нинди төр адәм булуымны тагын да ныграк аңларга телидер, күрәсең.

– Ә сез бүген күл буена бик иртә төшкәнсез... – дигән булам.

Ул да сөйләшергә ялындырып тормый:

– Әйе шул, шулайрак булды... – Һәм әз генә тынып торгач, тагын өсти. – Төн буена йоклый алмадым... Шуңа яктыра башлауга күл буена төштем.

– Сез монда кунакка килдегезме соң?.. – Аны безнең күршедәге йортларның берәрсенә килгән кунак кызы дип уйлап, шулай сорыйсы иттем.

– Хәерле иртәләр сез гүзәлгә! – дидем мин, үземне булдыра алган кадәр табигыйрәк тотарга теләп.

Ә ул башта байтак вакыт күзләрен тутырып карап торды әле. Минем олы сомбрероны (чөнки якын-тирәдә андый нәрсә киюче бүтән кеше юк!), төймәләре төшкәләгән җәйге җиңел күлмәгемне һәм «күл буенда барыбер бер кеше дә булмый», дип киелгән иске шортымны, яланаяк басып торуымны – һәммәсен дә күздән кичерде. Хатын-кыз бит ул, кешенең тышкы кыяфәтенә карап, без күрмәгән, без белмәгән әллә нәрсәләрне аңлап, нәтиҗә ясый ала. Әнә шул күз йөртеп алуы

– Юк, юк, алай түгел! Менә бу пионер лагерена (ул башы белән җиңелчә генә ымлап, каршы як ярдагы урманга таба күрсәтте) вожатый булып килгән идем мин... Әмма андагы черки! – диде дә яңа танышым иркенәеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Валя исемле икән ул. Институтның чит телләр факультетында укый. Алар быел дүртенче курсны бетергән дә, менә монда педагогия практикасы үтәргә җибәргәннәр.

– Ә сез монда нишлисез соң? – Бусы инде ул миннән сораштыра башлый. Үзе шаян елмаеп миңа текәлгән. Күрәсең, минем яланаяк булуым, ә башыма шундый сәер эшләпә киюем елмайта аны. Минем исә аның елмаюыннан кәеф кенә күтәрелә.

– Менә шәһәрдән качып килдем! – дим аңа. – Монда рәхәт бит. Иркен! Ялгызлык! Тыныч! – Бераздан, тагын да батыраясы килеп, болай дип тә өстәп куям: – Урман уртасындагы өйдә берүзем яшәп ятам!

Ул елмаюыннан туктап, җитди итеп сорап куя:

– Төннәрен дә курыкмыйсыңмы син?

– Ю-ю-ук! – дим мин. – Урман мине ярата ул!

– Һы! Ә бандитлар килеп чыкса?!

Үземнең башыма да килмәгән бу фикергә бермәлгә аптырабрак калам да, аннары сүзне уенга борам:

– Ә мин менә бу сомбрероны киям дә аларга: «Мин – мексиканец, ноу понимау!» – дип котылам, – дим, көлә-көлә.

Мондый борылыш Валяга да ошый, ул тагын да матуррак итеп, бөтен йөзе, күзләре белән балкып көлә... Ә мин аның кулыннан җитәкләргә җөрьәт итәм:

– Әйдә, суга керик инде!

Ә Валя һаман көлә-көлә: «Ноу понимау», – дип кабатлый.

Сүз уңаенда мин аның нинди чит телләр өйрәнүен сорыйм. Инглиз һәм немец телләре икән. Немецчә мин дә бераз беләм. Хәтта Мәскәүдә булган чагымда бер фин кызы белән немецча сөйләшеп йөргәнебез булды. Чөнки ул урысча бөтенләй белми иде. Мин, билгеле, боларын ук сөйләп тормыйм инде Валяга, бары тик немец телендә: «Без синең белән су коенабыз», дигән сүзләрне әйтәм. Ул мине бер урында тезәтә дә, кәефе китмәсен дигән төсле хуплап:

– Йа, йа! – дип куя. Ягъни «әйе, әйе» – дигән сүзе инде немецча.

Шуның белән немец теле онытыла. Валя ике кулын матур итеп алга суза да, башта суга чумган төсле хәрәкәт ясый, ә аннары, кулларын ике якка җәеп, бик нәфис хәрәкәтләр белән ипләп кенә йөзеп китә. Аның менә шулай итеп суга керү мизгеле, матур итеп йөзүе, бу гүзәлнең дулкын һәм су стихиясе белән тоташуы, – соклангыч рәвештә минем күз алдымда, мәңгегә-мәңгегә истә кала.

(Дәвамы киләсе санда).

Берлинны яулаган татарлар

(Дәвамы. Башы 30 нчы санда).

Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Күки авылында 1925 елда туып-үскән **Миңнулла Гыйззәтуллин**, үсмерлеккә җиткәч, колхозда хезмәт куя. 1943 елның апрелендә Кызыл-Йолдыз комиссариаты тарафыннан фронтка озатыла. Беренче Украина фронтында 20нче гвардия механикалаштырылган бригаданың укчылар бүлегендә автоматчы булып көрәшә. 1944 елның 23 сентябрендә Одер елгасын кичү барышында күрсәткән каһарманлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. 1945 елның 24 апрелендә Берлин янындагы Уленхорст бистәсенә беренче булып бәреп керә, үз пулеметы белән 6 фашистны юк итә. Яралана. Демобилизациядән соң Казанның тимер-бетон конструкцияләр заводында эретеп ябыштыручы булып эшли. 1993 елда туган авылында җирләнә.

Миңнулла Гыйззәтуллинны Герой исеменә тәкъдим иткән рапорт.


376
Наградной лист
1. фамилия имя отчество - Гизатулин Мунула Сунгатович
2. звание - гв. красноармеец 3. Должность часть - автоматчик
2 мотострелкового б-на 204 Гвардейской Замощицкой ордена Ленина механизированной Краснознаменной бригады
Представляется к награде присвоения звания „Героя Советского Союза"
4. Год рождения - 1925 5. Национальность Татарин 6. Партийность - б/парт.
7. Участие в гражданской войне и последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где когда)
1-ый Украинский фронт с декабря 1943 г.
8. Имеет ли ранения в Отечественной войне - легко ранен 26.12.43 г.
9. С какого года в Красной Армии. - с апреля 1943 г.
10. Каким РВК призван - Кзыл-Ярдовским РВК, Татарской АССР
11. Чем ранее награжден - не награждался.
12. Постоянный домашний адрес и адрес семьи.

В наступательных боях батальона с 17.07.44 тов. Гизатулин проявил исключительное мужество, смелость и бесстрашие при форсировании рек Западный Буг и Сан и в тяжелых боях в окружении.

При форсировании р. Висла 30.07.44 г. несмотря на автоматно-пулеметный огонь и арт-минометный огонь противника и непрерывный обстрел авиацией противника т. Гизатулин по собственной инициативе на бредне стал форсировать р. Висла. Находясь на середине реки вражеская авиация стала бомбить и обстреливать вражеская авиация. Взрывом бомбы т. Гизатулин был сброшен с бредня в воду, но не растерявшись и проявив исключительные усилия вплавь добрался до противоположного берега. Под сильным огнем противника т. Гизатулин подполз к траншеям противника и бросил две гранаты Ф-1 в результате чего было убито 22 солдата противника. Овладев траншеей пр-ка тов. Гизатулин вел непрерывный автоматный огонь по противнику, чем способствовал форсированию реки остальным личным составом б-на.

За мужество и отвагу, бесстрашие, инициативу и геройство достоин присвоения звания „Героя Советского Союза"

Командир б-на гв. капитан (Соргишево)

Мамадыш районының Кече Кирмән авылында 1915 елда туган **Гафият Нигъмәтуллин** 1930 еллар башында Чиләбе трактор заводында, Алапаев һәм Свердловск заводларында эшләп ала. Аннары туган авылына әйләнеп кайта да, «Пятилетка» совхозында политбүлек башлыгының яшьләр белән эшләү буенча ярдәмче вазифаларын башкара. 1939 елда Кызыл армия сафларына чакырыла. Ленинградтагы хәрби-сәяси училищеда белем ала. 1939-1940 еллардагы совет-фин сугышында катнаша. Шундагы батырлыгы өчен 1940 елның 21 апрель Указы нигезендә Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. 1942 елда Хәрби-сәяси академияне тәмамлый.

Бөек Ватан сугышында Төньяк-Көнбатыш фронтның 7 нче армиясендәге 86 нчы укчы дивизиядә рота политругының ярдәмчесе булып катнаша. 1945 елның 8 маенда Берлиндагы соңгы бәрелешләр вакытында һәлак була.

Норлат районының Җирекле авылында 1895 елда туган **Миңнехан Мәсәгутов** фронтка Октябрь хәрби комиссариаты аша озатыла, 115 номерлы ныгытылган районда 504 нче аерым пулемет-артеллерия батальонында сапер булып хезмәт итә. Сугышлар барышында Белоруссия белән Польшаны азат итүдә катнаша, Нейсе елгасын кичкәндә, кырларны һәм яр буен миналардан арындырып, һөҗүм белән алга баручы совет частьлары өчен плацдарм әзерли. Бер шушы елганы кичкәндә генә дә танкларга каршы 100 дән артык минаны юк итә. Ул 3 нче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Берлинны штурмлау башлангач, 1945 елның 24 апрелендә дошман өнендә һәлак була. Һәртөрле хәрби кагыйдәләрне бозып, М.Мәсәгутовны 1946 елның 15 маенда игълан ителгән Указ буенча, 1 дәрәҗә Дан ордены белән бүләклиләр.

1926 елда туган **Сөләйман Муса углы Мусин** фронтка Теләче район комиссариаты аша озатыла. 94 номерлы укчы дивизиянең 288 нче гвардия укчы полкында рядовой укчы булып хезмәт итә. Берлинны штурмлаган чактагы батырлыгы өчен, 1945 елның 30 апрелендә тутырылган рапорт нигезендә, ул Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, әмма соңыннан нибары Сугышчан Кызыл байрак ордены белән бүләкләнә.


Все графы заполнять полностью
Наградной лист
1. Фамилия, имя и отчество Мусин Сулейман Муса
2. Звание Гвардии красноармеец 3. Должность, часть стрелок 8 стрелковой роты 288 Гвардейского стрелкового полка 94 Гвардейской стрелковой дивизии
Представляется к присвоению звания Герой Советского Союза
4. Год, место рождения 1926 Национальность Татарин
6. Партийность Член ВЛКСМ 1944 г. 7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР в Отечественной войне (где, когда)
1 Белорусский фронт 1.11.44
8. Имеет ли ранения или контузии в Отечественной войне (число, месяц, год ранения местонахождение в настоящее время) ранений не имеет
9. С какого времени в Красной Армии (месяц, год) 11.1943
10. Каким РВК призван Тюлячинским РВК 11. Чем ранее награжден (№ приказа, дата, чей приказ) Медаль „За отвагу" приказ № 03/н. от 23.01.45 288 сп.

1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

В бою в г. Берлине 28.04.45 года на Александер плац при штурме полицейского управления города, первым ворвался в дом и ручной гранатой уничтожил яростно сопротивлявшихся 3 гитлеровцев "фаустников", чем дал возможность оцепить дом.

Когда на втором этаже дома в одной из комнат были немцы, в количестве 6 человек, он завязал с ними бой, ворвавшись в дом и броском гранаты уничтожил 6 сопротивляющихся.

Кроме того при штурме полицейского управления, в подвале уничтожил 5 полицейских, которые обстреливали из подвала наши передовые подразделения.

В бою за Александрийский вокзал, в доме на углу Кайзер-штрассе засевшая группа немцев мешала продвижению, т. Мусин скрытным путем подполз к дому и гранатой уничтожил до 12 немецких солдат.

За [...] мужество и отвагу достоин присвоения звания [...] Советского Союза.

Командир 288 [...] стрелкового Кишиневского [...] полка [...] /КОНДРАТЕНКО/

"30" Апреля 1945 года.

Сөләйман Мусинны Герой исеменә тәкъдим иткән рапорт.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

ЧЕРНОГОРИЯДӘГЕ ИҖАТ ОСТАСЫ

Аделаида Исламова иҗаты хакында газета битендә моннан берничә ел элек кечкенә язма басылды, улчак без Аделаида белән аны интерьер уенчыклары иҗат итүче гамәли сәнгать остасы буларак таныштырган идек. Хәзер талант иясенең яңа картиналарына сокланыйк.

Аделаида Исламова 1990 елда Казахстанның Караганда каласында туган. Каланың балалар сынлы сәнгать мәктәбендә, балалар музыка мәктәбендә скрипка һәм саксофон классларында белем алган, ул әле фортепианода да яхшы уйный. Ул Казан дәүләт федераль университетының сәнгать һәм дизайн факультетын уңышлы тәмамлаган. Бүген үз гаиләсе белән Черногориядә гомер итә. Аделаида Фәрһад кызы 2019 елда үз картиналары белән Луврда узган Халыкара яшь рәссамнар күргәзмәсендә дә катнашкан иде. Мәскәүдә оештырылган «Яшьләр-2021» күмәк күргәзмәсенә аның хезмәтләре дә сайланды.

«Бирегә без 2022 елның язында күчендек. Әле моннан берничә ел элек кенә, балаларыбыз туганчы ук, җәмәгатем Ренат белән шушы дәүләткә сәяхәт иткән идек, – дип сөйли Аделаида ханым. – Шулчак бу матур илне бик ошаттык. Рәссам буларак биредә күп манзараны ясап булуын да аңладым. Сәяхәтебез көннәрендә бер ярым җимерек пристань янәшәсендәге тау башында бердәнбер йортка игътибар иткән идем. Шулчак аның аша тыйнак бер образ барлап, әлеге күренешкә гашыйк та булдым. Бу йорт Тиват ярыннан яхшы күренә. Анда кайчандыр Австрия-Венгрия хәрби базасы урнашкан булган, ахры. Тик минем үз фантазияләремдә исә ул хыял йортына әверелде дә куйды. Шулай итеп, «Хыял йорты» дигән картинам иҗат ителде. Әлеге әсәрдән Черногория хакындагы сериям башланып китте, бер-бер артлы «Петровацтагы йорт», «Будва – иске кала», «Будва бухтасы төне», «Котор күренеше» дә язылды...

Черногория дәүләте хакында иҗат кешесе бары мактау сүзләрен сөйли. Аның матурлыгын сүзләр белән генә аңлатып та булмый. Аны килеп күрергә кирәк дип саныйм. Тауларның диңгезләр белән ничек очрашуына гаҗәпләнерсез, ак болытларның бер күч итеп җыелып, тау түбәләре янәшәсендә үк ял итәргә тукталуларын күрерсез, кояш баеганда шушы мәгърур гүзәл күренешләрне алсу-ачык шәмәхә төскә кертә. Болар барысы да шулкадәр дә искиткеч, чынбарлыкка туры килмәслек булып тоелган күренешләр, аларны грек мифларындагы борынгы шагыйрьләрнең әкияти Парнас тавы белән соклануларына тиңләп була төсле. Мондый соклану бер миндә генә түгелдер... 1970 елларда бөек иҗатчы, җырчы һәм шагыйрь В.Высоцкий да Югославиядә гастрольгә килеп, бу дәүләткә гашыйк булуы хакында шигырь дә язган икән.

Черногория бүгенге тормышымда минем өчен дә икенче ватаным була бара. Минем иҗатта шушы ил матурлыкларын күрүдән туган образлар белән тулылана баручы яңа этап ачылды. Мин биредәге шәһәрләрне язам, йортларны... Безнең глобальләштерү һәм төрле милләтләрнең үзара кушылулары белән аерылып торучы һәм дә бик тиз узып баручы гасырыбызда Черногория халкы – үз үзенчәлекләрен, ил ямен, тыныч күкләрен сакларга омтылучы халык ул, дияр идем. Ә бу бит бер дә аз кыйммәтләр түгел... Рәссам тормышы өчен дә тулы бер бәхет».

Аделаида Фәрһад кызының Черногориядәге тагын бер иҗади темасы биредәге песиләрне сурәтләү белән бәйләгән. «Бу илдә хуҗасыз хайваннар аз, ә булганнары арасында песиләр – иң күбе, – дип аңлатты ул. – Шуңа күрә нәкъ шушы җан ияләрен ешрак сурәтли башладым. Дөрес, песиләр үз көннәренең яртысыннан артыгын диярлек йоклап үткәрергә яратканга күрә, аларны йокымсырау итеп ешрак язарга да туры килә. Аннары гомере буе мәчеләрне генә ясаган Бөекбритания рәссамы Луис Уйэнны да искә төшердем дә, нишләп әле миңа да бу темада булмаска, дип уйландым. Әлеге рәссам песиләрне артык нык ошаткан, билгеле!»

Әйе, Л.Уйэн гына түгел, башка рәссамнар да песиләрне күпләп ясаган. Бу хәзер дә шулай. Әй-

тик, бүгенге япон рәссамнары арасында да гел пеcи сурәтен генә ясаучылар җитәрлек. Күп кенә рәссамнар, гомумән, сәеррәк сыйфатлы була һәм аларның күбесе: «Мин: «Сынлы сәнгать – ул аерым бер «бәла» дигән уй белән килештем. Син шул «кимчелек» белән туасың һәм аңа карата яхшы мөнәсәбәттә булырга тиешсең – бу аерым бер холыкны таләп итүче сәю, шашкын хис, ә син шуңа тарыган бер зат инде...» – дип сөйләнергә ярата. Моның белән килешмәскә дә мөмкин түгел. Билгеле, сынлы сәнгать, ул, чыннан да шундый өлкә: син аннан бик читләшә алмыйсың, һәр көн рәсем ясыйсың, һәр көн үз хисләреңне киндергә түгәсең, энергияңнең бер өлешен картиналарыңа таләп кучерәсең. Әлбәттә, иҗатта бер теманы алга сөрү дә хаклы булырга мөмкин.

Аделаида Исламова да моны һич тә ашыкмыйча, сарыф ителгән вакытын җәлләмичә, җитди тырышлык белән иҗат ителгән картиналары белән дә раслый. Андагы сурәтләр, әйтерсең лә, төрле төстәге йөзләрчә-меңнәрчә нечкә сызыклар-җепселләрдән генә үрелгән. Бу ясау ысулы – плентанизм. Әзер сурәтләр киндерләрдә челтәрдәй бәйләмнәр хасил иткәндәй күренә. Мондый ысул белән язылган чәчәкләр, кеше портретлары, шәһәр пейзажлары, пеcи сурәтләре рәссам иҗатындагы һәрбер хезмәте уңышлы килеп чыга.

Талантлы рәссамның «Күгәрченнәр» дип аталган картинасы да тамашачылар игътибарыннан читтә калырлык түгел. Бу күренешне ул үз гаиләсе белән Нью-Йорк паркында һава сулап йөргән чакта истә калдырган. «Әлеге паркта һәрчак төрле иҗат вәкилләре еш була иде, шунда без күгәрченнәрне ашатып утыручы, сәләмә киемле бер адәмне дә күреп алдык. Аның янәшәсендә һәрчак күгәрчен өере булды. Ул адәм үзе дә аларга җаны-тәне белән береккән, кошлар да аны бик үз итә төсле кебек иде. АКШтан кайткач, шул хатирәмне барлап, әлеге әсәремне яздым», – ди әңгәмәдәшем.

Сәләт иясенең шушы елларны өчен сайлаган дәүләттә рәссамнар ничек көн күрә соң?! Аделаиданың бу хактагы җавабы да ихлас: «Черногориядә иҗат кешесе авырлыкларга әзер булырга тиеш. Бирәдә картина галереялары күп түгел, һәм бүген ачылганнарын да мөһаҗирләр: – Россия һәм Украинадан килүчеләр тота. Күптән түгел Бечичида оештырылган күргәзмәгә барып килгән идек, анда Черногория яр буе артистлары, музыкантлары, рәссамнары – бар иҗат бомонды җыелды. Күбесе бирәдә үз картиналарын сата алмауга сыкранды, төп сынлы сәнгать базары булып саналучы Белградны искә алды. Бу аңлашыла да. Яшәү һәм мәгърифәт дәрәҗәсе бар Югославия белән чагыштырганда Белградта һәрчак югарырак булган бит. Әлеге шәһәрдән алган тәэсирләр дә Россиянең мәдәни башкаласы Питерны искә төшертә. Бу җәһәттән Черногория Сербиядән сизелерлек калыша. Мин бирәдә тырышам, әмма әлегә бу омтылышларым зур нәтиҗәләргә китермәде. Черногория башкаласы Подгорицадагы берничә картина галереясы бар, әмма картиналарымны анда сатуга кую – катлаулы мәсьәлә булып чыкты. Әлеге процесс кирәгеннән



артык бюрократлаштырылган, галерея хуҗалары да яңа исемнәр эзләп азапланмый, моның хаҗәте дә юк. Аларда, ахрысы, үз илендә танылган үз рәссамнары әсәрләре генә сатыла да. Хезмәттәшлек хакындагы теләсә кайсы тәкъдимне тыңлауга ук алар рәссам хакындагы бар мәгълүматны, картина фотоларын почтага салуны гына үтенә, ә бу инде җавапны чиксез озак вакыт көтәргә туры киләчәк дигән сүз.

Бервакыт Әдрән диңгез яр буенда урнашкан Бар шәһәрендә безгә үз эшләрен галереяда сатучы җирле рәссам белән сөйләшеп алырга туры килде. Галереядагы башка рәссамнарның картиналарына күз атып, ул аларның ясау дәрәҗәләре өчен уңайсызланып та куйды. «Карагыз, мин нәрсә сатам! Бу бит – катастрофа, һәлакәт!» – диде ул безгә русча. Аның яше алтмыштан узганга күрә ул элеккеге Югославиядә нинди сынлы сәнгатьне яхшы бәяләүләрен һәм сатуларын бик яхшы хәтерли иде. Сугыштан соң җәмгыятьнең мәдәни һәм эстетик зәвыгы дәрәҗәләре нык какшаган икән. Һәм бирәдәге сынлы сәнгать бүген ике катлаулы булмаган мәсьәләне генә чишә: базарны сувенир продукциясе һәм өй интерьерында кулланылучы арт-вак-төяк әйберләр белән тәэмин итү. Шушы үзенчәлекләр белән килешергә туры килә.

Бүгенге көндә мин Будвадагы ике кибет белән хезмәттәшлек итәм: аларның берсенә үзем иҗат иткән курчакларны сатуга куям, икенчесенә – картиналарымны. Менә бу көннәрдә Херцег-Нови каласы картина галереясы хуҗабикәсе мине хезмәттәшлек шартлары хакында сөйләшергә чакырды, Ренат белән шушы җирле мәдәни башкалага юл тотачакмын. Бу хезмәттәшлек нинди нәтиҗәләргә китерер, карармын. Мин һәр көн иҗатта!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
11 август
№31, 2023

КАЛМАКЛАР

Кемерово өлкәсенең Яшкино районында Том елгасы буена – табигатьнең әкияти матур урынында урнашкан Юрты-Константиновы дигән авыл бар. Анда Ислам динен таратырга килгән бохаралылардан мөселманлык алган Себер татарлары – калмаклар яши. Заманында бу шактый зур авыл булган, ике катлы иркен агач өйләрдә сәүдәгәрләр гомер кичергән. Авылның бер башында мәдрәсәдә белем бирсәләр (ул өлеш Юрты /йорт/ дип аталган), Константиновы дип йөртелгән икенче өлешендә рус мәктәбендә укыганнар. Авыл уртасындагы мәчеттән исә азан тавышлары яңгырап торган. Совет хакимияте урнашкач та «Красный Восток» күмәк хуҗалыгы барлыкка килә, фермаларда сыерлар тотыла, бозаулар үстерелә, ат заводы да була. Сыер малы ишле булгач, табигый ки, май заводы да тулы көченә эшләп тора. Пекарняда исә тәмледән-тәмле икмәк пешерелә.

Хәзер инде кайчандыр шаулап-гөрләп торган авылның үткәне турында инде тузып барган, кайчандыр ашлык саклаган биналар, ватылып, таралып, күгәреп беткән авыл хуҗалыгы техникасы гына искә төшерә. Хәер, алар гына микән?

Җәйнең матур көнендә бер төркем зыялылар Бөтендөнья татар конгрессының Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты рәисе Альберт Борһанов җитәкчелегендә Юрты-Константиновы авылына килеп җиттек. Кемерово дәүләт университеты бинасында «Кузбасс һәм Көньяк Себер татарлары: тарих һәм заман» дигән темага үткән Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең дәвамы шушы авылда узарга тиеш иде.

Безне таза бүрәнәләрдән салынган, әмма инде шактый тузган, уң якка бераз авышкан ике катлы агач йорт янында милли киемнәрдән калмак ханымнары каршы алды. Ике катлы йорт дигәнебез «Притомские калмаки» («Том буе калмаклары») дигән тарихи-этнографик очерклардан торган китапны туплап чыгаручы Нәфисә Садыйкова-Еремейкинаның ата-бабаларыннан калган мирасы икән. Бу бинада элек мәдрәсә булган. Биредә Нәфисә ханымның бабасы һәм әбисе балаларны гарәп хәрефләрендә укырга-язарга өйрәткән, дин белеме биргән. Октябрь революциясеннән соң мәдрәсәне япканнар, йортта гаилә тормышы башланган. Биредә Миңгали Йосыф улы Садыйков һәм аның җәмәгате Рәйсәнең сигез балалары туып буй җиткергән. Нәфисә ханымның әтисе Сәфәргали гаиләдә өченче бала булып дөньяга килгән. Бөек Ватан сугышы башлангач, Ибраһим белән Сәфәргали фронтка киткәннәр. Йортта алты бала калган. Аларның иң кечкенәсе – төпчек кыз Гыйззелбанат Садыйкова булган. Япь-яшь кызга ир-атлар эшен башкарырга туры килгән, ул ат җигеп сыерлар фермасыннан сөт һәм каймакны рус мәктәбенә ташыган. Ә үзенә сугышка бармый калган әрсез ир-атлар бәйләнмәсен өчен шаровар, ирләр күлмәге кигән, чәчен кыска итеп кистергән, рус телендә сүгенергә өйрәнгән. Аны авылда барысы да «Абау» дип атап йөртә башлаган. Аның 16 яшеннән үзе теләп фронтка киткән, танкист булып фронт юлларын узган, үлем белән күзгә-күз очрашкан абыйсы Сәфәргали, Җиңү көнен каршылагач та, Германиядә 1950 елга кадәр хезмәт иткән әле. Ул туган авылына исән-имин әйләнеп кайткач, әлеге ике катлы йортта гомер итүче сеңелесе Абауны танымаган. «Син кызмы, малаймы?» - дип сораган.

Гыйззелбанатның бик оста балыкчы булуы турында да белгәннәр. Аның янына балык алырга дип, төрле тарафлардан – Кемероводан, Томскидан да килгәннәр. Моннан тыш Абау балыкны да бик оста ыслый торган булган. Абау кияүгә дә чыкмаган, ике катлы йортта йортта ялгызы гомер кичергән. Ул узган ел гына 92 яшендә бакыйлыкка күчкән.

Йортны исә XVIII нче гасыр ахырларында төзелгән булырга тиеш, дип фаразлыйлар. Ул бер кадак кагылмыйча, карагач һәм эрбет агачлары кулланып торгызылган. Ә 1904 елдан мәчет-мәдрәсә итеп тотылган.

Юрты-Константиновы – бүген инде бетеп бара торган авыллар исемлегендә. Авылда мәктәп тә, хәтта кибет тә юк. Бүген авылда 60-70 йорт бар, 48 кеше яши. Аларның күбесе лаеклы ялда, 15 ләбе – җәйге чорда кайтып торучылар. Шөкер, клуб, андагы музей эшләп тора әле.

Бүген инде авылны «туристлар сукмагы» дип йөртелә торган махсус маршрутка кертеп, бераз җанландырып җибәрергә дә ниятлиләр. Без дә Абау йортыннан башланган экскурсиядә булдык. Юлыбыз авылның изге урыннарын саклаучы – «Тынлык сакчысы» яныннан үтә. Ник тынлык сакчысы? Экскурсияне алып баручы Нәсимә Садыйкова якында гына мөселман каберлеге булуын, бу тирәлектә шауларга, музыка яңгыратырга ярамавын искәртте. Аннары сукмагыбыз янәшәдә генә булган Изге чишмә янына китерде. Гасырлар дәвамында, дөньяда барган төрле вакыйгаларга игътибар итмичә генә челтерәгән чишмә суы дәвалау көченә ия икән. Аны лабораториядә тикшерткәннәр, суның шифалы булуын белгечләр дә раслаган. Суын татыгач, аны пластик шешәләргә тутырып, Мәхәббәт агачы янына атлыйбыз. Ул 1589 елгы, ягъни XVI гасыр вакыйгаларын искә төшерә. Казак милләтеннән булган һәм элек күчмә халык булып яшәгән калмак кызы бер-берсенә гашыйк булган. Диннәре бергә кавышырга рөхсәт итмәгәч, яшьләр биредәге зур агач янында очрашып йөргән. Аннары агач картайган, егылган, аның урынында яшь үсенте борын төртеп, күтәрелеп киткән. Хәзер барлык туйлар да шушы агач яныннан башлана, парлар аның ботакларына теләк теләп тасма элә икән.

Чираттагы тукталыш йолалар үткәрү өчен дип тәгаенләнгән Шөкерана аланы. «Мин кече бала булганда монда йола үткәределәр. Ул бик эссе җәй иде. Әби-бабаларыбыз җыелды. Балалар йөгерешеп йөри, өлкәннәр ыгы-зыгы килә. Ике казан асып, берсендә – аш, икенчесендә пылау пешерделәр. Аннары безнең әби-бабаларыбыз Аллаһыдан яңгыр сорап, дога кылды. Кич белән, дөрестән дә, каяндыр болыт килеп, яңгыр ява башлады. Хәзер инде йолалар үткәрмибез. Әмма әби-бабарыбыздан калган гореф-гадәтләрне саклarга тырышабыз, бакый дөньяга күчүчеләрне дә мөселманча җирлибез», – дип сөйләде экскурсияне алып баручы Миннехәят ханым.

Аннары 1800 нче елларда салынган, бүген җитди ремонт көтүче мәчет янына тукталабыз. Совет хакимияте урнашкач, аны клуб иткәннәр. Бүген Аллаһ йортының эчендә бер нәрсә дә юк. Анда шушы көннәрдә генә ремонт башланган. Төбәкне өйрәнүче ир-атларның бер өлеше, мәчет янындагы чирәмлеккә җәелгән келәм өстенә басып, Новокузнецк шәһәренең «Чулпан» мәчете имам-хатыйбы Әнвәр Әшировка оеп, намаз укыды, тәкбир әйтте. Моны авылда яңа тормыш башланып китәчәгенә юрадылар.

Капка төбендә утыручы Нәркәз, Раяна, Фәния ханымнар белән дә аралашып алдык. Алар татар телендә бик матур итеп сөйләшә. «Балаларыбыз гына туган телләрен начаррак белә, – диләр. – Өлкәннәр китеп бара, эш булмагач, яшьләр авылда калмый. Җәйләрен бездә күңелле, кыш көне моңсу». Алар – шушы авылда, йорт янындагы бакчада чүп утап, өй тирәсендәге эшләрне башкарып, кышлыкка утын хәзерләп, аз булса да акча эшләү өчен, агачлардан кайры куптарып, аны тапшырып үскән ханымнар. «Пычкының бер ягыннан эти тартса, икенче ягыннан балалар чиратлап тарта иде. Атта да йөрдек, тракторда да эшләдек. Бәрәңге дә күмдек. Бар эшне дә башкарып үстек», – дип сөйләде алар. Ханымнарның берсе Томскида яши. Җәй көне апрельдә Юрты-Константиновыга кайта. Сентябрь, октябрьдә генә китә. «Әти-әниләре, ире, абые, апалары, туганнары – барысы да соңгы йортын шушы авыл зиратында тапкан. 72 яшьлек Камилә ханым исә Томскида гомер иткән, штукатур-маляр булып эшләгән. Пенсиягә чыккач, туган авылына кайткан. «Авылда шәһәргә караганда әйбәтрәк. Пенсиягә чыккач кайткан идем, шуннан бирле яшим. Шәһәрдә һава җитми», – ди ул.

Авыл белән танышуны тәгәлләгәч, конференциянең дәвамы – клубта Юрты-Константиновы авылын саклап калу темасына багышланган «түгәрәк өстәл» утырышы башланды. Анда авылның актив кешеләре, төбәк тарихын өйрәнүчеләрдән тыш Яшкино муниципаль округы халык депутатлары советы рәисе Юрий Вульф, аның киңәшчесе Олеся Новосельцева, округ депутаты Алена Гребенюк та катнашты. Нәфисә Садыйкова әйтүенчә, нәкъ менә алар авылга ярдәм

● А.Борһанов һәм Н.Садыйкова-Еремейкина.

● Алена Гребенюк һәм Юрий Вульф.

АВЫЛЫ

● Конференциядән соң.

кулы сузган, милли-мәдәни үзәкне ябу мәсьәләсе күтәрелгәч, аны саклап калырга булышкан.

Томск өлкәсе «Татар мәдәният үзәге» дәүләт мәдәният учреждениесе хезмәткәре Владимир Волков сөйләшүне калмаклар тарихыннан башлады. «Әле Себер җирендә яшәүче бу төркемнең тарихы турында күп нәрсә билгесез, калмаклар тарихы турында әдәбият та юк», – диде ул. Алар турында кечкенә генә бер диссертация язылган, бу тема белән башка беркем дә кызыксынмаган. Ә казынсаң, күп кызыклы мәгълүмат табылыр, тарих ачылыр иде.

В.Волков калмакларны кайчандыр Алтай краенда яшәгән зур кавем телеутлар белән туры-дан-туры бәйле халык, дигән фикердә тора. Алар төньяк чикләргә, Новосибирск җирләренә килеп җиткән, бик актив булулары белән аерылып торган. Әмма үзара мөнәсәбәтләр катлаулы булган, Россиягә каршы сугышлар алып барганнар. Телеутларның үз эчендә дә каршылыклар башланган. XVII гасырның икенче яртысында аларның бер төркеме Том елгасы буена күчеп утыра. Икенчесе көньяккарак – Кузнецк тарафына китә, телеутлар булып калалар. Теләсә нинди очракта да алар хәрби кешеләр булган. Татар-калмаклар дигән термин XIX гасыр ахырында килеп чыга. Бу инде катнаш халык, алар бохаралылар белән дә, Идел буеннан төрле елларда репресиягә эләгеп килгән Идел буе татарлары белән дә кушылган. Калмаклар арасында бик борынгы фамилияле кешеләр дә бар. «Документларны җыярга, аларны бастырып чыгарырга кирәк. Ревизия кенәгәләрен өйрәнеп чыгу да кызыклы булыр иде», – ди В.Волков. Биредә борынгы фамилияләләр дә бар. Тикшереп карагач, нәсари һәм мөселман төркемнәрдәге калмаклар бертуганнар, бер нәсел кешеләре булып чыккан. Бу бик зур зур нәсел булуын аңлата. Моннан тыш калмаклар генетик яктан калмыкларга якын халык булып чыккан.

«Томская писаница» музей-тыюлыгы директорының фән буенча урынбасары Вадим Горяев конференциядә катнашучыларның игътибарын 2010 елда үткәрелгән мониторинг нәтиҗәләре буенча калмакларның исәбе бик нык кимүенә юнәлтте. «Авылда яшәүче ханымнар үз милли мәдәниятен саклый. Нәсимә, Миннехаят кебек ханымнар эш шартлары уңайсыз, хезмәт хакының түбән булуына, яки бөтенләй түләнмәвенә карамастан, фидакярлек белән хезмәтләрен дәвам итә», – ди ул. Клуб бинасы да биредә яшәгән кешеләр тырышлыгы белән генә аякка бастырылган. Ә музейдагы экспонатлар юкка чыга бара. Аларның күбесе корт белән зарарланган. Әйтик, сыр ясау приборы порошок булып таралырга тора. Биредәге агач караватъ – бик сирәк ядкәр, ул өлкәнең бер генә музеенда да юк. Әмма ул да корт белән зарарланган. «Мәдәниятне, тарихны югалтабыз. Абау йорты авышып бара. Ярты гасыр элек бу урамда ике катлы 22 йорт булган. Галим В.Кимеев 1991-1995 елларда бу якларда йөргәндә, анда алты ике катлы корылма була әле. Бу биналардан хәзер мәчет, Абау йорты гына сакланып калган», – дип искәртте В.Горяев. Дөрес, соңгы вакытта боз беркадәр кузгалып киткән. Экскурсия планнары эшләнгән, текстларына кадәр булдырылган. Директор урынбасары В.Горяев та «Томская писаница» музей-тыюлыгының бу эшкә кушылырга әзер булуын белдерде. Әмма эш акчага килеп төртелә. Абау йортын реконструкцияләү проекты гына да 8 миллион сум торачак. Ә инде яңарту эшләренә 40-50 миллион сумнар тирәсе акча кирәк булачак. Вадим Горяев, «Түгәрәк өстәл» утырышының ике төбәкнең җитәкчеләре нинциативасы белән үткәрелүен искәртеп, резолюцияне Кемерово өлкәсе һәм Татарстан республикасы җитәкчеләренә мөрәҗәгать белән тулыландырырга тәкъдим итте. «Без бүген әйткән конкрет фикерләр реаль нигезгә ия. Ике төбәкнең дә белгечләрен кертеп, комиссия булдырырга мөмкин», – диде ул.

Татарстан республикасы татар төбәкчеләре оешмасы рәисе А.Борһанов йортны торгызуны тәэсирле «Томская писаница» яки берәр муниципаль төбәкне өйрәнү музее кысаларында бер штат булдырудан башланырга, эшнең этаплап барырга тиешлеген ассызыклады. Эшнең этнотуризм яки туризм, яисә «Татартур» проекты юнәлештә алып бару мөмкинлеге дә белдерелде.

Эшне башлап җибәрү өчен исә Россия гранты алу тәкъдиме дә булды. Пенза өлкәсеннән төбәкне өйрәнүче Гөлназ Самочкина тарихи һәйкәлләрне яңартуга грантлар алу тәҗрибәсе белән уртаклашты. «Узган ел танылган лингвист-төрколог, СССР Фәннәр Академиясенең әгъза-корреспонденты Әдһәм Тенишев укуларын үткәрдек, мемориал такта куйдык. Бу юнәлештә дә күпмедер акча алырга мөмкин,» - диде ул. Ул шулай ук меценатлар килеп чыгу мөмкинлеге булуын да искәртте, мисалга Пенза өлкәсендәге Даньшино дигән авыл турында сөйләп алды. Ул үлеп бара торган авыл була. Даньшинода туып үскән, хәзер Мәскәүдә яшәүче эшмәкәр авылның бетеп баруы турындагы хәбәрне укып, йортларын яңарткан, туристлар сукмагын ясаган.

Өлкәнең Мариин районыннан килгән төбәкне өйрәнүче Рәмзия Хәмзина Тункинка авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлнең тузуын һәм халыктан акча җыеп мәрмәр һәйкәл куюлары турында сөйләде. Тиз арада кечкенә генә авылдан 240 мең сум акча җыеп алганнар. «Зиратны тәртипкә китерү өчен дә акча җыйдык. Сабан туен да үз көчебез белән уздырабыз», – диде ул.

Күп кенә мәсьәләләр, гадәттә, аерым кешеләрнең инициативасына бәйле. Бу уңайдан Татарстанның Питрәч районы Чыты авылында яшәүче Миңнур Шәмсетдинов эшчәнлеге үрнәк итеп куярлык. Аны районның мәдәният бүлеге башлыгы, район мәдәният йорты диекторы, район спорт бүлеге җитәкчесе итеп куярга телиләр. Әмма ул бер кая да китми, Чыты авылы чишмәсен берүзе тәртипкә китерә, авыл башына Мәүлә Колый яшәве турында баннер куя, музей туплап эшләтеп җибәрә, түгәрәкләр алып бара.

Шул ук вакытта төп әһәмият яшь буынны туган ягын ярату рухында тәрбияләү мәсьәләсенә дә бирелергә тиеш. Альберт Борһанов балаларда туган якларын, үз милләтләрен ярату хисләре тәрбияләүнең, аларның җиде буынга кадәр үз әби-бабаларын белергә, шәҗәрәләрен өйрәнергә тиешлеген белдерде, аларның үз нәселләре белән горурланып үсүләре әһәмиятле икәнен ассызыклады.

Әлбәттә, Юрты-Константиновода яшәүчеләрнең бу көнне авылларының яңарып, матурланып китәчәгенә, аның киләчәге булуына ышанычлары артты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

● Тынычлык сакчысы.

Гаяз Исхакый – бар гомерен татар халкын берләштерүгә, аңа хөр, бәхетле тормыш яулауга багышлаган шәхес. Башка милләт булса, мөгаен, ул үзенең хәтта Тукай «Милләт юлбашчысы» дип бәя биргән бөек әдип юбилейларын барча мөселман илләреннән иң абруйлы кунакларны чакырып, үзебезнең дә җөмһүрият башлыклары катнашында билгеләп үтәр иде. Тик Исхакыйның 140 еллыгы, 145 еллыгы да тавыш-тынсыз гына үтеп китте. Исхакыйның исеме генә кайтты, әмма рухы-җаны татар арасына әйләнеп кайта алмады. Ул бүген дә безгә бик рәнҗидер сыман. Әмма Исхакыйның «Аллага тапшырып, хәрәкәт итәргә кирәк», дигән шигарен һич тә онытмыйбыз. Исхакыйның данын-рухын татар милләтенә кайтару өчен алда да көрәшәчәкбез.

Менә, Исхакыйның илне ташлап киткән чакта алып барган көндәлек битләрен таптык. Комиссарлар ышыгында дан алган кайбер драматургларыбыз үз әсәрләрендә Г.Исхакый, С.Максуди, Ф.Туктаров, Г.Батталларны хәер сорашып йөргән качаклар хәленә төшереп тасвирлаудан да тартынып тормады бит. Андыйларга Исхакый көндәлеге – лаек җавап. Алтынга корым ябышмаган шикелле, Исхакый-Максудилар безнең өчен маяк булып кала.

Гаяз ИСХАКЫЙ

Япониядән

(Әдип көндәлегеннән)

1919 ел, 1 июль.

Бүген Солых бәйрәме. Бөтен урам автомобиль берлән тулган. Һәммәсе дә төрле-төрле иттифакъчыларның байраклары берлән зиннәтләнгәннәр. Японча-инглизчә шигарьләр язганлар, урам тулы халык. Һәммәсе солых булганга шадлыкларын белдермәкче булалар. Диңгездәге япон крейсеры бер туктамаенча ата. Ләкин рух алай ук түгел. Һәр кешенең йөзендә шул солыхга бер ышанмау чыкган. Барысының да йөзенә бар да йөрегәч, без дә йөримез дигән мөһер басылган. Без дә урамга тамаша карарга чыкганда, урамда бик күп чех солдаты очратамыз, сорашамыз. Владивостокдан икән. Анда, дүртенче эшелонда, безнең якын танышымыз, Учредительное собрание әгъзасы, комитетның мәгариф нәзары булып торган Егор Егорович Лазарев (Лазарев Е.Е. (1855–1937, тәхәллүсе – Бровинский – революционер, эсер, Учредительный собраниегә делегат итеп сайланган) булырга кирәк иде. Чехлардан бармы, дип сорыймыз. Бар, дип җавап бирәләр. Кызулатып пристаньгә китәмез. Әллә никадәр чехдан сорашамыз. Кайсы бар, ди, кайсы юк, ди. Берсендән чакыртырга җибәрәмез, ләкин, юк, чыгып киткән, диләр. Без Йокоһаманың урамы буе эзләп таба алмагач, сәгать өчкә килермез дип, хат биреп китәмез. Безнең аны күрәсемез килүнең мәгънәсе бар. Чөнки алар бара торган пароход Америкага бара. Әгәр безне дә алса, мәсьәлә хәл ителгән була. Егор Егорович Харбинда вакытда безгә шулай барырга тәкъдим дә иткәнлеге, без ул вакытда үземезнең кәгазьләремезгә ышанып, бик соңга калачак дип, кабул итмәгән идек. Хәзер аны очрата алсак, бик кабул итү ягында. Сәгать өчдә тагын барамыз, җидегә кадәр көтәмез. Һаман юк да юк. Ахырдан аның анда булмавы, пароходда комитетның икенче әгъзасы Брушвитның (Брушвит И.М. (1879–1946) – эсер, Учредительный собрание әгъзасы) гына булуы мәгълүм була. Аны күрергә тырышамыз. Ул да тугры килми. Иртә күрергә булып китәмез. Кичкә безгә Иван, Вафа һәм дә Окубо (Окубо Кочи – Комазава университеты профессоры, тюрколог) күрешергә киләләр. Бүген рамазан бәйрәменең өченче көне булса да, без бер әрмән, бер япон, бер төрек компаниясендә бәйрәм итәмез. Өченче көнгә иртәнге поездга билет алырга куштык. Бүген кичке телеграммада кытайларның солых могаһәдәсенә (килешүенә) кул куймаулары мәгълүм булды. Кытайның Токиодагы сәфире Токио шәһәр башлыгы тарафындан бирелгән зыяфәткә дә килмәгән. Кытай – истикъляли (бәйсез) милләт. Киләчәкдә шәрыкдә зур роль уйнаячак.

2 июль.

Бүген озак йөрегәндән соң, Гомәр (Гомәр Терегулов (1883–1938) – сәяси эшлекле, педагог) чехлар пароходындагы кешеләрне күреп кайтды. Болар берсе Брушвит, икенчесе Климушкин (Климушкин П.Д. (1886–1969) – эсер, Учредительный собрание әгъзасы) икән. Болар – Учредительное собрание комитетында зур роль уйнаган затлар. Хәзер чех булып, солдат киемендә, солдат боткасын ашап, Америкага качып китеп баралар... Без иртәгә китә алмыймыз, чөнки билет булмады. 3 нче июль. Бүген вак-төяк әйберләр алгалап үткәрдек. Иртәгегә билет алдык. Насыйп булса, китәмез. Бүген акча курсы төшде. Себер акчасын бөтенләй алмыйлар. Омскида тагы үзгәреш бар, диләр. Колчак (Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), патша Россиясе хәрби эшлеклесе) берлән Дутов (Александр Ильич Дутов (1864–1921) – атаман, генерал-лейтенант) тартыша, имеш. Ни булса да, Колчакның вәзгыяте бик начарлана булырга кирәк.

4 июль.

Бүген, иртүк торып, поездга китдек. Поездымыз 9 сәгать дә җиде минутда Йокоһама стансасыннан китде. Бик кызу бара. Болай барганда, иртәгә иртәнге пароходка барып җитәчәк. Көн бик бөркү, шуның өстенә, бик ягмурлы. Монда әллә нинди үзенә махсус йылы, вак ягмур ява. Болит шулкадәр түбән, кул сузсаң, җитәчәк. Поезд тау буйлап барганда, тауның итәгенә китә торган башына менеп җитмәгән бик күп болыт агымларына очрыймыз. Бер йирдә, тау өстенәрәк менгәч, поездымыз ярты сәгать чамасы болыт эчендә бара. Көн шулкадәр бөркү, вагонда суга батып барамыз. Кичкә таба сәгать җиделәрдә безгә японча әллә нәрсә килеп сөйлиләр, ләкин без аңламыймыз. Бераздан безгә бер инглиз: «Поезд бара алмый, юлны ягмур юган, шуның өчен, теләсәгез, Кобеда каласыз, теләсәгез, андан ике сәгатьлек йирдә Окаямага да туктыйсыз. Әүвәлгесе зур шәһәр булганга, номерлар-отельләр күп, икенчесе япон шәһәре генә, Яурупада отельләр юк», – ди. Без, төрле-төрле уйлагандан соң, Окаямага барырга буламыз. Кызу, ягмур астында сәгать төнге 12 ярымда Окаямага төшәмез. Вокзалда һичбер төрле русча белгән юк. Шалтыр-полтыр белгәнемез берлән инглизчә сөальләр бирәмез, аңарга японча җавап бирәләр. Ахырдан бер түрәгә бераз инглизчә сөйләп аңлатамыз. Юлымызны өч йирдән ягмур юган, поезд Симоносекига бара алмый, ләкин иртәгә таң берлән сәгать биш дә пароход Симоносекига китә, шулай булгач, без вокзалда гына көтәргә буламыз. Сәгать бишкә кадәр көтәмез, алтынчы була, тагы сорыймыз. Поезд сәгать унда китәчәк, пароход юк, диләр. Аңарга ышанмыйча, икенчесендән сорыймыз. Поезд сәгать дүртдә китәчәк, ди. Шундан соң, боларның сүзләренә өмет юклыгын күреп, тагын белешергә тырышамыз. Поездның кай вакыт китәчәге мәгълүм түгел, дип игълан иткән сүзне белгәч, номер эзләргә тотынамыз. Ерак түгел бер япон өе табып, шунда керәмез. Камыш намазлык, бүлмәнең идәненә урын салалар. Баш астымызга озынча йомры мендәрләр бирәләр. Пальтоларымыз берлән йокларга ятамыз. Сәгать унларда торып, тагы белешергә китәмез. Тагы кырык төрле хәбәр. Берсе кич сәгать җидедә китә, ди. Берсе сәгать унда, ди, сәгать унбердә, ди. Бер ресторанга кереп, чәй эчәргә утырамыз. Йомырка, күмәч, май, чәй сорыймыз. Элгәре май китерә. Андан чирек сәгатьдән йомырка китерә. Андан чирек сәгатьдән әллә нинди соры бер су китерә. Андан чирек сәгатьдән икмәк. Моңарга ачу килеп, йөдәп беткәч, үземез барып күрсәтеп, тагы белешергә китәмез. Анда беразрак русча белә торган япон офицерына очрыймыз. Ул юл бик нык бозылган, ягмур һич туктамый. Поезд өч-дүрт көнсез төшәчәк түгел, ди. Сәгать өч ярымда Кобега китәмез. Көн буе ягмур ява. Поездымыз бер туктамаенча су диңгезендән йөзә. Уң як, сул як су берлән капланган. Кукдән ягмур чиләкләп актарыла. Дөге кырлары су эчендә. Иң зур дөге саплары да күренми. Сәгать сигездә Кобега (Симоносеки, Кобе, Окаяма – Япониядәге шәһәрләр) киләмез. Билетсыз йөдәп бетеп, бер нәрсә эшли алмагач, бер япон номерына китәмез. Ашаганымыз-эчкәнемез юк. Өстемез башдан-аяк су, тир эчендә үземез. Чәй һәм йомырка китерергә кушамыз. Ике сәгатьдән соң йомырка, былчырак чәй эчеп ятып йоклыймыз.

6 июль.

Бүген иртүк торып юынганның соңында пароход мәсьәләсенә керешәмез. Русча белә торган япон вәгъдәсенә килми. Аны бик тынычсызланып көткәннең соңында, ике сәгать кичегеп килә, пароход сәгать уникедә китә, ләкин икенче класста да, беренче класста да урын юк, фәкать өченчедә генә бар. Дүртенчедә булса да ярый, ал гына. Бездән билет акчасы алалар, биш мәртәбә артык хак алганлар. Пароходка кереп утырамыз. Урынымыз иң аскы катда, трюмда. Анда бинийһая эссе. Эчәргә сорыймыз, бирмиләр... Менә кич. Ай моңлы гына яктысы берлән диңгезне сөя. Диңгезнең төбендәге яшерен хәятләрен, диңгезнең эчендәге серләрен укымакчы була. Пароход әйтеп бетермәслек муллыкны ертып, һаваланып, йокларга яткан дингезне ерып алга таба бара... Төнемезне капитандан камыш намазлыклар сорап алып, баш астымызга пальтоларны салып йокларга ятамыз. Ике якдагы ачык тәрәзәләрдән диңгез һавасы безне сөя-сөя йоклата. Әнә таң сызылып килә. Дингезнең әнә теге очында зур куәтле бер кызыл нәрсә чыгарга теләп маташа. Берничә карт япон чыкканлар да кояш чыгышка карап басканлар. Күзләре кояш чыгышына текәлгәннәр. [...] дип кычкыралар да, кулларын берсенә-берсен борып, шарт иткән тавыш чыгаралар, андан әллә нинди сүзләр мыгырдыйлар. Шул эш берничә мәртәбә кабатлана да, куллары берлән йөзләрен сыйпап, борылып китәләр. Болар кояшка гыйбадәт итәләр. Безнең элекке төрк бабайлар кояшка ничек гыйбадәт иткән булсалар, болар да шулай гыйбадәт итәләр. Юыныргы төшәм. Юыну бүлмәсе ир-хатын берлән шыгрым тулган. Хатыннар һәммәсе дә билләренә кадәр бөтенләй ачканлар, тәнләрен акшарлыйлар. Ирләре дә шулай. Берсе-берсенә

китеп барышлый

● Г.Исхакый, С.Максуди, Ф.Туктаров. Париж, 1920 ел.

карамыйлар да, илтифат да итми. Мин боларның шул гадәтләренә, шул безнең канга сеңгән «оят», «оят булу» дигән мәгънәнең булмавына гаҗәпкә калам. Мин күлмәкләрне салмаенча гына юынырга керәм... Пароход өстенә чыгам... Мин диңгез авыруыннан курыкмаганга, пароход өстендә калдым. Бик күп кеше. Безнең пароход бик кечкенә булганга, дулкын бик куәтле булганга, ул тирбәнә, кайвакыт бөтенләй дулкын астында кала кебек була. Дулкыннар пароход өстенә менеп, йөгереп төшәләр. Мин һаман бер почмакдарак коры калып барам. Менә бер дулкын икенчесен куып җитде, алар бер-берсен кочаклап, мине су башымдан аягыма кадәр коендырды. Астымдагы урындык шуып китде. Мин суга батып, бүлмәгә кереп, урынга ятдым, юрган ябындым. Урынга бик вакытлы килеп төшмәмез.

8 нче июль.

Бүген иртәдән бирле без Корея буйлап барамыз. Кыр тулган халык. Һәммәсе без үле күргән кебек ак киемдән. Кырда эшли торган ирләрнең барысы да билгә кадәр бөтенләй ялангач. Хатыннар тәмам үк ялангач булмаса да, күп йирләре ачылган. Балалары да япа-ялангач. Кырдагы эшнең хәзергесе дөге сугару, икенчесе аны утау һәм дә төбен йомшарту. Ирләр төрле исуылда кораллар берлән үзләренең җыйнаган чүпләрен дөге түтәлләре эченә куялар, хатыннар тездән су эчендә дөге утыйлар, төпләрен йомшарталар. Монда әле урып бетмәгән бодай берлән солы очраштыргалый. Көн буе шул бер төрле эш. Мескенләр, тамак туйдырыр өчен бик зур мәшәкатьләргә күрергә мәҗбүрләр...

10 июль.

Без кичә кич берлән Чанчуньга (Чанчунь – Кытайның Гирин провинциясендәге шәһәр) килеп җитдек. Монда безне көтеп торалар икән. Безне чакырган мәсьәләләре бик кечкенә вакыйга, сәяси тәрбиясезлекдән килеп чыккан бернәрсә генә булды. Аны ни дип тә тәгъбир итәр хәл юк. Кыскасы, мондан гыйбарәт: Нияз әфәнде үз эше берлән барганда, аны Семенов (Семенов Григорий Михайлович (1890–1946) – атаман, генерал-лейтенант) берлән күрешдергәннәр. Семенов безнең мөселман эшләре берлән бик танышасы килә һәм дә безнең берлән мөнәсәбәткә керешеп, мөмкин булса, бергә хәрәкәт итәсе килә икән. Себер мөселманлары, Кытай мөселманлары хакында бергәләшеп бер эш эшләп булмасмы, дип уйлый икән. Шуңарга күрә безне күреп сөйләшәсе килә икән. Шуның өчен Нияз әфәндегә безнең берлә барып сөйләшергә әйткән һәм дә юлына акча да биргән. Сөйли торгач, эшнең артында японлар да барлыгы мәгълүм була. Без мәсьәләне мөзакәрәгә куеп, карарлар ясыймыз: беренче, Семенов берлән мөзакәрәгә керешергә ярый. Милли сәясәтне йөрткәндә, ноктаи нәзар фәкать милләтнең мәнфәгате генә булырга кирәк. Шул милли мәнфәгать өчен тартышуда кем ярдәм итсә дә, шул ярый. Сөйләшәчәк мәсьәлә мондан гыйбарәт: Семеновның сәяси даирәсендә безгә бер шәһәр бирелсен, шунда без үземезгә махсус төрк-татар гаскәре төзик. Семенов шул хәрәкәтемездә безгә ярдәм итсен һәм дә безнең мөшкилятемез фәкать шул үземезнең милли эшемез өчен генә тотылсын. Шул мәсьәләләр хакында Семенов берлән фикер алышырга без разый. Шундан соң хәзер үк Семенов берлән барып сөйләшү кирәкме, бераз соңракмы мәсьәләсе куелды. Ул мәсьәлә безнең солых сәфәремезгә барып төртелә. Безнең солых сәфәремез алты ай дәвам иткәннең соңында Япониянең диңгезенә терәлде...

11 июль.

Минем Окаямада калган чемоданларым бүген килде. Эчендә бик күп әйбер бар һәм дә яңлыш куелып калган уналты мең сум акча да бар иде. Һәммәсе сау-сәламәт килделәр. Японлар бу хасиятләрне тәкъдир кылмаска мөмкин түгел. Көн буе теге мөзакәрәләр дәвам итде. Ахырдан Нияз әфәнде Кытай эченә барып кайтырга, Габдулла берлән хәзрәт китәргә дә безгә кеше эзләргә, безгә Чанчуньда көтеп торырга булдылар.

13 июль.

Бүген бер ни дә булмады. Кызулыкдан, тузандан йончып, өйдә ятдык. Монда тору бик мәгънәсез. Һавасы начар. Кешесе юк. Эш юк... Гомумән, эш, җәмәгатьнең иштираке берлән булмаганда, бер ни чыкмый. Кечкенә генә бер мисал. Инглиз матбугатына бирер өчен русчадан мәкаләне инглизчәгә тәрҗемә итдергән идек. Шуны карап мәкалә ясап чыгарга Габдулла Газиздән үтендек. Шул ике сәгатьлек эш эшләмәде. Инглизчә белә торган кешеләремез бер-ике данә булып, алары да шулай милли саботаж ясаганда,ничек эшләргә кирәк.

14 июль.

Бер ни юк. Бераз ягмур яуды да, һавалар матураеп китде. Бүген газета да юк. Кичәге хәбәргә караганда, большевиклар Екатеринбургка һөҗүм итәләр. 15 нче июль. Бүген иртүк Әмрулладан (Әмрулла Аги – Харбинда мәхәллә җитәкчесе) мәктүб алдык. Шимбә көн киләм дигән. Шуңарга күрә, аны шактый озак көтәргә тугры киләчәк. Монда һичбер эш юк. Безнең бу сәфәрнең ундан тугызы көтәргә китде. Хат көт, җавап көт, телеграмма көт, иптәшләрне көт. Монда бүген бик зур тантана берлән Гириндан (Гирин – Кытай провинциясе) Кытайның зур бер түрәсе килде. Аны каршы алырга бөтен гаскәре җыелган. Вокзал башына гаскәре караул куелган иде. Арбасына утырып мәйданга чыгуга атлы гаскәр бик күп сыбызгыдан кычкырта башладылар. Зур тавыш кубды. Миңа кечкенә вакытымда яңа сыбызгылар тотып, дәүрәк малайлар берлән сабан туендан кайтканны хәтерләтде. Бу арада Гирин губернаторы берлән Мукден губернаторларының аралары ачылып тора. Икесе дә Маньчжуриягә генерал губернатор булырга тырышалар. Бу эшне хөкүмәтләре берлән аңлашып эшләп булмый күрәсең. Ике губернатор да берсе-берсе берлән сугышмыйча мәсьәләне хәл кылырга уйлаганнар. Гирин губернаторы Япониягә бик күп йир саткан. Гомумән, Япония берлән эш итде, шуңарга күрә Кытай үзен ярат-мый, ди. Мукден губернаторын халык ярата, ди. Кыскасы гына, боларның берсе Кытайның истикъляллен саклау тарафында булып, Япониягә дошман, берсе Япония берлән эш күрү тарафында булырга. Ике агым тартыша-тартыша сугышка барып җитәләр булырга кирәк. Гирин губернаторы җиңсә дә, Мукден губернаторы җиңсә дә, Япония шул сугышыннан файдаланып, бармагын зурраграк тыгачак, бәлки Маньчжуриянең аерым бер дәүләт булуына эш җиткерәчәк. Бакалым, ни булыр...

16 июль.

Бүген яңа бер эш дә юк. Мәктүб булмагач, кичә үзем язып җибәрдем. Бу мәгънәсез көтү бик туйдырды. Бүген хисапларны карадым, әле расход бик аз тотылган. Шул акчалар берлән бик һәйбәтләп йөреп кереп булчак да бит, расходымызның очы-кырые булмады. Андан соң һичбер ярдәмче юк. Гомәр салам селкетми. Паспорт булса, Харбинга барып, андан Владивостокга бару уенда торам.

(Дәвамы 19 нчы биттә).

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

12 август (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 25нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 0.37 сәгатьтә калка, 19.10 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.21 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Буыннар сызлаганда

3 баш сарымсак һәм 4 лимонны иттарткычтан чыгарып, 1,5 литр кайнар суга салалар, болгатып, 3 тәүлек төнәтәләр, сөзәләр, суыткычта саклыйлар, көненә 1 тапкыр, ашар алдыннан, 1әр аш кашыгы эчәләр. Өлгереп саргайган кыярны иттарткычтан чыгарып, согын сыгып алалар (анысыннан лосьон ясарга була), калган массага тоз кушып болгаталар да, җитен тастымалга сылап, авырткан буынга бәйлиләр, өстеннән пленка һәм шарф урап, 2-3 сәгать тоталар. Тозлы май белән дә дәваланып була. Моның өчен 0,5 килограмм йодлы тоз өстенә аз гына су салып, бөтен су парга әйләнгәнче кайнаталар да, 200 грамм эретелгән каз яки тавык мае кушып болгаталар, яхшылап ябылган карасу төстәге банкада салкынча урында саклыйлар. Буын сызлаганда, йон тукымага шул майны сылап, авырткан җиргә урыйлар.

13 август (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 1.45 сәгатьтә калка, 19.49 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.17 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Балан сихәте

Йөрәк авыртканда, 3-4 аш кашыгы баланны 1 стакан кайнар суда 4 сәгать төнәтәләр, көненә 3-4 тапкыр 1 әр стакан эчәләр. Хроник баш авыртудан интеккәндә, көн саен 1-2 стакан балан согын бал белән эчү файдалы. Бөердәге, үт һәм бәвел куыкларындагы ташларны эретү өчен, көн саен 10-15 балан җимешен төше белән берәм-берәм ашарга кирәк. Бавырны чистарту өчен, ярты килограмм баланны эмальләнгән кәстрүлдә йомшарганчы пешерәләр, иләк аша сыттырып чыгаралар, 250 грамм бал кушалар. 2 атна буе иртән ач карынга һәм йоклар алдыннан 2 шәр аш кашыгы кабалар.

14 август (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 20.14 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.12 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап

15 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 3.01 сәгатьтә калка, 20.30 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.08 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

16 август (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кыз йолдызлыгында, 4.20 сәгатьтә калка, 20.40 сәгатьтә бата. 12 сәгать 38 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 15.04 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Кан тамырларын ныгыту

4 аш кашыгы нарат ылысы, 2 аш кашыгы гөлҗимеш җимеше, 4 аш кашыгы суган кабыгын 0,8 литр суга салып, кайнатып чыгаралар, төреп, төнгелеккә калдыралар. Иртән, сөзеп, тигез 4 өлешкә бүләләр дә, һәр порциясенә 1әр аш кашыгы лимон согы өстәп, көн дәвамында эчеп бетерәләр.

17 август (пәнҗешәмбе). ***Сәфәр аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 5.38 сәгатьтә калка, 20.46 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.00 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

18 август (җомга). ***Сәфәр аеның 2нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 6.55 сәгатьтә калка, 20.52 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.55 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Аджапсандал

500 г помидор, 250 г суган, 300 г кишер, 450 г болгар борычы, 800 г баклажан, 3-4 бүлем сарымсак, 1 чәй кашыгы шикәр, 3 дәфнә яфрагы, ярты стакан үсемлек мае, рәйхан, кинза (күп кешегә ул ошамый, шуңа петрушка белән алыштырырга була), ак әнеч, тәменчә тоз-борыч кирәк, ташкабак һәм ачы борыч кузагы да өстәргә мөмкин. Барлык яшелчәләрне дә якынча бер үк зурлыкта түгәрәкләп-бөҗралап турыйлар, казанга яки чуенга катламлап тутырып, тәмләткечләр сибәләр, май салалар, кайнап чыккач, сүрән утта 40 минут пешерәләр. Мондый рататуй (соте, рагу, лечо) йомшак ак ипи белән ашаганда аеруча тәмле була. Җырчы Федор Шаляпин, Франциядә яшәгәндә, кунакларын шундый рататуй белән сыйларга яраткан һәм аны "татар салаты" дип йөрткән.

Имам нәсыйхәте

Балалар уен мәйданчыгына барсак та, мәктәптән кайтучы укучыларны очратсак та, берәр спорт ярышына барып, үсмерләрнең үзара сөйләшкәнен ишетсәк тә, колаклар үрә тора.

Нигә сүгенә?

Күпчелек балаларның авызыннан ычкынган һәр унынчы гыйбарә – сүгенү сүзе. Барлык балалар да андый түгел, әлбәттә. Әмма бу начар гадәткә ияручеләре байтак. Бәлки, зур булып күренәсе килү теләге, йә шул юл белән үзләрен күрсәтәсе килергә омтылудыр. Ничек кенә акларга тырышсак та, бу чиктән тыш ямьсез гадәтсезлек безнең мөселман балаларын бер дә бизәми шул.

Дөрес, өйдә балаларыбыз авызыннан андый сүзләр ишетелми. Әмма урамга, үз ишләре янына чыккач, алар үзгәрә. Без, өлкәннәр, үз балаларыбызга шул хакта ныклап аңлатсак иде. «Сүгенү сине зур итеп тә, батыр итеп тә, «тека» итеп тә күрсәтми, киресенчә, дәрәҗәңне генә төшерә», – дип, гел тукып торырга кирәк. Тамчы да бит тама-тама каты ташта үз эзен калдыра, шуның шикелле, яхшылыкка чакырып әйтелгән сүз дә йомшак калебкә тәэсир итмичә калмас.

Кем гаепле?

Ә балаларыбыз сүгенергә кемнән өйрәнә соң? Кемдер интернетны, телевизорны, дусларын гаепләр. Әйе, аларда да гаеп бардыр, әмма проблеманың асылы бездә – зурларда. Бала, иң беренче, өйдә, әтиәнисеннән ишетә мондый начар сүзләрне, аннан урамдагы дусларына кабатлый һәм, шул рәвешле, сүгенү сүзләре тарала. Шуңа да, балаларыбызны гаепли башлаганчы, иң әүвәл, үзебез дөрес һәм матур итеп сөйләшергә өйрәник. Үзебез үзгәрми, төзәлми торып, балаларны төзәтә башлау файда бирмәс.

Әгәр дә хәдисләргә күз салсак, сүгенүнең бик начар, бозык гамәлләрдән саналганын күрербез. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Тыйнаклык (оялчанлык) – иманнан, ә иманлы җәннәттә булачак. Сүгенү – дорфалыктан, ә дорфалык (ягымсызлык, сөйкемсезлек) җәһәннәмгә илтә», – дип әйткән (Тирмизи риваяте).

Әйе, әгәр дә ояла белмәсәк, авыздан нинди генә сүзләр чыкмаячак. Ә менә үзебезне кешеләр белән дорфа тотсак, юаш күренмим әле дип, сүгенү сүзләре кулланмасак, бу, ахыр чиктә, гөнаһлы гамәлләр булып тупланып, безне уңышсызлыкка алып барыр.

Үзебез хакында «мин – иман әһеле, Аллаһыга ышанам, мин – мөселман», дип әйтәбез икән, димәк, без, беренче чиратта, телебезне фәхеш сүзләрдән сакларга бурычлыбыз, чөнки безгә үрнәк булган җәннәт юлын күрсәткән сөекле Пәйгамбәребез «Мөэмингә әрләү дә, ләгънәт кылу да, әдәпсез сүзләр әйтү дә, сүгенү сүзләре куллану да хас түгел», – дип әйтеп калдырган (Тирмизи риваяте).

Үзебезне мөселман дип саныйбыз икән, мөселман кешесенә хас булган гамәлләрне эшлик, ә мөселман кешесен бер дә бизәмәгән, аның намусын пычрата торган гамәлләрдән ерак булыйк, бигрәк тә тел мәсьәләсендә игътибарлы булырга кирәк. Әгәр дә без начар сүзләр кыстырмыйча сөйләшә алмасак, димәк, бу безнең сүз байлыгыбызның бик аз булуын күрсәтә. Сүз байлыгыбыз аз икән, ул безне белемсез, надан кешегә санарга нигез тудыра түгелме соң? Белем тупламый торып, бу тормышта ничек уңышка ирешербез соң? «Аллаһыга һәм Кыямәт көненә ышанучы кеше яхшы сүзләр белән сөйләшсен яки бер нәрсә дә дәшмәсен!» (Мөслим риваяте).

Сүз байлыгы әле ул күңел көзгесенең чагылышы да. Кешенең күңеле саф, яхшы булган саен, телендә дә хәерле сүзләр генә була. Ә күңел көзгең тутыкмасын өчен, уйларыңның да дөрес, яхшы булуы зарур...

Үсеп җиткәч

Кеше бу дөньяга аяк басып, акны карадан аерырга өйрәнгәч, үз-үзенә төрле сораулар бирә башлый. Ни өчен мин бу якты җиһанга килдем? Яшәвемнең максаты нидән гыйбарәт?

Бала кешесе әлеге сорауларны башта әти-әнисенә бирә, аннан – укытучыларына. Үз дуслары белән дә бу темаларга сөйләшә. Төрлесеннән төрле җавап ишетеп, төгәл нәтиҗәгә килә алмагач, башка кешеләрдән аерылмыйча, тормыш агымы уңаена яшәүне өстен күрә башлый.

Бу мөһим сораулар тора-бара онытыла. Чөнки инде башка төрле мәсьәләләр барлыкка килә һәм аларны хәл итәргә кирәк була. Әйтик, урта мәктәпне тәмамлаган үсмергә тормышта нинди һөнәр сайларга? Кем булырга? Укыргамы-юкмы? Кемнәрдер 30 яки 40 яшькә җитеп тә, үзенең сәләтен ачыклый алмый, яраткан эшен табалмый интегә, тегендә-монда бәрелеп-сугылып йөри. Ә кайберәүләр тормышта үз урынын таба, яхшы эшкә урнаша. Яраткан берәр шөгыленең керемле кәсеп итеп, шул өлкәдә уңышка ирешеп, халык арасында танылып китүчеләр дә аз түгел.

Төп максат

Әмма бу дөньяда үз теләгәненә ирешкән кешегә дә һаман нәрсәдер җитми кебек, күңеленә нидер тынгылык бирми. Югыйсә, тормышта бәхетле булу өчен һәр нәрсәсе бар: гаиләсе дә, үз йорты, яраткан эше дә... Тик, барыбер, күңелендә тынычлык юк, калебендә – бушлык. Нәрсәне дөрес эшләми?

Әйе, адәм баласы яхшы машинада йөрергә, зур йортта, рәхәт тормышта яшәргә мөмкин, ләкин әгәр дә бу җир йөзендә яшәвенең төп максатына төшенмәсә, күңеленә һич тә тынычлык таба алмаячак. Бу галәмнәрнең Хуҗасын онытып, фани дөньяда Ул кушканнарны үтәмичә гомер кичереп, җир йөзенә ни өчен килгәнебез турында уйламыйча яшәү дөресме соң? Моңа җавапны Коръәндә табабыз: «Аллаһны оныткан (Аның боерыкларын үтәмәгән), шул сәбәпле Ул да аларга үз-үзләрен онытгырган (хәтта үзләренә нәрсә файдалы, нәрсә зарарлы икәнен белмәс булдылар) кешеләр кебек булмагыз. Әнә шулар (Аллаһның итагатеннән чыккан) – фасикъләр» («Хәшер» сүрәсе, 19 нчы аять).

Ни өчен яшибез? Бу дөньяга нигә килдек? Сораулар күп, ә җавабы кайда соң?! Уйлап карыйк әле, безгә берәр кеше тормышта авыр сынауны җиңеп чыгарга булышса, аңа карата нинди мөгамәләдә булабыз? Әйтик, бер кеше бик нык авырый ди. Ул бер табибка барып карый, файда тапмый; икенчесенең дә дәвасы шифа бирми. Хәле көннән-көн мөшкелләнә. Бер дусты килеп, кайсыдыр бер шәһәрдә тәҗрибәле яхшы табиб барлыгын әйтә, аның янына алып бара. Аллаһының рәхмәте белән, ул табиб бу авыру кешене аякка бастыра. Ул кеше үзен әлеге табиб янына алып барган дустына нинди мөнәсәбәт кылачак инде? Әлбәттә, гомере буе рәхмәтле булачак. Чөнки күңеле аны үзенә ярдәм иткән дустының игелегенә игелек белән җавап кайтарырга этәрә.

Рәхмәтле булыйк

Ә хәзер төп сорауга җавап эзләп карыйк. Көн саен кояшны кем чыгара? Басуларда игеннәрне кем үстерә? Чишмәләрдән әчәр суны кем агыза? Шуларны күрә торган күзләрне, җирдә басып йөри торган аякларны безгә кем биргән? «Аллаһы» диярбез бертавыштан. Әйе, шулай. Ә без Аллаһыга даими рәхмәтлеме соң?

Аллаһы биргән сәламәтлек какшап китеп, алдагы мисалдагыча, берәрсе ярдәм кулы сузса, ул кешенең яхшылыгына каршы ничекләр генә итеп яхшылык эшләргә дә белмибез.

Ә сәламәтлек һәм башка нигъмәтләре өчен Аллаһыга рәхмәтле булырга, Үзе кушканнарын үтәп яшәргә, Үзенә генә гыйбадәт кылырга омтылабызмы? Бу сорауга җавап бирүче булар, яшәвебезнең төп максатын Раббыбыз Аллаһы Коръәндә «Зарият» сүрәсенең 56 нчы аятендә бәян кыла: «Мин кешеләрне һәм җеннәрне бары тик Миңа гына гыйбадәт кылсыннар өчен барлыкка китердем». Гыйбадәт кылуыбыз исә Раббыбызга рәхмәтебезне белдерүне күрсәтә. Шөкер итүебез исә Аның әмерләрен үтәп, Ул тыйган гөнаһлардан ерак булудан башлана.

Раббыбызга буйсынып, Аңа гына гыйбадәт кылып яшәгәндә, Ул күңелебезгә тынычлык салыр, бар малыбызга каһәгать булып һәм рәхәтен күреп, бәрәкәт белән, бәхетле тормышта яшәүләрне насыйп итәр. Ни өчен яшәвебезне аңларга, кая барачагыбызны уйлап, ике дөньяны тигез күреп яшәргә Аллаһы тәгалә ныклы иман бирсә иде.

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының Тәберде Чаллысы мәчете мөгаллиме.

Чистайда Исхакыйлар нәселе

Чистай районының Мөслим авылында «Авыл көне» булып узды. Бәйрәм тантанасы Рамил Нуруллин һәм Рафыйк Насыйровның Мөслим авылы тарихы турында документаль китабын тәкъдим итүдән башланды. Заманында бу төбәктәге милли һәм дини тормышның үзәге булган Мөслим авылы мондый саллы, житди китапка бик лаек. Тантанада авторлар үзләре дә катнашты, чыгыш ясадылар.

Шушы авыл тумасы Рамил Нуруллин – Биләр урман хуҗалыгының баш урманчысы Рафыйк Насыйров – тарих фәннәре кандидаты, Аксубай районының Түбән Татар Майнасы урта мәктәбе директоры. Мин дә чыгышымда бу төбәкнең тарихына, бигрәк тә көчләп чукындырулар чорына тукталдым, Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәрендәге вакыйгаларның шушы як авылларында барганлыгын әйттем. Сөйләгәннәремне дәлилләп, Мөслим китапханәсенә Зөләйханың прототибы булган Гөләйзә турындагы «Гөләйзә» китабымны бүләк иттем.

Бу авылга кайтуымның икенче сәбәбе Гаяз Исхакыйның нәселе белән бәйле иде. Г.Исхакыйның әнисе Камәрия абыстай шушы Мөслим авылы кызы була, аның әнисе Мәхфүзә абыстай биредә кырык елдан артык балаларга ислам сабагы бирә. Тарихчы Рафыйк Насыйров Мөслим зиратындагы кабер ташларын өйрәнгәндә, бик матур язылган һәм бик яхшы сакланган бер кабер ташына юлыга. Анда Мөхәммәтша кызы Мәхфүзә абыстай җирләнгәне, аның кырык елдан артык балаларга гыйлем биргүе язылган була.

Метрика кәгазьләре, ревизия документлары белән чагыштырып, нәсел шәҗәрәләрен өйрәнеп, Рафыйк Насыйров бу кабер ташының Г.Исхакыйның әбисе Мәхфүзә абыстайныкы икәнлеген ачыклый. Ул бу кабер ташындагы язуларны күчереп ала, аларны кирилл хәрефләренә дә әйләндерә. Рамил Нуруллин җитәкчелегендә һәм Мөслим мәчете ярдәмендә, Мәхфүзә абыстайның кабере рәткә китерелә, зират капкасының шул турына коймага истәлек тактасы куела. Анда, «Бу кабергә татар халкының бөек юлбашчысы, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, язучы, драматург, нәшир Гаяз Исхакыйның әбисе Мәхфүзә Мөхәммәтша хәзрәт кызы, Габделвәли хәзрәт җәмәгате, кырык елдан артык Мөслим авылы балаларын укыткан галимә-остазбикә җирләнгән. (1839-1902)», дип язылган.

Чыгышда мин Мәхфүзә абыстайның оныкчыгы Сөембикә ападан күп сәламнәр тапшырдым. Ул – Гаяз Исхакыйның апасы Гайнелмәрзиянең кызы, аңа 104 яшь, ул Ташкент шәһәрендә яши. Авылдашы Наилә Потеева аша без аңа Мөслим авылындагы әбисенең кабер ташы һәм истәлек тактасы фотоларын җибәргән идек. Сөембикә апа әбисенең каберен яхшы хәтерли булып чыкты, ул элегрәк анда кайтып та йөргән. Мөслим авылында Гаяз Исхакыйның нәселе белән бәйле истәлекләрне кадерләп саклаганнары өчен ул авыл халкына зур рәхмәтләрен әйтте.

Рафыйк Насыйров белән берлектә, Мөслим зиратында булдык, Коръән укып, Мәхфүзә абыстай рухына, Исхакыйлар нәселенә дога кылдык. Шунысын да әйтергә кирәк, бу нәсел ике яклап та танылган дин әһеле, кырымлы Гәрәйләр династиясе вәкиле Морат муллага барып тоташа, аның кабере янәшәдәге Чирүле Шынталасы авылы зиратында.

«Авыл көне» н халыкның исендә калдырырлык итеп уздырганы, туган авылы турында китап язганы, Гаяз Исхакыйның нәселе белән бәйле истәлекләрне кадерләп саклаганы өчен Рамил Нуруллинга һәм Чулман аръягы төбәгенең төп тарихчысы Рафыйк Насыйровка чиксез рәхмәт!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.
Чистай районы, Мөслим авылы.

Япониядән китеп барышлый

(Ахыры. Башы 16-17 нче биттә).

17 июль.

Бүгеннең иң зур вакыйгасы – большевикларның Златоустны алулары булды. Димәк, большевик Уралның бу ягына чыкды. Хәзер Омскига хәрәкәт башлана. Көн бик эссе, өйдә утырып булмый. Кырык градусдан артык. Милли идарәне эзләргә вә табып, җавап китерергә бер кеше җибәрергә булган идек, Омскидан Колчак кача башласа, милли идарәне табуы бик авыр булыр кебек күренә. Газеталарга караганда, Омскига чит кешене кертмиләр, димәк анда зур паника башланган.

18 июль.

Бүген милли идарәгә озын мәгърузә (доклад) яздым. Томскида Нурулла Карповка (Нурулла Карпов – Томскида «Том сүзе» газетасы нашире), Петропаулда Мостафа Тумашевка озын-озын хатлар берлән мәсьәләне тәмамән ачдым. Һәммәсендән дә берничә сөальләргә җаваплар сорадым. Бу мөрәҗәгать берничә мәртәбә булмаса да, бәлки берсендән-берсендән бер җавап килеп чыгар. Мәсьәлә, фәүкылгадә, чуалчык дәвергә керде. Булмады дип эшне туктатсак, вөҗдан канәгатьләнми, дәвам итдерергә дип карар итсәк, ялгыз бер кеше һичбер бер ярдәмсез шул кадәр мөшкилят эчендә ни эшләмәкче буласың. Әгәр заграницага чыгып киткән бер-ике кешемез булса, әлбәттә, шуларга телеграмма, мәктүб берлән эшне аңлатып, алардан эшне дәвам итдерергә үтенер идек...

19 июль.

Бүген мобилизациягә баруның беренче көне. Монда Чанчуньда артык бер нәрсә булмады...

20 июль.

Кичә кичдән яисә бүген иртә берлән Әмрулла әфәнде килергә тиеш иде. Мәктүбе дә, кеше артыннан әйткән вәгъдәсе дә шулай иде, ни өчендер килмәде. Һәм дә сәбәпләрен күрсәтеп мәктүб дә булмады. Әллә мобилизация мәсьәләсе маниғ булды, әллә башка эш. Инде аны тагы көтәргә кирәк. Безнең бу хәерсез сәфәремез көтүдән гыйбарәт булып чыкды. Бүген мин авырый башладым. Дөресе, авырыйм дип курыкдым. Тамакга бака калыкды, баш авыртды, ангина була дип шөбһәләндем. Башка эш бетде кебек инде, авырырга гына калды, ди. Бер туктамаенча тамак чайкап торып чыкдым. Кичкә таба бака бетде. Бүген газетада Екатеринбургны алу хәбәрен укыдык.

21 июль.

Бүген без көн буе Әмрулланы көтдек, ахрысы килми торгандыр. Хәерле булсын. Нияздан хәбәр алдык. Артык хәбәр юк.

22 июль.

Милли идарәдән мәктүб алдым. Мәктүб 12 нче июльдә генә язылган. Безнең күп мәсьәләләргә җавап биргән кебек – бик күп эшләрне томанда да калдыра. Беренче конференциядә сайланган эш башы Фуад (Фуад Фәссах улы Туктаров (1880–1938) – журналист, язучы, сәясәтче), Солтанбәк (Солтанбәк Мәмлиев, Петроград Эшче-солдат депутатлар советының әгъзасы) әфәнделәрнең килүе мәгълүм түгел. Алар рәсми рөхсәт алырга дип тотынган булганлар да, шуны дәвам итдергәннәре юк, мәгълүм булмаган. Солтанбәк солдатка алынган. Фуады Омскида торадыр, ди. Икенче, безнең виза мәсьәләмез хакында. Анда зур чуалулар чыкган... Гомәр хакында бер сүз дә юк. Бу мәктүбдән соң мәсьәлә тагын бераз үзгәрде. Бик күп уңгайсызлыклар бар. Берсе – мин заграничный паспортымның хөкеме югала. Яңадан алу бик авыр мәсьәлә. Бирмәү ихтималлары да бик якын. Бу – бер. Икенчедән, солдатка каралырга кирәк. Солдатка алулары да бик якын, ул вакытда бөтен план пыран-заран килгән була. Шуның өчен боларның берсе дә ярамый. Фәкать качып керергә, аның өчен минем кулымда нинди булса да паспорт булырга кирәк. Миңа Харбиндан җибәрергә вәгъдә иткән булсалар да, ул да килмәгән. Качып-посып чыгарга маташырга, ләкин бу вакытда тотсалар, зур күңелсезлекләр булу ихтималы бар. Ләкин мондый вакытда куркып торсаң, бер нәрсә чыкмый. Аллага тапшырырга, хәрәкәт итәргә...

Текстны басмага әзерләде:
***Ләйлә* ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.
«Фәнни Татарстан» журналы,
1918 ел, №1.

Үтергеч нурланыш

АКШта халык 5G кәрәзле челтәре вышкалары төзүгә дәррәү каршы чыккан. Компания вәкилләре исә, әлеге челтәр иң тиз һәм иң сыйфатлы элемтә белән тәэмин итәчәк, анда мәгълүмат тапшыру тизлеге 4G га караганда йөз тапкырга яхшырак булачак, дип ышандырмакчы. Әмма алар мондый челтәрнең кеше сәламәтлегенә тәэсире турында бер дә сөйләми. Халыкара “Табибләр әйләнә-тирә мохитне саклау яклы” җәмгыяте һәм аның 27 илдәге бүлекләре исә радиоешлыктагы нурланыш тарата торган 5G челтәрен үстерүне туктатырга өнди. Медиклар кәрәзле технологияләрнең бишенче буынын кеше сәламәтлеге өчен гаять зыянлыга саный. Әлеге челтәр югары ешлыктагы миллиметрлы дулкыннар таралуга нигезләнә. Әмма мондый дулкыннар кыска араларга гына тарала, аның сигналын агачлар, яңгыр йота, шунлыктан АКШта бер-берсенә бик якын урнашкан вышкалар төзи башлаганнар – алар никадәр күбрәк булса, элемтә шулкадәр яхшырак икән. Кешеләр яши торган йортлар югары ешлыктагы нурланыш тараткан спектр чолганышында кала. Халыкара яман шешне өйрәнү комитеты 2011 елда ук радиоешлыктагы нурланышны куркыныч канцероген дип тапкан. 5G челтәре аэропорттагы сканер кадәр үк нурланыш дозасы тарата. Иерусалим университетыннан доктор Яэль Стайн, кеше тиресе микродулкынлы нурланышның 90 процентын йота, дип саный. Миллиметрлы дулкыннар авырту рецепторларын ялкынсындыруга сәләтле, Пентагонның демонстрацияләрне куып тарату системасы нәкъ менә шул принципка нигезләнгән. Нурланыш тарата торган җайланма халыкка таба юнәлтелә, һәм кешенең тиресе түзеп булмаслык авырта башлый. Хәзер исә телекоммуникацияләр индустриясе бөтен әйләнә-тирәлекне шул нурланыш белән тутырырга җыена. Тәүлегенә 9 сәгать буе радиоешлыктагы нурланыш астында тотылган күселәрнең йөрәгендә яман шеш үсә башлаган, аларның ДНКсы зарарланган. Хайваннар белән үткәрелгән тәҗрибәләр күрсәткәнчә, микродулкынлы, аеруча миллиметрлы дулкыннар күзгә һәм иммун системага зыян сала, күзәнәкләр үсешенә йогынты ясый. Галимнәр шуңа чаң суга: 5G Җирдәге бөтен тереклекне юкка чыгарырга сәләтле. Әмма телекоммуникацияләр индустриясе кисәтүләрне санга сукмый, чөнки гаять зур табыштан колак кагасы килми.

(“USA Today”).

Телсез дә, тарихсыз да...

Бразилия Милли музеенда янгын чыгып, 200 еллык тарихы булган музей бинасы бөтенләй янып беткән. Ут 20 миллион предметтан торган тупланманың 90 процентын юкка чыгарган. Иң үкенечле югалтулардан берсе – Бразилиядә яшәүче төп халыкларның телләре турында материаллар архивы. Бирегә 500 ләп һинди кабиләсе яши, шулардан иллеләбенә юкка чыгу куркынычы яный. Әлеге кабиләләр халкы 330 телдә сөйләшә, Милли музейда шулардан 160 лабы турында тикшеренү материаллары – аудиоязмалар, юкка чыккан халыклар телендә җыр, документ, фотосурәт, негативлар, Бразилия этник төркемнәренең лингвистик картасы сакланган. Аларның күпчелеге әлегә цифрлаштырылмаган булган, чөнки бүленгән акчаның күп өлеше бүген җуелу куркынычы янаган тел вәкилләрен эзләүгә тотылган. Мондый архивларны цифрлаштыру бик кыйммәткә төшә. Мәсәлән, Техастагы Латин Америкасының төп халыклары архивы моңа 300 мең доллар сарыф иткән. Рио-де-Жанейродагы Милли музейның еллык бюджеты исә нибары 128 мең долларга тәңгәл. Бер елны, хезмәткәрләренә түләргә акча җитмәгәч, аны хәтта берничә ай ябып та торганнар. Кайбер экспонатларны ремонтлауга исә краудфандинг ярдәмендә акча җыярга маташканнар.

(“National Geographic”).

Рекордлар патшасы

Нью-Йорктан менеджер Ашрита Фурман 1979 елдан бирле Гиннесс китабына кертелгән рекордларны кабатлау белән шөгыльләнә, инде 600 казанышны буйсындырган, шуларның 226 сында үзе рекорд куйган. Аларның кайберләре сәер булса да, кайсылары шактый катлаулы. Әмма Ашританы бернәрсә дә куркытмый. Ул, бертуктаусыз жонглерлык иткән килеш, марафон йөгергән, эфлисунны борыны белән бер километр ярым буе төртеп барган, бер минутта бензин пычкысы белән 24 сыра шешәсен ачкан, бер минутта таякчыклар белән 678 грамм желе ашап бетергән, дөньяда иң зур хула-хупны әйләндергән, иң авыр ботинканы киеп йөргән һ.б.

(“FB.ru”).

Тишек янтаулы сыерлар

Швейцариядәге зур терлекчелек фермаларының барысында да сыерларның янтыгында кеше кулы сыярлык тишек бар. Хайван физиологиясенә мондый үзгәреш кертү нигә кирәк икән соң? Мондый сәерлекне сыерларның сәламәтлеге һәм фермерларның финанс иминлеге турында кайгырту дип аңлаталар. Хуҗасына мөмкин кадәр күбрәк табыш китерсен һәм югары сыйфатлы сөт бирсен өчен, сыер сәламәт булырга тиеш. Әмма еш кына хайваннарның катлаулы ашкайнату системасында тайпылышлар килеп чыга, һәм бу аларны чирләтә. Әлеге патологик үзгәрешләр туклану тәртибен кискен үзгәртүгә, рационга яңа азык өстәмәләре кертүгә бәйле булырга мөмкин. Сыер ашказанындагы микроорганизмнар яңа төр азыкны эшкәртүгә җайлашып өлгерә алмый, ашкайнату процессы бозылу нәтиҗәсендә тупланган газлар исә хайванның гомерен өзә. Менә шулардан саклану өчен махсус җайланма уйлап тапканнар да инде. Тана бозаулар ашказанының беренче камерасына махсус бүрәнкә кертәләр, аның сәламәтлеген контрольдә тоту өчен микрофлораны тикшерергә кирәк булса, клапанны ачып, анализ алалар, җыелган газларны чыгаралар. Гамәли файда китерүдән тыш, сыер янтыгындагы клапан сөт фермасына экскурсиягә килүчеләр өчен күрсәтмә материал да булып тора.

(“TravelAsk”).

Сәер сәйях

Джон Фрэнсиска Planetwalker – “планета буйлап йөрүче” кушаматы тагылган. 1971 елда ул Сан-Франциско култыгында ике баржа бәрелеп, суга 3 мең тонна нефть түгелүен, кош һәм балыкларның һәлак булуын күргән һәм, табигатькә шундый ваемсыз мөнәсәбәткә таң калып, шәхси протест акциясен башлаган – шуннан соңгы 22 елда бер генә тапкыр да автомобильгә утырмаган, бөтен Америка буйлап җәяү йөргән. Әмма Фрэнсиска бу гына аз булып тоелган. 1973 елдан башлап, 17 ел буе ул беркем белән дә сөйләшмәгән. Кешеләр белән ым ишарәләр ярдәмендә, ия язып аралашкан. Кайберәүләр аны җүләргә саный башлаган, әмма Джонның моңа бер дә исе китмәгән. Соңрак ул барыбер докторлык дәрәҗәсенә ирешкән. 22 ел эчендә Фрэнсис 48 штатны әйләнеп чыккан (Гавай һәм Аляска гына калган) һәм хәтта җәяүләп Көньяк Америкага кадәр дә барып җиткән. 1993 елдан гына кабат транспортка утыра башлаган. Үзенең сәяхәте турында китап язып бастырган. 1990 елда кабат сөйләшә башлап, университетларда экология укыта, әмма барыбер һәр ел саен 4 тәүлек буе беркем белән дә аралашмыйча, табигать хозурында яшәп ала.

(“Die Presse”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

14 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 15.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «УЕННАН УЙМАК». 16+
10.00, 23.00 «СВАТЫ». 16+
11.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 Хоккей. Кубок TANECO. Матч за 3-е место. 6+
15.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
16.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00 Хоккей. Кубок TANECO. Матч за 1-е место. 6+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Әхтәм Зарипов турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Мингалим турында телеочерк. 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «НЕВЕСТА МОЕГО ЖЕНИХА». 12+
11.10 «Театральное закулисье». 12+
11.30 «ОТЕЛЬ «ПРЕЗИДЕНТ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПАРФЮМЕРША 2». 12+
14.45 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Моя блокада». 12+
16.30 «Солнце в подарок». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Штирлиц навсегда». Рождение легенды. 12+
21.00 «Время».
22.00 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
23.15 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись». Олег Табаков.
7.35, 18.45 «Предки наших предков».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 Открытое письмо. «Первые открытки России».
8.50 «РАННЕЕ, РАННЕЕ УТРО...»
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ».
11.25 Сказки из глины и дерева.
11.35 «Божьей милостью певец. Зураб Соткилава».
12.45 Моя любовь - Россия! «В гостях у крымских караимов».
13.15 Линия жизни. Лариса Малеванная.
14.10 «ПАСПОРТ».
15.50, 23.50 Цвет времени. Владимир Татлин.
16.05 «Буба».
17.15 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова. П.И. Чайковский. Избранные произведения.
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 Спектакль «Проснись и пой!»
22.55 «Елена Образцова. Жизнь как коррида».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+

Сишәмбе

15 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 16+
10.00, 23.00 «СВАТЫ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Ватандашлар». 16+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
11.30 «Я ИЛИ НЕ Я». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПАРФЮМЕРША 2». 12+
14.45 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Бастионы России». 12+
16.30 «НА ДАЛЬНЕЙ ЗАСТАВЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
23.15 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись». Олег Табаков.
7.35, 18.45 «Предки наших предков».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 Открытое письмо. «Спорт на открытках XX века».
8.50 «РАННЕЕ, РАННЕЕ УТРО...»
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ».
11.25 Сказки из глины и дерева. Богородская игрушка.
11.35, 23.15 «Энрико Карузо. Запретные воспоминания».
12.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.05 «Коллекция».
14.35 «ЦЫГАН».
16.15 Острова. Микаэл Таривердиев.
17.15 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова. Б. Барток, Э. Блох, М. Равель. Избранные произведения.
18.10 «Запечатленное время».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 Спектакль «Город миллионеров».

«НТВ»
4.40 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+
0.45 «Авторитеты». 16+

Чәршәмбе

16 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2». 16+
10.00, 23.00 «СВАТЫ». 6+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Продолжение семейной истории - 20 лет Клинике Нуриевых». 16+
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10, 8.40, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Яхин турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
11.30 «Я ИЛИ НЕ Я». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПАРФЮМЕРША 3». 12+
14.45 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Бастионы России». 12+
16.30 «НА ДАЛЬНЕЙ ЗАСТАВЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
23.15 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись». Олег Табаков.
7.35, 18.45 «Предки наших предков».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 Открытое письмо. «Театр и кино на открытках Серебряного века».
8.50 «РАННЕЕ, РАННЕЕ УТРО...»
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ».
11.25 Сказки из глины и дерева.
11.35, 23.15 «Неразрешимые противоречия Марио Ланца».
12.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.05 «Коллекция».
14.35 «ЦЫГАН».
16.00 Цвет времени. Караваджо.
16.15 «Александр Вампилов».
17.15 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова.
18.15 «Запечатленное время».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 Спектакль «Счастливцев-Несчастливцев».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+

Пәнҗешәмбе

17 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «УЕННАН УЙМАК 2». 16+
10.00, 23.00 «СВАТЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Соотечественники». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.20, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Әхтәм Зарипов турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
11.30 «Я ИЛИ НЕ Я». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПАРФЮМЕРША 3». 12+
14.45 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Бастионы России». 12+
16.30 «НА ДАЛЬНЕЙ ЗАСТАВЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
23.15 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись». Олег Табаков.
7.35, 18.45 «Предки наших предков».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 Открытое письмо. «Портрет эпохи. Истории, рассказанные фотооткрыткой».
8.55 «КАПИТАН СОВРИ-ГОЛОВА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ПРИМИТЕ ВЫЗОВ, СИНЬОРЫ!»
11.25 Сказки из глины и дерева.
11.35, 22.55 «Скучная жизнь Марио Дель Монако».
12.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
13.50 «Первые в мире».
14.05 «Коллекция».
14.35 «ЦЫГАН».
16.00 «Забытое ремесло».
16.15 85 лет со дня рождения Валерия Левенталя. Эпизоды.
17.15 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова.
18.10 «Запечатленное время».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 Спектакль «Юбилей ювелира».
23.50 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+

Җомга

18 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
21.10 «КВН РТ- 2023». 16+
23.10 «БЫВШАЯ С ТОГО СВЕТА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Ватандашлар». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Газинур Морат турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
11.30 «Я ИЛИ НЕ Я». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «НА БЕРЕГУ МЕЧТЫ». 12+
14.30 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Бастионы России». 12+
16.30 «НА ДАЛЬНЕЙ ЗАСТАВЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ПЛЕНКИ АНДЕРСОНА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
23.00 Концерт «И сердце девичье забьется...» 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.40, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
15.05 «Вторая мировая война. Операция «Багратион» (12+)
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Удивительные люди. Лучшее». 12+
23.55 «СТЮАРДЕССА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись». Олег Табаков.
7.35 «Предки наших предков».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 Открытое письмо. «Православная открытка Российской империи».
8.55 «КАПИТАН СОВРИ-ГОЛОВА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ПРИМИТЕ ВЫЗОВ, СИНЬОРЫ!»
11.25 Дороги старых мастеров. «Мстёрские голландцы».
11.35 «Елена Образцова. Жизнь как коррида».
12.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
13.30 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
14.05 «Коллекция».
14.35 «ЦЫГАН».
16.00 «Забытое ремесло».
16.15 «От Мозыря до Парижа».
17.15 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова.
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 Искатели. «Сокровища Хлудовых».
20.30 Линия жизни. Людмила Хитяева.
21.25 «ОБЫКНОВЕННЫЙ ЧЕЛОВЕК».
23.05 «Тунис. Дворец Эссаада».
23.30 «Я МЕЧТАЮ О ДЖИНИ, ДЕВУШКЕ С КАШТАНОВЫМИ ВОЛОСАМИ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+

Шимбә

19 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Килеп китсәм ни була?» 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 Спектакль «Банкрот». 16+
16.30 «Уроки истории». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «ВЕРЮ В ЛЮБОВЬ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Харис Мусин турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20, 0.55 «Йөрәктән-йөрәккә». Рәшит Абдуллин турында телеочерк. 16+
14.20 «Онытасым килми сине». Шамил Шәрипов җырлары. 6+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 16+
22.30 Спектакль «Яшь йөрәкләр». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Архивы истории». 12+
5.25 «Земля людей». 12+
5.50 «Легенды кино». 16+
6.30 «Театральное закулисье». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «КРАСОТКИ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «В НЕБО…ЗА МЕЧТОЙ». 6+
14.45 «Золотое дно Охотского моря». 12+
15.30 «РЕЦЕПТЫ СЕМЕЙНОГО СЧАСТЬЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЕДИНСТВЕННАЯ ЗАБАВА В ГОРОДКЕ». 16+
23.00 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Осведомленный источник в Москве». 16+
15.15 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ». 12+
17.05, 18.20 Концерт «Юбилейный вернисаж». 12+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.40 «ЭВИТА». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «Доктор Мясников». 12+
12.55 «ПО ТУ СТОРОНУ СЧАСТЬЯ». 12+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ОТДАЙ СВОЮ ЖИЗНЬ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Лето Господне. Преображение.
7.05 Мультфильмы.
7.55 «ОБЫКНОВЕННЫЙ ЧЕЛОВЕК».
9.30 «Классная тема!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Тайны старого чердака. «Гравюра».
10.45 «ШУМНЫЙ ДЕНЬ».
12.20 «Воображаемый музей Михаила Шемякина: 60 лет исследований».
13.00 Неизвестные маршруты России. «Тверская область. От Твери до Торопца».
13.40 «Серенгети».
14.35 Большой балет.
16.35 «Тамара Лисициан. Непобежденная».
17.20 «Первые в мире».
17.35 «ЗАДЕРЖАННЫЙ В ОЖИДАНИИ СУДА».
19.45 «Эстрада, которую нельзя забыть».
20.30 «КВАРТЕТ ГВАРНЕРИ».
22.55 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
23.25 «ИНТЕРМЕЦЦО».

«НТВ»
4.35 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Основано на реальных событиях». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.25 «ПЁС». 16+
22.30 «Жара Music Awards-2023». 12+

Якшәмбе

20 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Фәрештә түгел». Илсөя Бәдретдинова. 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы.
8.40 «Сөенеч».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Пар алма». Илназ Баh. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ПЕНЕЛОПА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Адымнар». 16+
7.00 «Канун.Парламент. Җәмгыять».
8.00 «Су буенда учак яна». 6+
9.00 «Җыр - ул хиснең балкышы!» Наил Касыймов турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Күрешергә вакыт табыйк». Илсаф концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.50 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Яшик сөенеп кенә». Рифат Зарипов концерты. 16+

«ЭФИР»
5.00 «Архивы истории». 12+
5.25 «Земля людей». 12+
5.50 «Легенды телевидения». 12+
6.30, 14.15 «Театральное закулисье». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «РЕЦЕПТЫ СЕМЕЙНОГО СЧАСТЬЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВЕРНЫЙ». 6+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «КРАСОТКИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВСЯ ПРЕЗИДЕНТСКАЯ РАТЬ». 16+
23.15 «КУРОРТНЫЙ ТУМАН». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 Ко дню рождения Муслима Магомаева. «Лучший голос Земли». 12+
13.25 Концерт к 80-летию Муслима Магомаева. 12+
14.50 «Муслим Магомаев. Ты моя мелодия...» 16+
16.55 «Штирлиц навсегда». 12+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
23.35 Подкаст.лаб «20 лет спустя». 16+

«РОССИЯ»
6.10 «ЛЮБВИ ВСЕ ВОЗРАСТЫ...» 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «МОЁ СЕРДЦЕ С ТОБОЙ». 12+
15.10 «Петросян-шоу». 16+
17.50 «Песни от всей души». 12+
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
8.05 «КЛАД».
9.25 Диалоги о животных.
10.05 Тайны старого чердака. «Форма имеет содержание».
10.35 «КВАРТЕТ ГВАРНЕРИ».
13.00 Человеческий фактор. «Найти человека».
13.25 «Огненные птицы».
14.10 «Игра в бисер» «Сергей Аксаков. «Аленький цветочек».
14.50 «Аленький цветочек».
15.30 Концерт «Путь к вершине».
17.15 «Пешком...»
17.45 «Рецепты нашей жизни».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
19.45 «Виктор Розов. Пьеса без правил».
20.25 «ШУМНЫЙ ДЕНЬ».
22.00 «Тамбов. Дворец Асеевых».

«НТВ»
4.20 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «ЧЁРНЫЙ ПЁС-4». 16+

Китәсең, моңсыз итәсең...

– Китәм инде, – дип редакциягә килеп кергән Луизаны күргәч, йөрәгем төшеп киткәндәй булды. Бар көчемә: «Китмә, Татарстанны моңсу итмә», – дип кычкырасым килде, булдыра алмадым. Әнә шул эчемдә калган тавышым җаныма тынгылык бирми. Газета аша тавышымны башкаларга да, Луизаның үзенә дә ишеттерәсем килә...

Күңелләрнең бик матур җырга, якты моңга сусаган бер чагы иде. Озак көттереп, зарыктырып, әллә кайдан үз тавышы, үз моңы белән Луиза Батыркаева килеп чыкты. Барыбызны бөтереп алды да үз артыннан торналарга ияртте, су буйларына алып төште. Без сизгерләнеп, сафланып калдык, торналарның канат кагышларына колак салдык. Ә торналары кайда соң? Без хәтта торналарны барлый, көтә башладык. Фәлән авылда ике пар күргәннәр, фәлән районда борчак кырыннан торналар йөгереп үткән.

«Һаваларда торна тавышлары,
Ишетелә канат кагышлары».

Композитор Луиза Батыркаева белән шагыйрь Марсель Галиев иҗат иткән «Кайту» җырын тыңлаганда кем генә битараф калыр икән! Бу җыр әнә шул битарафлыктан чыгу турында да:

«...Кошларда да кеше язмышлары,
Чит илләрдән кайтып барышлары».

Без кайтулар чорында яшибез. Үлгәннәр, үтерелгәннәр, язмышлары тапталганнар, теләсә нинди очракта да бөек булып, кеше булып кала алганнар кайта. «Кайту»ның сүзләренә дә, көенә дә әнә шул мәгънә салынган.

Югыйсә, Марсель үзе Луизага шаяртып кына:

– Мә, бала, минем сүзләргә дә бер көй язып кара әле, – дигән иде. Бу шигыре – иң яратканнарыннан. Ул аны күп кенә композиторларга биргән иде. Әллә аңламадылар, әллә ошатмадылар.

– Бу сүзләрнең үз көе бар, син шуны тап, – дигән иде Марсель. Луиза шагыйрь тәкъдименнән аптырап калды. Белә ул аны, укыганы да бар, тирән мәгънәле, фәлсәфи сүзләрен көйгә салырга батырлыгы гына җитми. Көтелмәгән тәкъдим композитор җанының тынычлыгын ала. Колакта торна тавышлары, кеше язмышлары, йөрәк сагышлары, туган илгә кайту тантанасы...

Ул елны яз иртә килде, шомыртлар, алмагачлар, чияләр ак күбеккә коенгандай, ашыга-ашыга чәчәк атты. Бөек Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм итәргә Казанга ветераннар җыелды. Җәндагы моңга алмагачлар аклыгы, орден-медальләрнең чыңы кушылды. Ул көннәрдә Луиза больницада була. Врач: «Бер айсыз да чыгара алмам», – дигән.

Күңел менә-менә түгелергә тора, шундый чакта түзеп кара әле. Юк, түзәлми Луиза, больница киемнәреннән өйләренә йөгереп кайта. Соңгы көчен җыеп талпына да пианино янына килеп утыра.

Композитор Луиза Батыр-Болгари белән җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗанованың иҗат студиясен ачканда очраштык. Татар җыры, татар сәнгате турында фикерле, кирәкле, мәгънәле чыгыш ясады ул.

Дөньяга әле моңа кадәр билгесез илаһи моң тарала. Кат-кат, туйганчы рәхәтләнеп уйный-уйный да ак кәгазьгә төшерә. Шуннан соң иң матур күлмәген, яраткан туфлиен киеп, җырын кочаклап урамга чыга. Нишләргә, шундый зур шатлыкны кем белән уртаклашырга? Дуслары күп үзенең, шуларның кайсысына барырга? Җырчы Римма Ибраһимоваларга китә. Ишек төпләрнә керергәме-кермәскәме, үзләре күренмәсләрме, дип озак басып тора. Батырлыгы җитми, килештермәсләр кебек, кире борыла. Зөһрә дә якын дус. Аларга китә. Зөһрә җанынан нур түгелгән Луизаны күтәреп кенә алмый. Пианино янына утырта, өй эче җылы, якты моң белән тула. Икенче бүлмәдән яннарына чыгып баскан Хәйдәр, Зөһрәсе зиһенен җыйганчы: «Бу җыр минеке, үзем җырлыйм», – ди. Беренче булып Хәйдәр Бигичев җырлый. Аннан соң Хәмдүнә, башкалар, хәзер инде барыбыз да. Җырлый алмаганнарның күңелендә ул «Кайту», йөрәгендә...

Ә Марсель һаман да шаяртмакчы:

– Син шуннан да яхшырак җыр яза алмыйсың, – ди, үзенең яздырасы килә, ничек кенә әле. «Су буеннан әнкәй кайтып килә» дигән шигырен Марсель бары тик Луиза өчен яза. Берәүгә дә күрсәтми дә, тәкъдим дә итми.

– Бу көйне бары тик син генә яза аласың, – ди. Күңелләрне күтәрерлек, иҗатыңа иң зур бәя, иң зур рәхмәт шушы, шагыйрь сүзләре түгелмени?

Менә шушы ике генә җырын язса да, Луиза зур, талантлы композитор булып калыр иде. Җырлары күп аның. Гөлшат апа Зәйнашева сүзләренә язган «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә» дигән җыры да, Наил Касыймов сүзләренә язганнары да җырлап, тыңлап туйгысыз.

Луиза китап нәшриятында редактор булып эшләп алды. Шагыйрәләрдән Фирая Зыятдинова, Шәмсия Җиһангировалар белән аралашты, дуслашты, алар сүзләренә матур-матур көйләр язды, аларны халыкка танытты. Редактор булып җыр китаплары чыгарды. Композитор Луиза Батыркаеваның үзенең дә халык яратып өлгергән егерме алты җыры китап булып чыкты. Шулай итеп, гадилеге, сафлыгы, бөеклеге, самимилеге белән Луиза барыбызның да яраткан композиторы булып өлгерде.

Әнә шушы җырчылары, шагыйрьләре, композиторлары, барыннан да бигрәк җыр сөючә халкы белән бергә-бергә яшисе, иҗат итәсе, бер-береңне рухландырасы, илһамландырасы иде дә бит, тик китәләр... Китүчеләр арасыннан Латыйф ага Хәмиди искә төшә. Гомере Алма-Атада зарыгып, сагынып үтә. «Күңелле яшьләр» дигән җыры үзе генә дә ни тора. Казакъ вальсына әйләнде. Кайтасы килә, үз иленә кайтып иҗат кичәләре үткәрү турында хыяллана. Фатир, яшәү шартлары булмаганга күрә киткән була. Гомере читтә үтте. Бер китсәң, кайтулар авыр. Гомер кыска, кабере дә читтә.

Талантлы композитор көн дә туып тормый ул. Рәхмәт яусын Луизаның эти-әнисенә. Кызларына 4 яшь тулгач, аның талантын сиземләп, аны укыту өчен Свердлау өлкәсеннән Казанга күченәләр. Көчләрен дә, вакытларын да кызганмыйлар.

Үзбәк егете Абусәет Нәбиев тә – талантлы композитор. Никадәр генә үз милләтен яратса да, Абусәет үзенә караганда Луизаны ныграк ярата. Талантына баш ия, хөрмәт итә. Шуңа да ул, консерватория бетергәч, Казанда кала. Әлеге дә баягы, шул – яшәргә шартлар булмау талантларны сүндерә, читкә җибәрә. Аларга күршеләр белән янәшә коммуналь квартирадан бүлмә бирәләр. Кешенеке тәсләрәк квартира, телефон сорап Луиза ары сугыла, бире сугыла. Музыка тавышы яңгыраткан өчен күршеләр белән ачуланышып бетә.

Әнә шундый тормыш ыгы-зыгысыннан, ваклык-түбәнлекләрдән саклап каласы килгәнгә, Абусәет, Казанда биш ел яшәгәннән соң, Ташкентка күченә. Шәһәр уртасыннан болын кебек йорт бирәләр.

Беләм, кемнәрдер: «Майлы икмәккә алданып китмәсеннәр», диячәк. Ләкин күрше белән яшәп, иҗат итеп булмаслыгын үз башына төшкәннәр генә белә.

Композиторлар берлегендә дә Луиза Батыркаеваның иҗатын тулысынча бәяләп бетермәделәр. Композиторлар берлегенә әгъзасы итеп алырга да Сара апа Садыйкова яшенә җиткәнен көтәргә булдылар кебек.

Мәдәният министрлыгында да Батыркаеваның үтенечәнә колак салырга бик ашыкмадылар. Үтенече халык өчен иде. Җырларын җырлап, пластинка чыгару өчен бер хат, рөхсәт яздырып алу иде. Булмады, бирмәделәр. Луиза Ташкентка китәр алдыннан Композиторлар берлегенә дә саубуллашырга керә. «Китмә», дигән сүзне ишетәсе килә аның. «Хәерле юл», диләр. Кайберәүләр китүенә хәтта сөенеп калгандыр кебек.

Китте Луиза. Талантларны зурлый, кадерен белә торган яклар да бар. Беләм, Ташкентта аңа иркен, затлы фатир да, яшәү, эшләү шартлары да булыр. Кайда да югала торган түгел, эшләр, иҗат итәр, балалар үстерер. Ләкин талантларны зурларга үз халкы, үз җирлеге кирәк. Читтә никадәр зур булсаң да, онытыласың. Моңа тарихта мисаллар күп.

Бу көннәрдә телевизордан яраткан җырларга бәйге кебегрәк анкета сораулары буенча тапшыру булды. Л.Батыркаеваның «Су буеннан әнкәй кайтып килә» дигән җыры иң күп балл җыйганнардан. Халык җырыннан кала, узган елның халык яраткан иң яхшы җырлар арасыннан беренче урынны алган. Күрсәтергә автор үзе генә юк. «Иҗат командировкасында», диделәр. Әһ, шулай гына була күрсен иде. Луиза сәнгать осталарына гына түгел, ул халыкка, Татарстанга кирәк. Кайда гына яшәсә дә, әнә шул сүзләрне исеннән чыгармасын иде. Әйтергә теләгән сүзләрем кайту турында түгел, ә талантларны җибәрмәү һәм югалтмау турында.

Бу язмам газетада чыккач, бер давыл булып алды. Композиторлар берлегеннән редакциягә мине, Луизаны тиргәгән хатлар килде. Җибәрмәгез Луизаны, фатирымны бирәм, дип килүчеләр булды. Ул әле исәнсау. Рәшидә апаны күптән түгел күрдем, кочаклап алдым.

Ул чакта Луиза китте. Сагынуга чыдый алмый тагын кайтты. Тагын китте. Кайтты. Яңа җырлар язды, китаплар чыгарды, авырды. Көрәште. Җиңде.

«Кайту» дигән җыры өчен Луиза Батыр-Болгарига дәүләтебезнең Тукай бүләген бирделәр. Ишеткәч, җиргә ятып (бакчада кишер чәчә идем), рәхәтләнеп еладым. 21 апрель иде. Ул елны яз иртә килде. Үз бакчамнан үзем үстергән тюльпан чәчәкләремне бер кочак урдым да аңа илтеп бирергә булдым. Шигырь бәйрәменә соңга калдым, чәчәкләремне Тукайга салдым.

* * *

Әй, гомер агышлары. Аккан сулар кебек үтә дә китә икән. Китүләр, кайтулар арасында йөрсә дә, Луиза ханым иҗаттан, көрәштән аерылмады. Татар моңына каршы («Үзгәреш җилләре») көрәш барса да, аның җырлары исән. Сәхнәләрдән яңгырлана, радио-телевизорлардан ишетелеп, күренеп тора, халык көенә әйләнеп күңелләрдә яши.

14 августта аның туган көне. Олуг, бик матур, түгәрәк гомер бәйрәме. Шул уңайдан сәнгать түрәләре каршына барды. Кичәсен үткәрәсе, халык белән очрашасы килүен, әсәрләрен китап итеп чыгарасы килүен житкерде. «Акча юк», – диделәр. Булыр әле, Луиза, бер дә кайгырма. Татар моңына беркайчан да акча булганы юк. Соңгы елларда бигрәк тә!

Луиза, халык сине ярата! Бусы инде теләсә кемгә эләкми, шуны белеп яшә!

Фәния ХУҖАХМӘТ.

Мәдәни җомга

Курчак кына димәгез...



«Эпицентр кукол» берләшмәсе Гамәли бизәү сәнгате рәссамнарының иҗади берлегендәге курчак секциясе белән бергә «Россия халыклары – Россиянең йөрәге» дип исемләнгән зур проект башлап җибәргән. Илебездә 190 халык вәкиле яши һәм иҗатчылар шуларның барысын да курчакларда гәүдәләндереп, Россиянең байлыгын, төрлелеген чагылдыруны максат итеп куя. Проектка инде бер ел булып килә, бу вакыт эчендә алтмышлап курчак иҗат ителгән. Аның унбишен Казаныбызга да алып килеп «Казан Кремле»ндәге «Мирас һәм традицияләр» исемле күргәзмәдә күрсәттеләр.

Рәссамнар алдында халыкның характерын, асыл билгеләрен чагылдыру яисә берәр әкият яки риваятьне гәүдәләндерү максаты куелган. Кыскасы, һәрбер курчакның үз тарихы булырга тиеш.

Рәссам Василий Андросов, мәсәлән, якут кәләшен атка атландырып гәүдәләндергән, чөнки ат күчмә халыкларның тормышында зур урын тоткан. Якутларның атны изгеләштерүе олонхо милли эпосларында да чагылып тапкан.

«Атсызны юлда биш бәла сагалап тора, атлыдан бер бәла дә кача», дигән мәкальләре дә бар. Якутлар бүген дә атның кылларын рухларга корбан итеп бирә. Кыллар белән туйларда агач кымыз чүлмәкләрен, безнең Сабан туе кебек зурлап билгеләп үтелә торган Ысыах бәйрәмендә зур күн агачны һәм күн капчыкны бизи.

«Хомус Хотун» дип аталган тагын бер курчагы бер үк вакытта хатын-кызны да, хомус исемле милли мәдәниятләренең символы дәрәҗәсендә кадерләнгән музыка уен коралын да гәүдәләндерә. Хомус галәм тирбәлешләрен чагылдыра һәм кешене өске дөнья белән бәйли дип исәпләнелә.

Рәссамны бу курчакка хомуста виртуозларча уйнаучы «Айархаан» этнотөркеме, аерым алганда, аның өч хатын-кыз музыканты илһамландырган. Курчакның кием XVI-XVII гасырлар якут кәләше киемнәренә охшатып тегелгән. Корсет бер үк вакытта шул дәвернең хәрби киемен хәтерләтә. Бу чорда Тыгын Дархан исемле баһадир аерым-аерым яшәгән һәм бер-берсен дошман күргән төркемнәрне дошманнан саклап калу өчен берләштергән, хәрби кием чалымнары кертеп ясау бик урынлы.

Тагын бер рәссам Агафья Колесованың айга ашкан ятимә кыз турындагы риваятьне курчак аша тасвирлавында татар һәм якутларның уртак төрки тамырдан булуы күренә.

Татьяна Калининаның «Чүлмәк тоткан Мәрьям» исемле кумык курчагы ошады. Кумыклар – Дагыстанда яшәүчеләр арасында сан ягыннан икенче урында торган төрки халык. «Бер кумык – кумык, ике кумык – җыр, өч кумык – филармония» дигән әйтемнәреннән чыгып фикер йөрткәндә, бу халык җырларга ярата. Кумыкларда бер туй йоласы бар. Кәләш кияү йортына кергәндә, бер кулын бал чүлмәгенә чумдырып алып, ишек янында бал эзе калдыра. Бу йола бәхет, муллык, шатлыклы тормыш билгесе дип исәпләнелә. Мәрьям исемле курчак нәк шул йоланы гәүдәләндерә.

Кыскасы, һәр курчак үзенчә мөлаем. Дагыстан кызының аккош кебек горур биюе матур чагылдырылган. Чегән кызының ирек сөючәнлеге соклану уята. Алман хатыны янында йон төене белән уйнаучы песи баласы, үзбәк кызы янәшәсендә гәүдәләндергән ап-ак бөдрә сарык бәтие бу ике скульптурага да йомшаклык өсти.

Рита Казанцеваның Айбикә исемле татар курчагы исә бер дә күңелгә ятмады. Костюмы Казан ханбикәсе Сөембикә киемнәре эскизы буенча эшләнде диелсә дә, зиннәтле энҗе ташлар белән бизәлсә дә, курчак әллә нинди килешсез килеп чыккан. Үзе тутырган тавык кебек таза. Күзләрендә бер җан әсәре, нур юк. Сөембикә курчак булып сынландыруга бик лаек шәхес, әлбәттә. Әгәр автор Сөембикәне ясауны максат итеп куйган булса, аның тормышын өйрәнергә, кыяфәтен ногай кызларына охшатыбрак ясарга кирәк булгандыр, бәлки. «Эзбир» чырайлы бу курчак тамашачыга татар хатын-кызы турында тискәре фикер генә уятырга мөмкин. Дөресен генә әйткәндә, ул бөтенләй татарга охшамаган. Халкы нинди, курчагы да шундый, дияргә генә кала...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәех улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәләк ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 11.08.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2500 данә

Заказ 2630

16+